PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН
№ 3 / 2023

# СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

могҗиза
АНА
ышанычы көче

БАТУЛЛА
тормыш
кагыйдәләре

бәйрәм
табынына
КАТЛАМА

## Ирина МИХАЙЛОВА:

«Бердәмлек бүген аеруча кирәк».



сеть ювелирных салонов
ЭКСКЛЮЗИВ

ЖАНЫГЫЗ НИ ТЕЛИ!

60% КАДӘР ТАШЛАМА*

Казан, Р. Зорге ур., 67; Бутлеров ур., 29; Чистай ур., 15/16; Восстание ур., 62.

www.exclusive-jewelry.ru vk.com/сеть ювелирных салонов «Эксклюзив» t.me/exclusive_kazan

Реклама

*Акция 31.03.2023 кадәр дәвам итә

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2022




Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

**Баш мөхәррир**
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зәлия Ахунова, Ирада Әюпова,
Зилә Вәлиева, Гөлүсә Батталова,
Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова,
Альбина Насыйрова, Алсу Нәбиева,
Сәрия Сабурская, Гүзәл Сәгыйтова,
Нурия Һашимова, Рафаэль Шәвәлиев.

**Редакциянең гомуми телефоны** 222-09-77

**Баш мөхәррир урынбасарлары** 222-09-78
Мәликә Әсәтуллина
Гөлнур Хәсәншина
**Җаваплы сәркатип**
Алсу Шакирова
**Әдәби мөхәррир**
Эльмира Закирова
**Сайт мөхәррире**
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Рекламаның эчтәлеге (фото, текст) аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

**Тышлыкта:**
Ирина Михайлова
Фото: Темине Мкртчян

**Мөхәррирләр**
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Лилия Гәрәева
Фәгыйлә Шакирова
**Верстка**
Резеда Галиуллина
**Корректор**
Фирдәвес Исмәгыйлева
**Фотокорреспондент**
Анна Арахамия
**Гамәли хезмәткәрләр**
Ильмира Сөләйманова
Павел Фадеев

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 22.02.2023 ел.
Чыгу көне: 3.03.2023 ел.
Заказ С-0484
Тираж 8351

Учредитель:
Акционерное общество «Татмедиа»




ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
**www.syuyumbike.ru**
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+



Казанның Чернышевский урамында урнашкан «Яратам» сынлы композициясе. Сынчы Фәнил ВӘЛИУЛЛИН эше. Фото: Анна Арахамия

# Баш мөхәррир сүзе



Кадерле укучым!

Менә ничә ел инде 8 Март бәйрәме алдыннан республикабызда «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» бәйгесе уза. Без бу бәйгене көтеп алабыз. Үзебез өчен һәрвакыт яңа ачышлар ясыйбыз, һәм алар белән сезне журнал битләрендә дә таныштырабыз.

Сәхнәгә хатын-кызларыбызның иң лаеклылары күтәрелә бит. Алар ирешкән уңышларга шатланып, горурланып карыйсың; алар үткән юлны, кичергән сынауларны тыңлаганда күз яшьләреңне яшерә алмыйсың... Быел әнә барысы да диярлек иңнәренә яңа вазыйфа салган (үзләре теләп!): махсус хәрби операциядә катнашучылар өчен гуманитар ярдәм оештыручыларга кушылган. Алай гына да түгел, бу эшне үзләре оештыра, үзләре башлап йөри, хәтта илтеп тапшыра... Сынаулар безне ныгыта гына!

Ачыктан-ачык әйтегез әле: сезгә үз гомерегездә бер мәртәбә булса да: «Булдыра алмассың, син бит хатын-кыз», «Ярар инде, юл бир, син бит хатын-кыз» дигәннәрен ишетергә туры килгәне булдымы? Кайчак турыдан-туры кимсетеп, кайчак кимсеткәннәрен аңламыйча да... Ә мин күңелемнән әлеге республика бәйгесендә катнашкан ханымнарны тагын бер кат барлыйм һәм... СИН БИТ ХАТЫН-КЫЗ, дим.

Бәйрәм белән барыгызны да! МИН БИТ ХАТЫН-КЫЗ, дип яшик!

Яратып, Лариса МАЛИКОВА

PRESSA



# Безнең тышлыкта

*«Алга барыр өчен янәшәңдә рухландырып торучылар, «син булдырасың», дип әйтүчеләр кирәк. Яшьләргә бигрәк тә»*



8 «Кешеләрне яратам...»
Чулпан Галиәхмәтова

20

«Һәркемнең матур сыйфаты бар...»
Чулпан Галиева

24

«Ватаным Татарстан» аңлата
Чулпан Галиәхмәтова

28

Күңел күзе ул – фәлсәфә
Эльмира ЗАКИРОВА

## ЭЧТӘЛЕК


### Заман һәм без

«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы»-2022 — 6

«Тормыш мине чыбыркылап куа» — 12
Алсу Шакирова

Әни — 16
Гөлнур Сафиуллина

Туган җанлылык — 31
Вәсилә Сафиуллина

### Мәдәни тормыш

Сандугачтан моң алып... — 46
Рәсимә Гарифуллина

Без бүген – якты яз! — 47
Илмира Гыймаева

Өч монолог — 48
Гүзәл Әдһәм

Әдәбиятта юаныч табам... — 53
Айдар Шәйхин

### Яшәеш

Безнең почта — 54

### Хуҗабикә

Сорау—җавап — 56

Эшлекле этикет — 58

Күзләргә макияж — 59

Грушалы десерт — 62

Ефәктәге сәнгать — 64
Зилә Нигъмәтуллина

34



Татар дөньясы


Без – Күңгәрнеке!
Лилия Гәрәева

42



Нәселебезнең йөзек кашы
Марс Гаитов

60



Катлама
Альбина Фәсхиева тәкъдим итә



**Зилә ВӘЛИЕВА,**
**Татарстан Республикасының Иҗтимагый палата рәисе, «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе**















«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы». Әлеге республика бәйгесенең исемен әйтү генә дә җитә: һәр яктан булган, эшлекле, талантлы, игелекле хатын-кызларыбызны күңелдән уздырам. Күп алар! Һәр елның үз геройлары: яңа исемнәр ачабыз, уңышлары, талантлары, фидакарьлекләре, олы йөрәкләре белән шаккаттырган ханымнарга, кызларга сокланабыз.

Ә бүгенге җәмгыять тормышында хатын-кызлар үзенә бер аерым урын алып тора, чөнки илдә барган вакыйгалар, зур сынаулар, дөнья гаме хатын-кыз җилкәсенә дә төште. Быелгы «Ел хатын-кызы» – кемнәр алар? Ирләрен, улларын хәрби операциягә озаткан, исән-сау кайтуын өмет белән көткән аналар. Махсус хәрби операция башлануга сугышчыларга ярдәм оештырып йөргән волонтерлар. Кичләрен җыелып җылы оекбашлар, бияләйләр бәйләгән, маскировка өчен челтәрләр үргән апалар... Һәр эштә булышырга әзер торуларында да, көтә белүләрендә дә илне, балаларны яшәтергә омтылыш, өмет көче чагыла.

Зона турлары тагын яңа шәхесләр ачты. Әнә, авыру балаларны тернәкләндерү үзәге рюкзаклар, термокиемнәр тегеп, бу эшкә үз өлешен керткән. Азнакайлар хәрби операциядә катнашучыларга адреслы посылкалар, гуманитар ярдәм итеп азык-төлек, көнкүреш товарлары, медикаментлар җибәргән. Киң җәмәгатьчелеккә таныш булмасалар да, үз районнарында, шәһәрләрендә алар дөнья тоткасы.

Тәтештә узган зона этабында бер ханым «Хатын-кыз – ана» номинациясенә әзерләнеп килгән. Күп балалы әни ул: балалары арасында тәрбиягә алганнары да бар. Ләкин ул... сәхнәгә чыкмады. Күз яшьләрен йотып: «Ике атна инде улымнан хәбәр юк», – дип өзгәләнде. Әниләр йөрәге шундый шул инде! Тәрбиягә алынган бала булса да, Ана йөрәге газиз улым диеп яна!

50 еллык юбилеен билгеләп үткән Бөгелмә тегү фабрикасында 45 ел тегүче булып эшләгән Мария Кудряшованың бөтен язмышы исә шушы оешма белән бәйле икән. «Язмышым – һөнәрем» номинациясендә чыгыш ясаган бу булдыклы ханым – көнгә 50–60 кышкы костюм теккән уңганнарның берсе, ә фабрика күптән туган өенә әйләнгән! Фабриканың йөзек кашы дип йөртәләр! Күп оешмалар, завод-фабрикалар таркалып юкка чыкканда, шундый осталары, һөнәрчеләре булганга яшәп калган бу берләшмә. Алар теккән киемнәр хәрби операциядә катнашучыларны да җылыта. Мондый булган, тырыш, олы йөрәкле хатын-кызлар белән ничек горурланмыйсың да, ничек җиңүгә өмет белән яшәмисең!







Фотолар: «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы архивыннан.



**Гөлзадә РУДЕНКО,**
**Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы генераль директоры, Россиянең һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия музейлар президиумы әгъзасы**

Бу искиткеч бәйге Татарстан Республикасының социаль-икътисадый, мәдәни һәм рухи үсешенә, үсеп килүче буынны тәрбияләүгә, гаилә институтын ныгытуга зур өлешен кертүкән дистәләгән затлы, зыялы хатын-кызлар белән таныштыра.

Барлык катнашучы гүзәл затлар да – төрле өлкәләрдә үзен тапкан, әйләнә-тирәсендә абруй казанган шәхесләр, алар эшләгән урыннарында зур уңышларга ирешкәннәр. Безнең бәйге аларга киң җәмәгатьчелек алдында үзләрен күрсәтергә, талантларын ачарга, ә кемгәдер киләчәктә үсеш өчен яңа танышлар булдырырга мөмкинлек бирә.

Иң мөһиме – без матур, талантлы, эш сөючән һәм уңышлы хатын-кызлар турында гына сөйләшмибез. Катнашучыларны бәяләгәндә аларның тормыш кыйммәтләре, әхлакый нигезләре, гомумән, эчке рухи дөньялары әһәмиятле критерий булып тора.

Быел әлеге бәйге 26 нчы тапкыр үткәрелә инде! Әмма кызыксыну һаман арта гына бара. Конкурска ихтыяҗ зур, анда төрле яшьтәге кешеләр катнаша. Киләчәктә дә шулай дәвам итәр дип ышанам.



**Эльвира ГАЛИЕВА,**
**Татарстанның Азнакай район советы оештыру бүлеге җитәкчесе, «Азнакай шәһәре һәм Азнакай районы хатын-кызлар советы» коммерцияле булмаган оешма рәисе**

Конкурс хатын-кызның чын асылын ачып бирә. Матурлык, наз таратучы һәм иң гаҗәеп сыйфатын – кешелеккә тормыш бүләк итүче буларак күрсәтә. Бу нәфис, нәзберек затларның язмыш сынауларына, авырлыкларга бирешмичә, аякта нык торырга, тагын да зур уңышларга һәм танылуларга ирешергә сәләтле булуын сурәтли. Бәйгедә катнашучы хатын-кызларның язмышы һәм характеры, аларның бәяләп бетергесез тәҗрибәсе, ихтыяр көче, һөнәри осталыгы, бөтен нәрсәдә өлгерлек күрсәтеп, үз тормышларын оештыра белүе башкаларга үрнәк булып хезмәт итә.

Хатын-кыз... Бары алар гына башкаларның иминлеге, уңышы өчен үзләрен, вакытларын кызганмыйча, эчкерсез күңел белән бөтен барлыкларын багышларга әзер! Быел хатын-кызларның бу сыйфаты бәйгенең барлык номинацияләрендә дә киң ачылды, һәм ул, гадәттәгечә, мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә, өлкәннәргә ярдәм итүдә генә түгел, махсус хәрби операциядә катнашучы үзебезнең егетләргә ярдәм итүдә дә чагылыш тапты. Мин үзем дә гуманитар ярдәм җыю һәм хәрби операциядә катнашучыларга, аларның гаиләләренә ярдәм оештыру эшендә әйдәүче-инициатор булып торам. Форсаттан файдаланып, үземнең фикердәш дусларыма ихлас рәхмәтемне җиткерәм.

Авыр вакытларда халкыбыз һәрчак берләшә, алгы сафка баса. Соңгы айларда бу сыйфат аеруча көчәйде. Безне туган илне ярату, тугрылык, бурыч хисе дәртләндерә. Бергәләшеп, иңне иңгә куеп кына Җиңүне якынайта, улларыбыз һәм ирләребезнең өйләренә кайтуын тизләтә алачагыбызны аңлыйбыз.

Еллар узып, заман таләпләре, карашлар үзгәреп торса да, хатын-кызның гүзәл сыйфатларын, рухи һәм физик көчен ачарга ярдәм итүче бу бәйге озын гомерле булсын дип телим!

























# «КЕШЕЛӘРНЕ ЯРАТАМ...»



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

**Минзәлә шәһәре уртасында урнашкан «Ялкын» яшьләр үзәге гөрләп тора. Балалар да, яшьләр дә, өлкәннәр дә килә. Аларны монда тыңлыйлар, аңлыйлар, ярдәм итәләр, үстерәләр, күңел ачтыралар. Җылылык булган җиргә барасы килеп тора бит ул. Үзәкнең директоры – «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең «Хатын-кыз – лидер» номинациясендә финалист Ирина МИХАЙЛОВА үзе дә кояш кебек. Бар кешене җылытырга теләп яшәгән Ирина Маркс кызы «кешеләрне яратам», «балаларны яратам» дигән сүзләрне еш кабатлый. Бу ясалмалылык түгел, чын күңелдән әйтелгән сүзләр. Аның җиңел булмаган язмышы да кешеләрне яратырга, аларга ярдәм кулы сузарга өйрәткән. «Мин булдыра алдым бит, димәк, сез дә булдыра аласыз, бары тик максат куярга кирәк», – ди ул яшьләргә.**

## Иринаның да язмышы бөтенләй башкача булыр иде. Ә ул бирешми...

### *«Хәрәкәт бар икән, димәк, үсеш бар...»*

Шәһәрнең Яшьләр үзәге ике ел элек яңартылган зур бинага күчкәч, «Веста» исемен «Ялкын»га үзгәртеп, эшчәнлеген тагын да куәтләндереп, ялкынландырып җибәргән. Элек кечкенә генә салкын бинада да яшьләрне җыярга тырышып эшләгәннәр. Әмма замана яшьләре искегә карамый, бары тик яңага, яңалыкка игътибар итә. 2020 елда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Яшьләр эшләре буенча министрлыкның инициативасына теләктәшлек күрсәтеп, яшьләр үзәкләрен яңартуга финанс бүлеп бирә. Республикада үзәкләр урнашкан биналар яңартыла. Заманча инфраструктурага яшьләр, билгеле, битараф кала алмый. «Безнең үзәк Минзәләдәге иң кәттә урыннарның берсе хәзер», – дип сөенә директоры Ирина Михайлова. Элек төрле чаралар үткәрергә бер тулай торактан икенчесенә йөрсәләр, хәзер яшьләр үзләре килә. Алар өчен төрле түгәрәкләр эшли, тематик, профилактик чаралар үткәрелә. Йөз урынлы заллары да бар. Яшьләр, тели икән, «Форпост» җәмәгать тәртибен саклау буенча оешмага кушыла, тели икән, рәсем сәнгате серләренә төшенә, тегәргә өйрәнә, актерлык сәләтен сыный, психолог белән сөйләшә. «Ярдәм кулы» дип аталган волонтерлык хәрәкәтләре дә бар. Ә хәзер волонтерлар ярдәме бигрәк тә кирәк. Хәрәкәттә йөздән артык студент, укучы тора.

– Хәзерге яшьләрне үз-үзен яратучылар гына, диләр. Һич алай түгел. Алар ачык һәм ярдәм итәргә әзер. Безнең үзәккә йөрүче волонтерларга соклануымны яшерә алмыйм. Алар вакыт үткәрү йә булмаса укуларында өстәмә балл алу өчен генә түгел, ә чын күңелдән йөри. Киләләр, ярдәм итәләр, бергәләп утырып чәйләр эчәбез, сөйләшәбез, киңәшләр бирәбез. «Безгә кешеләр белән аралашу ошый», – диләр. Монда яңа дуслар табалар. Үзәкнең төп бурычы да яшьләргә үз юлларын табарга ярдәм итү бит, – дип сөйли Ирина.

Үзеннән белә, алга барыр өчен янәшәңдә рухландырып торучылар, «син булдырасың», дип әйтүчеләр кирәк. Шуңа да яшьләргә үсәргә мөмкинлек бирер өчен тырышалар. Патриотик тәрбия актуальләшкән чорда, бергәләп әлеге темага спектакльләр куялар. Премьералары хәтта шәһәр театры бинасында узган. КВНнар, тематик чаралар, төрле батллар үткәрәләр, җырлыйлар, бииләр. Тынгысыз директор яшьләр өчен нәрсә булса да уйлап табып кына тора. «Хәрәкәт бар икән, димәк, үсеш бар», – ди ул.

Үзеңнең кирәклегеңне белү яшәргә көч бирәдер, мөгаен. Берәү дә үзен кирәксез итеп тоярга тиеш түгел. «Умырзая» тернәкләндерү үзәгендә тәрбияче булып эшләгәндә күргән балалар тынгылык бирми Иринага. Үзәккә чакырып, алар өчен бәйрәмнәр, төрле мастер-класслар үткәрә башлыйлар. Хәзер инде ул балалар – җиткән егет-кызлар. Яшьләр үзәгеннән кала, башка барыр урыннары да юк. Махсус алар өчен «Эшләми торган яшьләр» клубы оештырганнар. Утызлап кеше йөри. Ирина һәрберсе хакында сәгатьләр буе сөйли ала кебек. Тормыштагы кечкенә генә җиңүләре өчен дә чын күңелдән сөенә. «Барысы да туганнарыбыз кебек якын. Алар монда килгәч, ачылып китә, шуны күреп бик куанабыз», – ди. Иң мөһиме – егет-кызлар үзәктә бер-берсе белән аралаша, шушында йөрәк дусты табулары аеруча шатландыра.

Хәзерге яшьләргә үз-үзләрен табарга күп мөмкинлекләр ачылуына куана Ирина. Үсмерләр, яшьләр беркемгә кирәкмәгән чор да булды. Узган гасырның 90 нчы елларын бик яхшы хәтерли ул. Минзәләдә генә түгел, барлык шәһәрләрдә яшьләрнең җыелу урыны – пычрак подъездлар, өметсез киләчәк, хәерчелек... Бик күп яшьләр нәнә шул вакытта адашып калды. Максат куеп, тормыш баткаклыгыннан чыгарга теләүчеләр бары тик тырышлыклары, юлларында очраган изге күңелле кешеләрнең ярдәме белән генә үз юлларын таба алды. Иринаның да язмышы бөтенләй башкача булыр иде. Ә ул бирешми...

### *«Син безнеке түгелдер...»*

Минзәләнең гап-гади бер гаиләсеннән ул. Әтисе тракторчы, әнисе санитар булып эшли. Биш бала арасында Ирина иң кечкенәсе. Тормышлары авыр, юклык... Хәер, 90 нчы елларда күндәм генә башын күтәрми эшләп тә, хезмәт хакы ала алмаган гади халыкның күпчелеге хәерчелек хәлендә яшәде. Әмма Ирина киләчәгенең якты булачагына ышана, ул бу хәерче тормышка баш иеп яшәргә җыенмый. Гаиләдә бер укыган кеше булырга тиеш бит инде! Курчагын утыртып куя да, иске шифоньер ишегенә акбур белән яза-яза, аны «укытырга» ярата кыз. Һичшиксез укытучы булачак ул! Мәктәптә яхшы укый, активист. Һәрвакыт үзеннән акыллырак кешеләргә тартыла. Сыйныф җитәкчесе Татьяна Беспаловага әле дә рәхмәтле. Өенә барып, чәй эчә-эчә укытучысы белән сөйләшеп утыру кызны рухи яктан үстерми калмый. Бик тә укытучысына охшарга тырыша. Тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, Минзәлә педагогика көллиятенә имтиханнар бирә, әмма баллары җитми. Түләп укытырга әти-әнисенең мөмкинлеге юк. Гарьлегеннән елый кыз. «Башыңны катырма әле, нигә кирәк соң ул укытучы һөнәре?! Әнә пешекче йә тегүчелеккә бар, умартачы булырга укы», – ди әтисе. Юк, бирешми кыз. Мәктәптә тагын да тырышып укый һәм хыялын чынга ашыра. Көллияттә югары стипендия ала. «Катнашмаган бер чара калмады. Миңа һәрвакыт хәрәкәттә булу кирәк иде», – дип искә ала Ирина. Тынгысыз, максатчан кызына карап: «Син безнеке түгелдер», – дип соклана әтисе. Әйе, аларның зур горурлыгы була ул.

«Син кая барасың?» – дип сорыйлар кыздан көллиятне тәмамлагач. «Директор булам, юкка укыдыммы әллә мин», — ди ул юллама бирү буенча комиссия әгъзаларына. «Директор булырга иртә әле сиңа, Әлмәткә барып, мәктәптә укытып кара», – диләр аңа. Иринаның егете армиягә китә, үзе нефтьчеләр шәһәренә күченә. Мәктәптә өстәмә сәгатьләр дә ала яшь белгеч, кичләрен Хәрби хезмәт һәм хәрби-патриотик тәрбия бирү үзәгенең тирында да эшли. Эшсез утырырга яратмый. Аннан соң әти-әнисенә

Фото: Темине Мкртчян

PRESSA



## Хәзерге яшьләр өчен күп мөмкинлекләр ачылды.

дә ярдәм итәсе, киемнәр аласы да бар. Бик тә матур итеп киенергә ярата шул кыз. Шуңа да җәйләрен ял иткәнен хәтерләми дә. Йә идән юа, йә кирпеч заводында эшли.

Тирда эшләгән вакытта аны үзәкнең директоры күреп ала да эшкә чакыра. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укытырсың, ди. Тәвәккәлли Ирина, мәктәптән китә дә, үзәккә урнаша. Ә анда бөтенләй башка атмосфера! Хәрбиләр, төгәллек, хәрби устав хакимлек итә... Анда эшләү үтә дә кызыклы була аңа. Эш тәҗрибәсе, яңа сыйфатлар туплый: таләпчәнлеккә, дисциплинага өйрәнә. Ярты елдан Иринаны тәрбия эшләре буенча завуч итеп куялар. Канатланып эшләп йөргәндә Женя армиядән кайта. Әлмәткә килү турында ишетергә дә теләми ул. Кыз бөтенесен ташлый да, булачак ире янына кайтып китә. Минзәләдә мәктәптә урын булмый, ә яшәргә кирәк. Бер эштән дә курыкмаган Ирина кибеткә сатучы булып урнаша. Бер дә ошамый аңа яңа эше. Бернинди үсеш булмаячагын аңлый, тынгысыз җанына һава җитми кебек. «Умырзая» тернәкләндерү үзәгенә эшкә урнаша, аннан






соң кинотеатрга методист булып күчә. Монда да тыныч кына эшли белми. Тематик кино күрсәтер алдыннан мәктәп укучылары өчен төрле чаралар үткәрә башлый. Тырышлыгын күреп, «Веста» яшьләр үзәгеннән җитәкләргә чакыралар. Директор булам дигән хыял чынга ашарга тора, ә Ирина... куркуга кала. Әнә шул чакта үсендерер кеше кирәк шул. «Син булдырачаксың, ризалаш», – ди кинотеатр директоры Рәзилә Мәзһәровна. Бер ай сынау вакыты белән эшкә алалар. Сынатмый Ирина! Иске генә бинада урнашкан үзәкне яңа директор җанландырып җибәрә. Идеяләре күп, әмма аларны ялгызы гына тормышка ашыра алмый директор – коллектив кирәк. Элек бергә эшләгән хезмәттәшләре әкренләп янына җыела башлый. Ныклы, ышанычлы, эштән курыкмый торган коллектив туплый ул. Ирина һәрвакыт «без» дип сөйли. Менә инде 13 ел җылы атмосфера тудырып, бер гаилә кебек эшлиләр. Бер-берсенә карата хөрмәт сизелә ул коллективта. «Коллективым булмаса, бер идея дә чынга аша алмас иде. Кызлар белә: эштә хилафлыклар булса, мин бик коры җитәкче, ә инде берәр борчу килә икән, иң элек үзем ярдәмгә барачакмын», – ди Ирина.

Һәр җәйне үзәк базасындагы «Олимпиец» спорт лагеренда уздыра ул. Югыйсә җаваплы кешене дә билгеле ала. Әмма Иринаның үзенә лагерь тормышына катнашырга, барысыннан хәбәрдар булырга кирәк. Ышанмау дигән сүз түгел бу, балалар янында үзенә рәхәт. Кызыксынучан табигате дә читтә калырга ирек бирми. Олы малае Даниэль дә лагерьда үсә, өч айлык кечкенә улы белән дә лагерьга китә. Әйе, бала карау ялына чыкмый ул. Яңа үзәк ачыларга торганда ничек тыныч күңел белән өендә ятсын?! Югыйсә икенче улларын 15 ел көтәләр. Берничә кат операция кичереп, уңышсыз ЭКО узып, инде өмет өзелде дигәндә, Аллаһы Тәгалә аңа икенче бала бүләк итә. Шушыннан соң ничек Аллаһының барлыгына ышанмыйсың?! Шуңа да ислам дине кануннарын саклап яшәргә тырышалар.

Улына алты ай булганда эшкә чыга. «Бәлки өйдә утырырсың?» – дип карый ире. Юк, өйдә күңелсез аңа, хәрәкәт, аралашу җитми. Әмма үзен начар әни дип санамый Ирина. Балалары куандырып үсеп килә. Олы улы Чаллыда төзелеш көллиятендә белем ала. Әтисе кебек төзүче булырга хыяллана. Таирына инде 3 яшь. Кая гына барса да үзеннән калдырмый аны Ирина. Әле бергәләп Җиңү парадында катнашалар, әле волонтерлар белән кайнашалар. Бик мөстәкыйль бала булырга охшаган. Ире кайчак: «Эшеңне күбрәк яратасың», – дип әйтсә дә, Ирина белә: ул аның белән горурлана. Хатынының кызыксынучан, аралашучан, һәрвакыт үсештә булырга теләгән тынгысыз җанын күптән кабул иткән инде. Гаилә тергән тоймаса, тыныч күңел белән эшли, яңа идеяләр белән яна алыр иде микән Ирина?! Әле Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтында читтән торып икенче югары белем ала. Ландшафт дизайны серләрен өйрәнә. Аңа кызык! Кабат яңа идеяләр! Яшьләр үзәге бинасы тирәсен гөлбакчага күмәргә ниятли хәзер.
Күп идеяләрен тормышка ашырырга ярдәм иткәне өчен район башлыгы Айдар Фәслахович Сәлаховка рәхмәтле.

Теләктәшлек күрсәтеп, канатлар куя белгән җитәкче ул. Шуңа да үзенә тапшырылган һәр җаваплы эшне җиренә җиткереп башкарырга тырыша Ирина.

### *«Без булмасак, кем?..»*

Узган ел илдә килеп туган вазгыять беркемне дә читтә калдырмады. Гомумән, тарихтан күренгәнчә, Россия халкы авырлык килгәндә берләшә белүе белән аерылып тора. Бүген безнең буынга кабат бердәм булу бурычы килеп басты. Битараф булмаган халык ил куркынычсызлыгын саклау өчен махсус хәрби операциягә мобилизацияләнгән егетләргә, хәрби хәрәкәтләр барган урыннарда яшәүчеләргә ярдәм кулын сузды. Татарстанда да «Ярдәм янәшә! Помощь рядом!» хәрәкәте булдырылды. Шунысы куанычлы: ярдәм итәргә теләүчеләр бик күп. Минзәлә районында «Ялкын» яшьләр үзәге базасында узган елның октябрь аенда штаб төзелә. Район буенча җыелган ярдәм шушында тупланып, егетләргә җибәрелә. Минзәлә артык зур түгел. Бары 27 мең кеше булган район халкы күршесенең, танышының хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан улына ярдәм итүне үз бурычы итеп кабул итә. Шуңа да битараф калмаганнар күп җирлектә.

Штаб җитәкчесе итеп билгеләнүгә, Ирина район делегациясе белән бергә Казанда танк училищесы базасында өйрәнүләр узган мобилизацияләнгән райондашлары янына бара. Шунда янына бер егет килә дә, Минзәләгә кайткач, әнисе янына барып килүен сорый. Кайтуга ук Люба апа янына ашыга Ирина. Аның белән дуслашып китәләр. «Бер шимбәне бара алмаган идем, өеннән дә чыкмый мине көткән. Люба апа миңа хәзер туганым кебек якын», – ди Ирина. Ярдәмнең бит әле мондые да кирәк. Күңел хакы хәзерге вазгыятьтә дә онытылмый. Өйдән посылка алу мөмкинлеге булмаган егетләрне барлап, аларга исемле посылкалар җыеп җибәрәләр штабта. Ризык, кирәк-ярак кына түгел, хат та язып салалар. Нәкъ өйдән килгән кебек булсын дип тырышалар. «Башкалар посылка алганда нәүмиз булып калмасыннар», – ди Ирина.

Район штабына аерым кешеләрдән дә, хезмәт коллективларыннан, предприятие һәм оешмалардан, авыл җирлекләреннән, шәхси эшмәкәрләрдән бик күп гуманитар ярдәм килә. Яшьләр үзәгендә киберкабинет вакытлыча склад итеп җиһазландырылган. Анда нәрсә генә юк: азык-төлек, шәхси гигиена кирәк-яраклары, киемнәр, окоп шәмнәре, «буржуйка»-мичләр... Минзәлә районы барлыгы 18 тонна гуманитар ярдәм җыеп җибәргән. Эшмәкәр Светлана Степанова әнә Луганск өлкәсенә барып бер атна госпитальдә эшләп тә кайткан. Минзәлә халкы җыйган ярдәмне район егете Эдуард Гаффаров илтеп тапшыра икән. Үзләреннән киткән егетләр, аларның командирлары белән элемтәдә торалар.

Яшьләр үзәгендә тегү цехы да ачып җибәргәннәр. Башта волонтерлар тегү машиналарын үзләре алып килсә, соңрак үзәк грант буенча ике тегү машинасы ота, район хакимияте оверлок сатып алып бирә. Районнан мобилизацияләнгән һәр егеткә 120 литрлы «вещмешоклар» тегеп тапшыралар. Йокы капчыклары тегә башлаганнар. «Волонтерлар арасында, нигездә, яшьләр. Илдәге вакыйгалар патриотизм хисләрен уятып җибәрде кебек. Алар дәүләткә килгән авырлыкны аңлый, ярдәм итәргә тырыша», – ди Ирина. «Солдатка хат» Бөтенроссия акциясенә дә кушылганнар. Мәктәп укучылары һәм студентлар хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларга җылы хатлар яза. Рух ныклыгы өчен җан азыгы да кирәк бит әле. Ирина гаилә башлыклары мобилизацияләнгән гаиләләргә дә барып йөри. Берсе дә игътибарсыз калырга тиеш түгел, ди ул.

– Халык, чынлап та, берләште, – ди Ирина. – Хакимият белән дә аңлашу бар. Үз гомерләрен куркыныч астына куеп, ил тынычлыгын саклаганнарны кайгырту уртак эшебез булуын барыбыз да аңлыйбыз. Бу вазгыятьтә читләр кайгысы була алмый. Халык менә шуны аңлап, ярдәм итәргә алынды. Ә без булмасак, кем ярдәм итәр?! Анда бит безнең егетләр...



**Айдар СӘЛАХОВ,**
**Минзәлә муниципаль районы башлыгы**

Республикада гамәлгә ашырылган яшьләр үзәкләрен яңарту программасы районда заманча матур бинада яшьләр белән эшләү мөмкинлеген бирде. Интерактив киңлекләр, инфраструктура белән җиһазландырылган функциональ зоналарда яшьләргә төрле башлангычлар өчен шартлар тудырылган. Үзәккә килгән һәркемнең уңышка ирешер өчен реаль мөмкинлеге бар. Безнең Үзәк төрле юнәлешләрдә эшли. Районыбызда яшьләрнең күпмилләтле булуын искә алып, Татарстан халыклары Яшьләр Ассамблеясенең төбәк вәкиллеге булдырылды.

Махсус хәрби операция кысаларында мобилизация игълан ителгәч, районда штаб оештырылды. Гуманитар ярдәм эшчәнлеге Яшьләр үзәге базасында алып барыла. Аның җитәкчесе итеп Ирина Михайлова билгеләнде. Шулай ук районда мобилизацияләнгәннәр өчен кирәкле әйберләр җыю буенча волонтерлар төркеме дә эшли. Штаб районда дәүләт мәнфәгатьләрен яклаганнарга ярдәм итүдә битараф булмаган һәркемне берләштерде. «Донна Роза» кибетендә һәм Яшьләр үзәгендә «вещмешок», патрон сумкасы, «пятиточечник»лар, йокы капчыклары тегү буенча производство оештырылды. Бик күп оешмалар Бөтенроссия хәрәкәтенә кушылды һәм безнең егетләр өчен маскировка челтәрләрен үрә башлады.

Шәһәрнең шәхси эшмәкәрләре махсус хәрби операция зонасында булганнарга «буржуйка»-мич, аяк киеме киптерү җайланмасы әзерли. Ярдәм акциясенә авыл җирлекләрендә яшәүчеләр дә кушылды. Алар ярдәме белән госпитальләргә, хәрбиләргә чәкчәк, өй токмачы җибәрелде. Моннан кала, штабка йон оекбашлар, озак саклана торган продукцияләр китерәләр.

Районда шулай ук Татарстан Республикасы шефлыкка алган Лисичанск шәһәренә дә ярдәм оештырылды. Һәр мобилизацияләнгән райондашыбызга адреслы посылкалар җибәрелде. Минзәләлеләр җыйган гуманитар ярдәм якташларыбызга барып җитте. Алар бик рәхмәтле!

# «ТОРМЫШ МИНЕ ЧЫБЫРКЫЛАП КУА»





Алсу ШАКИРОВА

**– Икенче сыйныфта укый идем... Язгы ташу вакытында мәктәптән кайтышлый классташ дустым Света белән елгада бутыйларны юарга булдык. Светаның бутыена абындым да, елгага агып киттем. Ярый әле портфелем булган, шуның өстенә ятып йөзеп барганда бер апа күреп алып, әллә сәнәк, әллә тырма белән мине елгадан тартып чыгарды. Аварияләргә эләгеп тә исән калдым... Өметсез тоелган сынаулардан да җиңел чыктым... Аллаһ мине гел саклап йөртә. Бәлки, минем берәр изгелек эшлисем бардыр, дим...**
**Теләче зонасында «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесендә «Хатын-кыз – лидер» номинациясе җиңүчесе Гөлнара ЭРКАЕВАны язмыш балачактан ук чыныктыра шулай.**

К – Кич чыгарга әзерләнәбез. Әби әнә шундый вакытта эш таба да тора. «Печән киштәлисе бар, әйдәгез, тиз генә эшләп кайтыйк та, мунчада юынып кич чыгарсыз аннары», – ди. Эшне тәмамлап кайтканда кич чыгарлык түгел, юынырлык та хәл калмый. Өстәвенә, соң була инде. Әбинең шул вакыттагы зирәклегенә тора-тора шаккатам. Чыкмыйсыз да дими, бернидән тыймый да, ләкин үзенчә шулай безне саклый. Иң якын сердәшчем иде ул минем. Кич үзем ошатмаган берәр егет озатса, өйгә тизрәк кереп китәр өчен, капка келәсен бер-ике тапкыр кагып, әбигә хәбәр бирәм. «Сәгатьнең ничә икәнен беләсеңме син? Кайтыр вакыт!» – дип, әби мине эзләп чыгып җитә. Йокламыйча, миннән сигнал көтеп утыра иде шулай. Яшь вакытта ындыр табагында эшләргә кызыгабыз! Анда урак өстендә яшьләр кич тә, төнлә дә эшли, ләкин мине әби җибәрми. «Шуклыгың да бар, чаялыгың да... Әниең кебек 18 яшеңдә кияүгә китә күрмә тагын», – ди. Аңлаган инде ул, егетләр дә, ирләр дә бар бит анда... Өстәвенә, әбинең әни өчен дә үкенгән чагы булмый калмагандыр. Әни, авылга килеп эшләүче үзбәк

егетенә яшьли кияүгә чыгып, Үзбәкстанга китеп бара, – ди Гөлнара.

Гөлнара шунда туа. Әтисе белән әнисе килешеп кенә яшәп китсәләр дә, иренең туганнары белән уртак тел таба алмый әнисе Нурания апа. Сабырлыгы калмагач, кызы белән туган ягына кайтып китә. Ләкин ире артыннан килә һәм... Гөлнараны урлап кире Үзбәкстанга китә. Ананың кызы артыннан бармый чарасы калмый. Уллары туа, әмма тормыш барыбер җайланмый.
Бу юлы Нурания апа ике баласы белән бөтенләйгә дип кайтып китә. Ире дә башка артыннан эзләп килми.

– «Әни, нигә сабыр итмәдең? Без дә әтиле булыр идек», – дип, әнине рәнҗеткән вакытларым булды. Әтине күрәсе килеп, үскәч Үзбәкстанга да бардым әле. Аның күзләренә карыйсым килде. Таптым

Җәй буе авылда, Нәкыя әбисе янында үскән кыз әби тәрбиясе җимешләрен мулдан татый. Бик зур байлыгы – тегү машинасы да була әле Нәкыя әбисенең. Гөлнарага ничә күлмәк тегеп кидергәндер! Гөлнара гына, малайлар сыман койма башыннан йөреп, һәр яңа күлмәкне ертып кайта торган булган. «Әби, теккәндә үк берәр җирен ертык итеп тек шуның, барыбер умырып кайтам», – дия торган булган кызый үзе дә. Чыгарылыш кичәсенә күлмәкне әбисе өйрәтүендә үзе тегә инде ул. Нәкыя әбинең сандыгында «модалы» ефәк тукыма да табыла. Чын ефәк булмаса да, бик матур күлмәк килеп чыга бит! Тегеп киясе килү теләгеннән түгел, сатып алырга мөмкинлек булмаганнан тегелсә дә, шул беренче хезмәт җимеше, тегелгән тигез җөп юлы кебек, булачак һөнәренә беренче эзләрен сала. Ничек тә авылда

ка җиргә керә алмаганга, әтиәниләре кертеп урнаштырганга гына килеп эләккәннәр. Ә синдә талант күрәм, кал», – диде Наталья Николаевна. Шул вакытта мине тотып калганы өчен бик рәхмәтлемен остазыма. Тегүче белгечлеге алгач, кисүчегә укырга да җибәрде әле ул мине. Аннары инде Балтачка – ательега эшләргә кайттым.

Ательеда озак эшләми Гөлнара. Моның өчен әле дә үкенә ул. Әллә нинди бормалы юллар белән булса да, язмыш барыбер шул тегү машинасы артына утыртачак әле аны, ләкин яшь күңелне бәйләп тә тотам димә. Ашлык, бәрәңге, Маридан алып кайткан бройлер чебиләре сату белән кәсеп итү дисеңме – берсе дә калмый.

– Ул чебиләрне алып кайтканда булган бер кызык хәлне әле дә искә алып көләм. Чеби алырга дип башка-








этине. «Әниеңне гомерем буе яраттым, синең белән кайтып китәм», – дигән иде, тик минем күңелем кайтты... Без инде энем белән үстек, аякка бастык. Ә аның яңа гаиләсе, 5 яшьлек бәләкәй улы бар. Шул баланы уйлыйсы урынга, ул безнең янга, зур балалары янына кайтып китмәкче. «Син хәзер менә бу балага кирәк, безне ташлаган кебек, аны калдырма», – дидем. Шул гомер яшәп, әтинең анда берние юк иде. Хатыны да гел зарланып елады. Аны да бәхетле итә алмаган. Кайткач, әнине кочаклап, гафу үтенеп еладым... Дөрес эшләгән әни.

калмаска дип, Гөлнара Казандагы һөнәр училищесына тегүчелеккә укырга керергә уйлый. «Син түзә торган эш түгел ул!» – ди Нәкыя әбисе. Зирәк карчык баланы ничек үсендерергә кирәген белә шул. Гөлнарага әнә шул гына кирәк! Исбатламыйча туктамый. Укырга да керә.

– Шәһәр кызлары безне кыерсыттылар инде... Татарча сөйләшергә дә кушмыйлар. Укытучыма зарландым. Булмый миннән, авылга кайтып китәм, сыер савармын, дим. «Гөлнара, башкалар барысы да китеп бетсә дә сүзем юк, алар монда баш-

лар «ГАЗель» машинасы белән килә, мин «Ока» белән (машинаны да Нәкыя әби «кызыл кар яугач алсаң гына инде», дигән була оныгына – *А. Ш.*)! Ничә генә чеби сыя иде инде ул машинага... Иптәш кызым белән чебиләрне төяп, акрын гына кайтып киләбез. Вакыт-вакыт туктап, салонда һава алыштырып, астагы чебиләрне – өскә, өстәгеләрен аска күчерәбез. Арасында үлгәннәре дә була, аларын чүп контейнерларына атып калдырабыз. Берсендә кузгалып киттек шулай, бик акрын гына барабыз. Арттан килүче машина фаралары белән миңа сигнал бирә.



PRESSA



# Бераз кыркып китүчеләр дә бар, ә мин тагын да купшырак булып үсәм!

Куып җитте дә, тәрәзәмне төшерергә ишарәли. «Машинаң артыннан бер чеби чаба», – ди. Булмагае, көлә инде бу миннән, дим, ышанмыйм. Ярар, ярар, дигән кебек кул селтәдем. Аннары көзгегә карасам, чыннан да, машинам артыннан зур-зур атлап бер бройлер чебие йөгерә. Үлгән дип калдырганнары арасында ялгыш ташланганмы, һавага чыккач җан кергәнме, бездән калыр исәбе юк, арттан теркелдәвен беләә! – дип көлеп искә ала шул күренешне Гөлнара.

Аннары энесе, сеңлесе белән бергә (әнисе Нурания апа яңадан кияүгә чыга, тагын бер малае һәм кызы була) Казан яуларга чыгып китә. Әлеге дә баягы шул бәләкәй «Ока» машинасына утырып, мавыктыргыч шәһәр тормышына баштанаяк чумарга була исәпләре. Ләкин язмышның алдан корылган план буенча Гөлнараны бердәнбер мәхәббәте белән очрашуга алып чыгып китүе була бу. Казан урамы уртасында машинаның кайнап чыгуы да, тосол урынына салырга дип, су эзләп якындагы кафега керү дә, кафе ишегендәге «официантлар кирәк» дигән игълан да... Берсе дә очраклы булмый! Су сорарга кергән җирдән эшкә дә урнашып чыга Гөлнара. Шул ук көнне Казан аэропортына Баку шәһәреннән самолетта килеп төшкән азәрбайҗан егете Әкиф иртәгә бу кафега чәй эчәргә киләчәк. Дуслары белән утырган өстәлгә чәйне яшь официант кыз Гөлнара чыгара. Ләкин... кафе хуҗасы яңа хезмәткәргә табак-савыт юу вазыйфасын да йөкләргә уйлый. Гөлнара риза буламы соң инде моңа?! Казанга табак-савыт юар өчен килмәде сәнә! Өч көннән кыз инде икенче кафега китеп урнаша. «Кояшым, кая югалдың?» дигән смс-хәбәр килеп төшкәч, аптырап кала.

– Шул кафеда чәй эчкән көнне Әкиф мине ошатып калган. Анкетада күрсәтелгән телефон номеры буенча эзләп тапты. Икенче көнне үк «Америка горка»лары аттракционына алып барды, өченче көнне сиреньнән ары затлы чәчәкләр күрмәгән авыл кызы янына зур, матур, кыйммәтле чәчәк бәйләме белән килде. Бу кадәр игътибарны, җылы мөнәсәбәтне үз гомеремдә күргән юк иде. Авырып киткәч, түләүле клиникага алып барды, табибларга күрсәтте, бала караган кебек карады... Шуннан соң инде үзем дә аннан аерылырга теләмәдем. Авылга кайтып, кияүгә чыгарга җыенганымны әйттем, – ди Гөлнара.

Әнисе белән әбисе кызны ишетергә дә теләмиләр. Башка милләт кешесенә кияүгә чыгуның ни икәнен белгән Нурания апа аяк терәп каршы тора. Кияү буласы кешенең Гөлнарадан 22 яшькә олы икәнен белгәч, Нәкыя әбисе, кызны каршысына утыртып, үзе сөйләшеп карый. «Кызым, яшь аермагыз бик зур. Хәзер генә сизелми ул. Син алга таба йөгереп барырсың, ә ул синең арттан җайлап кына атлар», – ди.

– Алар хаклы да булганнардыр, әмма мин барыбер Әкифкә кияүгә чыктым. Кызганыч, парлы бәхетебез бик кыска гомерле булды. Сигез ел гына бергә яшәп калдык, ләкин бүгенге Гөлнара – тулысынча Әкифнең миңа биреп калдырырга өлгергән тормыш сабаклары, аның тырышлыгы нәтиҗәсе. Бүгенге бөтен уңышларымның юл башы – аннан. Мин үземне роза чәчәгенә тиңлим. Берәүләр минем тормышка ашлама булып килеп керә, мине тагын да үстерә. Икенчеләре бераз кыркып китә, ләкин аңа карап тагын да купшырак үсәм мин! Ирем, һичшиксез, тормышымдагы иң көчле ашлама булды, мине күп әйбергә өйрәтте. Алардагы балалар яратуны әйтеп аңлата торган түгел. Сүзгә килсәк тә, балаларга кагылышлы бәхәсләшү иде ул. Дөрес тотмыйсың, дөрес юмыйсың, дөрес ашатмыйсың... Бөтен нәрсәгә ул өйрәтте. Кызыбыз Сәмирә туып, ярты елдан соң гаиләбездә булган вакыйгаларның уңай чишелеше дә – тулысынча Әкифнең мәрхәмәтлелеге.

Сәмирәгә алты ай тулгач, язмыш Гөлнарага тагын бер сынау китереп тоттыра. Тоттыра шул! Кечкенә генә төргәкне үз куллары белән балалар йортыннан күтәреп чыга. Гөлнараның энесеннән авырга узган бер кыз, башта көмәнен төшерәм, дип әйтсә дә, соңыннан баланы тудырырга була. Ә тудыргач, аннан баш тарта. Кирәкми ул миңа, ди...

– «Бездә мондый хәл мөмкин түгел. Энең баланы ала алмаса, аны син тәрбияләргә тиеш. Үзе алырга әзер булганчыга кадәр», – диде Әкиф. Камиләне алып кайттык... Аны кабул итәргә ничек авыр булганын белсәгез! Өстәвенә, беркем дә хупламады бу адымны. Итәгемдә ике бала. Берсе – үзем тапканы, икенчесе – үз баламнан да якынрак күрергә тырышып баккан балам. Әкифнең ярдәме белән, аның киңәшләре белән үттем мин бу сынауны. Камилә бик талантлы бала! Кая гына йөртмәдем мин аны. «Йолдызлык» фестивалендә җиңү яулап, бүләк тун киеп кайтты бит ул! Хәзер Камилә үз әтисенең гаиләсендә яши. Камиләне алып кайту ничек авыр бирелсә, аның бездән китүе мең кат авыррак булды...

Әкифсез яшәгән гомере аның белән бергә үткәргән еллар санын күптән үтеп китсә дә, әле дә ул күрсәткән юл буйлап атлый Гөлнара. Үзе булмаса да, Бакуда яшәүче туганнары белән таныштырып, Гөлнараны да, кызлары Сәмирә, Айянаны да терәкле итеп китә Әкиф. Ике югары белем алган уллары белән янәшә гади тегүче кыз Гөлнараны түгел, башка бер затлырак, гыйлемлерәк кызны күрергә теләсәләр дә, беренче очрашуларында ук Әкиф Гөлнараның урынын билгеләгәли. Бер кырын караш та ташлаучы булмый килен ягына туганнары тарафыннан. Киресенчә, барган саен бүләккә күмәләр, акча җибәреп, ярдәм итеп торалар. Билет алып, кунакка көтәләр. Үз кызлары Сәмирә белән Айянага гына түгел, Камиләне дә калдырганнары юк. Туган көннәргә, Яңа елга гел бүләк килеп тора алардан.

– Әкиф үлгәч, туганнарына ел саен килеп йөрергә сүз бирдем. Машина белән әллә ничә тапкыр барып кайттым. Иске генә Лада-14 машинасы. Беләм, таможнядан иске машина белән үткәрмиләр. 250 мең залог калдырырга кирәк. Кая инде миндә ул кадәр акча? «Әфәнделәр, зинһар, кертегез, ун көнгә генә, балаларга әтиләренең каберен күрсәтергә алып барам. Бер көн дә артыгын тормыйм, кире чыгам. Ул кадәр акчам булса, мондый машинада йөрмим дә бит инде», – дип ялынам. Шунда таможняда эшләүче бер ир минем өчен шул акчаны үзе салды. «Нәкъ ун көннән кире чыгарга тиешсең», – диде. Шул таможня белән мәшәкатьләнеп, акчамны алыштырырга онытканмын. Чикне чыктык, ә миндә – сумнар. Бензин салырлык та җирле акча юк. Заправкадагы егетләр, хәлемә кереп, тулы бак бензин салып җибәрделәр бит! Кире чыкканда түләрсең, диделәр. Нәкъ ун көннән кире чыктык. Заправкадагы егетләргә дә, таможнядагы җитәкчегә дә рәхмәт әйтеп, түләп, күчтәнәч калдырып киттем. Юлымда шулкадәр яхшы кешеләр очрый минем! Әйтеп аңлата торган түгел...

Тегү мастеры Гөлнараны яңадан үз эшенә кайтару да тулысынча Әкифнең тырышлыгы. Сиңа үз һөнәрең буенча үсәргә кирәк, ди. Әле кайчан гына үзе теккән барлык костюмнарны күрсәтеп, зур бер бәйрәм уздыру, сәхнәне берсеннән-берсе матур, янып торган төрле милләт костюмнарына күмү хыялы белән яши иде бит Гөлнара. Инде бу хыялы да үзеннән-үзе тормышка ашты. «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесендә катнашканда аның кул эшләрен кигән балалар сәхнәгә түгәрәк уенга чыкты.

– Безнең Балтачта бик күп милләт яши. Нинди генә костюмнар текмәдем инде. Аны теккәнче башта тарихын өйрәнергә, китаплар укырга кирәк. Бер милләт бизәген, орнаментын икенчесенеке белән бутарга ярамый. Китапларны сатып та алам, китапханәдә дә эзләнәм, хореографлар белән дә киңәшләшеп эшлибез. Башка беркемдә булмаган киемнәр тегәргә яратам. Район мәдәният йортында узган концертларда, Сабантуй бәйрәмнәрендә үз эшләремне күреп горурланам. Даими клиентым, дустым Альбина Фәсхиева теләктәшлеге белән чигү машинасы алдым, эшне үзләштердем. Ул машина киемнәрне бөтенләй башкача баета, купшыландыра! Район җитәкчелеге дә ярдәм итә, үсәргә мөмкинлек бирә. Бер тегү машинасыннан башлаган эшемдә хәзер җиде машинка бар.

Махсус хәрби операция башлангач та районда мобилизацияләнгән егетләргә ярдәм кулын иң беренчеләрдән булып Гөлнара суза. Йокы капчыклары тегәргә алынганда үзенең өч бүлмәле фатирының бер бүлмәсендә башлап җибәргән эш калган бүлмәләргә дә кереп кунаклый. Тулы бер производство җәйгә салына шушы фатирда.

– Эшләп караган әйбер түгел, башта бер капчыкны сүтеп карадым. Шул ук көнне тукымалар алып кайтып, эшне башлап та җибәрдек. Капчык кына дисәң дә, эше күп аның. Башта берничә кеше генә ярдәмгә килде. Кичен эшләп утырганда сеңлем кереп видеога төшереп, социаль челтәрләргә куйган иде, бертуктаусыз халык агыла башлады. Нигә безгә дә әйтмәдең, дип үпкәләүчеләр дә булды. Туры җөй белән тегә беләм, бәлки файдам булыр, дип тә килделәр. Берәү кисә, икенчесе үтүкли, өченчесе тегә, берәүләр эчен тутыра... Конвеерга салынган кебек! Ничә капчык теккәнне санамадык та. Җитәрлек күләмдә тегелгәч, носилкалар тектек, аннары шәмнәр ясадык. Үземнең дә бер энем шунда бит...

«Хатын-кыз – лидер» номинациясендә җиңү яулаган Гөлнара Эркаева үзе тыйнак кына: «Нинди лидер инде мин?» – ди. Башкалар кебек тел осталыгым да, сәхнәдән сөйләү сәләтем дә юк, дип санап китә. Ләкин лидер моның белән генә билгеләнәме соң? Эшләрең, гамәлләрең синең турында кычкырып торганда... Изге эшкә тотынганда арттан иярүчеләрең булганда... Мәрхәмәтлелегең йөзләгән хәрбигә җитсә... Моны син генә булдырасың, дип, синең белән бер тапкыр эшләп караган кешеләр кире әйләнеп кайтса... Гөнаһсыз сабыйны үз кочагыңа сыйдырып, җылыңны бирә алсаң... Сине хөрмәт иткән кешеләр көн саен хәлеңне белергә килеп торса, юл өсте диеп кенә булса да кермичә үтмәсәләр...

Ә тормыш куаласын ул! Терәк булырлык әнисе, йөзгә җитеп килә торган зирәк әбисе исән-сау булганда... Җәелеп ял итәргә дә, мендәр кочып бер еларга да ирек бирмәсен! Авырлыкларның да, сайланып, көчле кешеләргә генә бирелүе хактыр...



■ Гөлнара кызлары (уңнан сулга) Сәмирә, Айяна һәм Камилә белән.

Фотолар: Ильяс Шәрипҗанов, Азамат Әхмәтҗанов

PRESSA



# ӘНИ



Гөлнур
САФИУЛЛИНА



– Нигә бирдең, Ходаем, бу хәсрәтне? Нигә нәкъ менә миңа?!.. Нигә… Аны ул чакта күрше Хөсни әби бүлдерә: «Бу сүзләрне башка беркайчан да әйтмә, балам… Димәк, Аллаһы Тәгалә шулай язган булган…» Күңелгә гомергә онытылмаслык итеп уелып кала бу киңәш. Әйтми! Ә әйтерлек очраклар тагын була әле аның тормыш юлында. Һәм бер генә дә түгел.

«Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесенең Әлмәттә узган зона турында таныштык без Гайшә ИЛЬЯСОВА белән. «Хатын-кыз – ана» номинациясендә җиңү яулады ул. Сәхнә түренә ул башта берүзе күтәрелде. Юк, ялгышам, янәшәдә – экранда улы да бар иде. Мараты! Яңа гына әнисе турында шундый җылы сүзләр әйтте ул аннан: «Сиңа ышанучы бер генә кеше булса да, алга атлыйсың. Ә минем андый кешем бар… Ул – әни!» – диде. Мараты… Юк, язмыш аннан «нигә» дигән сүзне улы белән булган очракта да ишетмәгән.

## Безгә иң күп ярдәм итүчеләрнең берсе – Ютазы элеваторының элеккеге директоры Гөлүсә Дәүләтшина.

### *Беренче очрак*

35 яшьтә тол кала ул. Кулында – берсеннән-берсе кечкенә өч бала. Өч мең ярым бурыч! Түбә астына гына кергән йорт... Беренче һәм соңгы тапкыр «нигә» дип әйтергә шул чакта талпына. Мәетне төн сакларга кергән күрше Хөсни әби бүлдерә аны... Бигрәк көтелмәгән, ачылардан-ачы хәсрәт була шул. Аңлап, кабул итеп, килешеп булмый торган. Иң авыры – күңелдәге мең сорауның берсенә дә җавап юк... Нәкъ бер атнадан – аяктан егарлык яңа хәбәр. Ирен җирләп җиде көн узуга, райпо директоры аны үзенә чакыра һәм: «Мөдәрисеңнең өч мең бурычы бар иде, түләргә туры килер», – ди. Бер чакыра, ике, өч... Бишенчесендә Гайшә түзми: «Түли алмыйм! Минем дә башымны элмәккә тыкканымны көтәсезме?! Юк, ул адымга бармам – балаларны үстерәсем бар!» – ди. Товаровед булып эшләгән иренә булмаган бурычны якканнар икән, ә ул, күрәсең, моннан котылу юлын тапмаган. Яңа өй җиткерергә дип болай да өч мең ярым ссуда алган еллары. Хезмәт хакы исә икесенең дә – сиксәнешәр сум... Директор ханым бер айдан соң гына бурыч турында искә төшерүдән туктый.

– Мин бу яңа борчуым турында ул чакта берәүгә дә белгертмәдем. Иремнең туганнарына да, балаларга да. Марат бу хакта дүрт ел элек кенә белде әле. Күңелләрендә кимгәдер карата ачу, үпкә саклап үсүләрен теләмәдем... Мөдәрис белән без мәктәптә укыганда ук очраша башлаган идек. Өч ел армиядән көтеп алдым мин аны. Тагын бер елдан соң өйләнештек, Ютазыда төпләндек. Һәм нибары унөч ел бергә яшәп калдык... Җанында нинди борчулар булганын сизмәгәнмен шул. Бер-беребезгә күтәрелеп карарга да вакыт булмаган чаклар бит: балалар кечкенә, юасы, җыештырасы, ял саен бианайга кайтып булышасы... Әгәр туганнарым булмаса, аны югалткач, сынар да, сыгылыр да идем. Мөдәрис дүртенче июльдә үлде, октябрьдә исә без яңа йортка күчендек. Үзе исән чакта түбәсен яптырырга гына өлгергән идек бит, ишек-тәрәзәсе дә куелмаган килеш калды. Миңсылу апа, Әдип җизни, Әминә сеңлем, Наил кияү, Хәмзә энем, киленебез Разия, туганнан-туганнар – барысы да булышты. Апалар атна саен Туймазыдан килеп йөрде, ипигә кадәр алып киләләр иде... Туганнар – бернинди акчага да сатып алып булмаслык байлык. Мин моңа инде кат-кат инандым. Балаларыма да бу хакта гел әйтеп торам...

Калган кешегә ничек тә яшәргә кирәк. Эштән кайткач, төннәрен йокламыйча, туйларга, бәйрәмнәргә тортлар пешерә. «Акча кирәкми, онын-маен, шикәрен генә бераз артыграк алып килегез», – ди. Тагын бер эшкә урнаша – идән юа. Күңелдәге авыр уйлардан шулай эш белән онытыла... Ул арада балалар кул арасына керә башлый: әйткәнне көтеп тормыйча, идән дә юалар, чиратлашып мунчага суын да китерәләр, тәрәз челтәрләренә кадәр үтүкләп элеләр... Син якыныңны югалттың дип кенә тормыш тукталып калмый – ул гел алга бара. Азаты мәктәпне тәмамлый, Мараты техникум дипломы алып, «Татнефть»кә эшкә урнаша, читтән торып Мәскәүдә укуын дәвам итә, Гөлназы да студент эскәмиясенә утыра...

### *Икенче очрак*

Гөлназы... Казан химия-технология институтының өченче курсында укыган чагы була аның. Яңа елларны өйдә каршылап, кышкы сессиягә дип, шәһәргә китеп бара. Һәм берничә көн үтүгә – телефон: «Әни, син курыкма, яме... Мин бераз пештем...» Бераз... Баргач кына күрә: кызы унбер җирдән пешкән, кечкенә җәрәхәтләренең исә исәбе-саны юк... Кызлар яшәгән фатирда иртәнге якта янгын чыккан, фатир хуҗасы үзе исән түгел, кызлар арасында иң авыр хәлдәгесе – Гөлназ...

– «Әни, син елама гына, яме», – ди... «Юк, еламыйм, кызым, исән икәнлегеңне күрдем бит инде», – дим. Һәм бер тапкыр да аңа күз яшемне күрсәтмәдем. Еласам, миңа берәр нәрсә булса, бу бала кем кулына кала дип уйладым... Кулларыннан тиресе перчатка салынган кебек кенә салынды бит... Янынннан бер минутка да китмәдем, беренче алты тәүлектә бер тапкыр урындыкка да утырмадым. Кешенең мөмкинлекләре чиксез икән аның... Сулыш ала алмый иде ул – күкрәгенә гел суккалап торырга кирәк. Әле кан басымы төшеп китә, әле температурасы... Андый чакта ана кешенең күзенә йокы керәме?! Аннан соң да ике урындык өстендә генә йоклап йөрдем... Беренче көнне үк кан кирәк, диделәр. 25 кешедән, диләр... Маратка шалтыратам: «Бөтен туганнарны җыеп килсәң дә, аның кадәр булмас бит, улым, нишлибез?!» – дим. Ютазы халкына мәңге бурычлымын: бездән килеп Казанда укучы студентлар, яшьләр кан бирде. Йөри торган егете, аның туганнары... 30 дан артык кеше кан тапшырды Гөлназ өчен!


Кырык көнгә якын хастаханәдә ятып кайта алар. Операцияләр кичереп... Ә аннан тагын да авыры башлана: янгыннан курку! Инде тәмам терелеп, укырга киткәч тә, төн уртасында берничә тапкыр Ютазыга шалтырата әле Гөлназ: «Әни, янабыз! Безнең йорт яна!»

– Икебезгә дә психолог ярдәме кирәк булгандыр инде ул чакта... Аңа да, миңа да. Бу хакта уйлый белмәгәнбез. Абыйсы белән булган фаҗига онытырды әлеге куркуын. Үзе турында уйларга вакыты калмагач кына курыкмый башлады Гөлназ. Әйе, 2006 ел миңа берьюлы ике хәсрәт алып килде. Кайгы ялгыз йөрми диләр, дөрес икән... Маратым...

### *Өченче очрак*

Мараты...

– Октябрь башы иде. Өйдә идән юып йөрим. Марат иртүк торып Уфага китте. Дустына документлар илтеп кайтырга кирәк икән. «Мин иптәшкә барам», – диде. Билетлар алынган, кичкә икесе дә Мәскәүгә чыгып китәргә тиешләр. Читтән торып Мәскәү ачык университетында укып йөргән чаклары... Кичкә каршы Алмаз исемле икенче бер дусты килеп керде: «Гайшә апа, борчылмагыз, яме... Маратлар авариягә очраган. Бәрелгәннәр бераз...» – ди.



## Маратны мәктәп дуслары ташламады, алар елга ким дигәндә өч тапкыр очрашалар.



2020 елда Марат Ильясов Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Президенты премиясе белән бүләкләнә.

Фото: гаилә архивыннан

Бераз... «Ашыгыч ярдәм» табиблары ук: «Муены сынган булырга тиеш», – диләр, һәм егетне Уфага алып барудан баш тартып, район хастаханәсендә генә калдыралар.

– Күзе ачыла да, авызы ачыла – калган бөтен гәүдәсе хәрәкәтсез. Температурасы кырыкка җитте. Үпкәсе җилсенде, баш мие шеште. Янында кулыннан тотып утырам, урыннан кузгалдыммы: «Әни!» – дип дәшә...

Районда 18 көн ятканнан соң, «улымның гомере, сәламәтлеге өчен җаваплылыкны үз өстемә алам» дигән гариза язып, Гайшә апа Маратын Уфага күчертүгә ирешә. Диагноз раслана: муены сынган, умыртка баганасы чәрдәкләнеп, арка миенә кергән. Операция сигез сәгать ярымга сузыла. Әни кешенең ут эчендә яшәгән сәгатьләре... Менә шул операциядән чыккач, Марат палата табибына: «Мин кайчан йөри башлыйм?» – дигән сорауны бирә. «Йөрергә? Сез хәтта утырып та тора алмаячаксыз», – дип җавап бирә аңа табиб.

– «Нишләп алай әйтәсез? Бу, беренче чиратта, Аллаһы Тәгаләдән, аннан үзебездән, аннан соң гына сездән тора», – дидем табибка. «Улым, тыңлама, утыру гына түгел, йөрибез әле без синең белән», – дим. Табиб: «Әйе, йөрерсез», – дип, көлемсерәп палатадан чыгып китте... Ул вакытта бик хәтерем калган иде. Аннары гына аңладым – табиб хаклы булган. Мондый диагноз белән Марат йөрергә тиеш булмаган. Германиядә дә шул сүзне әйттеләр безгә: «Сез ничек йөрисез? Бу бит могҗиза!» – диделәр... Рәхмәт ул табибка, йөрисез, дип әйтсә, өметләнеп көтеп кенә утырган булыр идек...

22 ноябрьдә Маратны инде хастаханәдән чыгарырга җыеналар. Ананың: «Ничек инде? Шушы хәлдәме?» – дигән соравына, табиб: «Ярты елдан үзегездә реабилитация узарга барырсыз», – ди. Барыбер мәгънә юк дип, әйтеп кенә бетерми... Улын неврология бүлегенә күчертүгә барыбер ирешә Гайшә апа. Дөрес, түләүле палатага. (Кемнәр генә булышмый аларга ул чакта: туганнар, табиб Наилә ханым Хөснетдинова кебек гаилә дуслары, Маратның дуслары, хезмәттәшләре, йөргән кызы... Операция өчен бар чыгымнарны да ул эшләгән «Баулынефть» газ һәм нефть чыгару идарәсе үз өстенә ала.) Улын аякка бастыру өчен көрәш башлана.

– Иртәнге сәгать дүрттә торам. Маратны юындырам, чистартам, кырындырам, ашатам. Һәм күнегүләр ясарга керешәм! Кул бөкләнеп каткан: аны сындырмаска да кирәк, шул ук вакытта хәрәкәтләндерергә дә. Кулга гына 1600 төрле күнегү ясый идек. Иң авыры – кул, диләр. Бер кул бармагын «җибәрү» өчен, бер аякны «җибәргән» кадәр эшләргә кирәк... Иртәнге сәгать тугызда процедуралар башлана. Каталка белән алып китәм. Кабинетларга кергәндә, бусага аша узу өчен каталканы аз гына күтәреп җибәрергә кирәк. Ярый әле буем кечкенә – җәлт кенә каталка астына кереп китәм дә иңбашым белән күтәрәм. Берәүдән дә ярдәм көтмәдем...

Эльмира Заһировна дигән табиб: «Марат, уй белән гел атлаганыңны, йөргәнеңне күз алдыңа китереп ят әле», – ди. Кичләрен, ял көннәрендә әкрен генә музыка кабызалар да, егет хыялга чума... Бер айдан соң уң аякның баш бармагы селкенә башлый! Гәүдәгә хәрәкәт иңә! Гайшә апага Маратны утыртырга булышырга Алексей Маликов дигән дусты көн саен (!) хастаханәгә килеп йөри. Әни кеше үзенә бирелгән ризыкны ашамыйча, аңа калдыра... (Алексей гына түгел, бүгенгәчә һәрдаим ярдәм кулы сузарга әзер булган Алмаз Дәүләтшин, Эдуард Ситдыйков кебек дуслары да бар әле Маратның.) Ә аннан шундый көн җитә: табиб-реабилитолог Вадим Мөхәммәтҗанов Маратны дүрт кеше ярдәмендә аякка бастырып карый: «Ун секунд басып торса, аңын җуймаса, йөриячәгенә өмет бар», – ди. Басып тора!

Бер ел буе алар әниле-уллы хастаханә палаталарында яшиләр: кайтып бер атна гына ял итәләр дә тагын китәләр. Маратның фаҗигагә тарыр алдыннан гына Баулыда ипотекага алган (аның өчен түләү – үзе аерым бер тарих. Ул көннәрдә бу авыр йөкнең бер өлешен олы улы Азат һәм аның гаиләсе үз өстенә ала) фатирының бер бүлмәсе тренажер залына әйләнә. Көн саен 10–12 шәр сәгать күнегүләр ясау башлана. Еллар дәвамында!

– Минем кебек хәлгә калганнарны, гадәттә, гел әниләре карый. Әмма минем әни кебеге сирәк. Әйтик, менә дәвалау физкультурасы дәресе бар. Авыруны караучылар, гадәттә, бу вакыт читтә басып тора. Ә әни гел янәшәмдә булды. Соңыннан өстәмә шөгыльләнү өчен үзенә өйрәнеп калырга кирәк иде аңа. Мин дә һәр күнегүне отып калырга тырыштым. Инструктор белән ярты сәгать шөгыльләнү нидер бирергә мөмкиндер, әлбәттә, әмма бу бик аз, – ди Марат.

Һәр көнне – карда, буранда, коеп яуган яңгырда алар урамда йөриләр. Өчәр чакрым! Башны, кулларны эшләтү өчен пазллар җыя башлыйлар. Дүртәр меңлек детальләне!

Маратның пенсиясенә генә көн итәргә туры килә. Бигрәк тә «Без зарланырга яратмыйбыз, хәлен үзегез күрмисезмени?!» – дигән өчен аны 2 нче группага гына

калдырган елны тормыш итү авырлаша: ипи дә ала алмаган чаклар була. Чарасызлыктан челтәрле маркетингка керәләр. Табыш китермәсә дә, бу шөгыльнең, аралашуларның бер файдасы була: Марат тотлыкмыйча сөйләшә башлый.

Аларның инде үз көенә аккан тормышын Дәүләт Думасы депутаты Ришат Әбүбәкиров ярдәме белән өч тапкыр Германиягә реабилитация узарга бару үзгәртә. Аннан кайткач бер танышы – «Пакер» фәнни-производство фирмасы директоры Марат Нагуманов: «Син кайчан кешеләрне дәвалый башлыйсың инде? Башкаларга да булышырга вакыт бит», – ди. Бер әйтә, ике, өч... Беренче ишеткәндә: «Ничек инде кемгәдер булышырга? Әле бит үземә дә ярдәм кирәк – начар йөрим», – дисә дә, аннан күңелгә уй керә. Ә икенче бер танышы: «Марат, син реабилитацияләү эшен практикада беләсең, теориясен өйрәнергә вакыт», – ди һәм... медицина университетында белем алырга киңәш бирә... Казан дәүләт медицина университетына укырга керә алар, һәм кызыл дипломга тәмамлыйлар. «Алар» дим, чөнки студент эскәмиясенә икәү утыралар: Гайшә апа лекцияләрне дәфтәргә язып бара, ә Марат хәтеренә сеңдерә. Курс эшләрен башкалар кебек интернеттан гына эзләми – үзе яза. (Өч югары белеме бар бүген Маратның: 2019 елда Идел буе физик культура, спорт һәм туризм академиясен дә «яхшы» билгеләренә генә тәмамлый ул.)

Башкаларга ярдәм итәр көн дә килеп җитә.

Беренче пациентларны алар өйдә кабул итәләр. Иң авыры тагын Гайшә апага төшә: Марат аңлаткан күнегүләрне башкаларга ясарга булышырга аңа туры килә бит.

2013 елда Германиядән Маратка «ходунки» алып кайталар. Аңа тотынып, Баулы урамнарын шактый урый алар әниле-уллы. «Бер ел йөрим дә, мин моннан машина ясатам әле», – ди Марат. Бабасыннан калган ат ияре, иске кәнәфи эченнән чыккан губка – барысы да ярап куя. Марат уйлап тапкан беренче тренажер ул. (Әлеге «тренажер-машина»ларда сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән авырулар арасында ярышлар уза хәзер. Ул – җайлаштырылган спортның яңа төре санала!)



Ә аннан ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләр саны арта – өйгә генә сыймый башлый. Медицина университетында укыганда коммерцияле булмаган оешмалар, аларның мөмкинлекләре, грантлар турында ишетә Марат һәм тәвәккәлли... Марат Ильясовның «Мин булдырам» («Я смогу») сәламәтләндерү үзәге республикабызда гына түгел, Россиядә дә уникаль проектларның берсе санала хәзер. Марат уйлап тапкан тренажерлар саны инде бер дистәдән артып киткән – алар инде күптән төрле заводларда җитештерелә. Үзәккә ярдәм итүчеләр дә саллы: Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов үзе, «Татнефть» җәмгыятенең генераль директоры Наил Мәганов, Баулы районы җитәкчеләре... Рөстәм Миңнехановның тәкъдиме белән Марат уйлап тапкан тренажерларны күбәйтү, аларны республика хастаханәләренә, реабилитация үзәкләренә урнаштыру бара. Әмма ул тренажерларны гел барып, күзәтеп торырга – белгечләр белән аралашырга кирәк: шуңа да алар хәзер гел юлда.

Үзәктә Татарстанның – 6, Башкортстанның 3 районыннан килүчеләр дәвалана. Бушлай! Дөресрәге, иганәчеләр, откан грантлар хисабына. Ярдәм сорап килгән берәүне дә кире бормыйлар. Ә аларның саны бу биш ел эчендә берничә меңгә җиткән. Бүген үзәктә инде ике инструктор, табиб, шәфкать туташы эшли.

– Бу үзәк – минем миссиям. Үзем аякка баскач, башкаларга ярдәм итәргә, үрнәк булырга тиешмен дип саныйм. Барысы да үзеңнән һәм сине әйләндереп алган кешеләрдән тора. Әнидән! Безнең әнинең буе 152 сантиметр гына әнә, мин исә 176 сантиметр. Әмма кирәк чакта ул мине күтәрде, күтәрә алмаса – тартты. Син булдырасың, диде. Шуңа күрә аякка баса алдым. Аның, гомумән, «булмый» дигәне юк. Нинди генә идеям барын белсә дә: «Әйдә, эшләп карыйк!» – ди. Ул мине кешеләргә яхшылык кына теләргә өйрәтте. Авариядән соң өч ел узгач, йөргән кызым кияүгә чыкты. «Син аңа чын күңелдән бәхет телә. Иң авыр чагында ул янәшәңдә булды», – диде әни. Кемдер сиңа ярдәм итә алмаган өчен аңа үпкәләргә ярамый, ди. Миңа ышанды һәм мине үз-үземә ышанырга өйрәтте. Ышану бик кирәк! Онлайн дәресләр алып барам соңгы вакытта. Күпләр бер-ике дәрестә катнаша да, югала. Берничә күнегү ясауга йөгереп йөри башлауны көтәләрдерме? Нәтиҗә булсын өчен көн саен күпме эшләргә кирәген әнидән сорасыннар әнә. Яңа таң туган саен без ничәмә-ничә ел аның белән өр-яңадан яши башладык...

...Сәхнәгә Гайшә апа башта берүзе күтәрелде, әмма улының янәшәдәлеген тойдык дигән идем. Инде уналты ел шулай бергә алар. Әмма икәү генә түгел! Авыр чакта иңнәрен куярга һәрвакыт әзер булган туганнар белән. Балаларының да үзара тату, бердәм булуы – ананың иң зур шатлыгы. Гөлназының ирен – Илмирны да ул «өченче улым» дип йөртә, килене Лирага да «кызым», дип эндәшә.

Әни һәм ул. «Нигә болай булды соң?» – дип әйтмичә генә гел алга атлый алар. Хәер, Марат әнә нәрсә ди: «Әни алты оныгының берсенең дә үскәнен күрмәде – аңа азрак ял итәргә дә кирәк инде», – ди. Таянырга тагын бер якын кешесе – Надясы да бар бит аның хәзер.

Мәктәп еллары һәр кешенең язмышында иң матур, истәлекләргә бай сөенечле бер чор булып урын аладыр. Тормыш белән очрашу, белем ачкычына ия булу, зур коллективта тәрбияләнү, үзеңне шушы җәмгыятьнең бер күзәнәге итеп тоя башлау, милли үзаң формалашу – болар һәммәсе мәктәп чоры белән бәйле могҗизалар бит. Ә мәктәпне һәм бу мөһим вакыйгаларны Укытучы дигән гаҗәеп затлардан башка берничек тә күзаллап булмый.

# «ҺӘРКЕМНЕҢ МАТУР СЫЙФАТЫ БАР...»





Чулпан ГАЛИЕВА

**– Үскәч кем буласың?**

**– Нурзидә апа кебек татар теле укытучысы!**

**Класста кызларның барысының да җавабы бер. Укытучының сәнгатьле сөйләвенә, матур киенүенә, кирәк вакытта шаярта, нәкъ син көтеп торган чакта ярдәм итә белүенә соклана идек һәм аның кебек буласы килә иде. Нурзидә Шәрәф кызы Кукмара районының «Березняк авылы Х. В. Ваһапов исемендәге төп гомуми белем бирү мәктәбе»ндә 25 ел татар теле һәм әдәбияты дәресен укытты. (Алдан ук шуны әйтеп куйыйм: без, авыл балалары, бер укытучыга да әтисенең исеме белән дәшми идек. Шуңа язмамда да укытучымны «апа» дип язуыма аптырамагыз.) Хәер, сүзләрем ничек кенә сәер тоелмасын, дәрес бирү укытучы эшенең меңнән бер кыйпылчыгы гына иде. Нурзидә апа безнең белән мәктәптә «яшәде», укучылар тормышындагы бер генә вакыйга, бәйрәм дә аннан башка узмый иде.**

…Кыңгырау шалтырады, чираттагы дәрес – татар әдәбияты. Кабинетка килеп керсәк, укытучы өстәлендә дистәләгән китап, әсәрдән өзек яздырылган пластинканы уйнатырга патефон корылган, аерым өстәлдә газета-журналлар ята, тактага зур портрет беркетелгән. Әһә, бүген Әмирхан Еники иҗатын өйрәнә башлыйбыз икән. Әдәбият белән кызыксынган берничә укучы дәрес башланганчы китапларны, язучы иҗаты турында язмалар басылган матбугатны караштыра башлыйбыз. Нурзидә апа читтән күзәтә, тәртипләп тезелгән өстәлнең астын өскә китерсәк тә, дәшми. Безгә ачарга ярамаган серле шкафының ишеген каерып ачып куеп, диафильм тасмаларын барлый. Димәк, бүген дәрес бик кызык булачак. Хәер, аның һәр дәресе кызык уза. Хәтта әсәрне укып килмәгән өчен борчылуыңны да онытып, әдәбият дөньясына чумасың да, укытучы туктап калган кызык урыннан соң нәрсә булганын белү өчен кулыңа китап аласың. Юк, әле башта укыган кыяфәт белән алдап карыйсың. Узган дәрестә колакка кергәннәрне җиңел генә әйләндереп-тулгандырып сөйләп чыктым. Котылдым дигәндә генә сорау яңгырый:

– Әнә шул мөһим вакыйга алдыннан геройның эчке кичерешләре сурәтләнгән урынга тирәнрәк тукталыйк әле.

Беттем! Укытучы сине дөм батырып бетерми анысы, тик оялырга мәҗбүр итә, һәм икенче көнгә инде шәпләп укып киләсең.

Ул чакта өлгерешне район, республика күләмендәге олимпиада нәтиҗәләренә карап билгелиләр иде. Ә без татар теле буенча ел саен призлы урыннар алып килдек.

– Дәрестән соң бүген китапханәгә барабыз.

Яңа язучының иҗатын узган саен, Нурзидә апа безне китапханәгә алып бара иде. Китапханә аерым бинада урнашкан. Кышкы салкын биттән чеметәме, коеп яңгыр явамы — йөз метрны Нурзидә апа артыннан йөгереп узабыз. Аннан ул һәркайсыбызга китап сайлаша: яхшырак укучыларга калын романнар алып бирә. Укырга яратмаучыга юкарак китап тоттыра да:

**Беттем!** Укытучы сине батырып бетерми анысы, тик оялырга мәҗбүр итә, һәм **икенче көнгә инде шәпләп укып киләсең.**

– Әйдә, энем, биш көндә шушы китапны укып чык, дан булсын, классташларыңның исе китсен, – дип, укырга яратмаган балада азарт уятып та өлгерә.

…Бүген безнең шигырь ятлый торган көн. Юк ла, программа буенча бирелгәнен түгел. Һәр укучы атнага бер шигырь ятларга тиеш иде. Аны үзең эзләп табасың, шигырь дәфтәренә матур итеп күчереп аласың һәм ятлыйсың. Аннары иң авыры – сыйныф алдында сөйләргә кирәк. Ятлавын ятлыйбыз ла аның, ә менә сәнгатьле итеп сөйләмәсәң, логик басымны бутасаң, кисәкчәләрне кушасы урында кушып, аерасы урында аерып әйтә белмәсәң – беттең! Киләсе атнада ике шигырь тапшырасы була! Шуңа сәнгатьле сөйләү сәләте булганнарга шигырь укып күрсәтәбез, басым төшәсе, аерып әйтәсе, туктап торасы урыннарын карандаш белән билгеләп куябыз. Нурзидә апа шулай итеп бездә шигърияткә мәхәббәт уяткан, сүз тәмен тоярга өйрәткән икән бит! Шуның өстенә әле бердәмлеккә дә өндәгән, чөнки бөтен укучы да вакытында тапшырса, сыйныф алдынгылар рәтенә чыга, димәк, бергәләп тырышырга кирәк.

…Дәрес тәмам. Бер катлы мәктәпнең озын коридорындагы нәкъ татар теле кабинеты янында турник итеп кулланылган штанга куелган. Спорт залы юк, көн салкын булганда безнең физкультура дәресләре шунда уза иде. Нурзидә апа тәнәфескә безнең белән бергә чыга.

– Кабинетка кереп утырырга өлгерерсез, йә, кем озаграк «эленеп» тора ала? – ди дә, ике куллап шул штангага ябыша. Малайларның укытучы белән ярышасы килмиме инде?! Букчаларын идәнгә тотып аталар да шул штангага атылалар. Дәрес арасында бераз тәннәрне язып алу булган инде бу.

Миңа мәктәптә бердәнбер «ике»лене дә Нурзидә апа куйды! Гел «биш»легә укыган мәктәпнең иң алдынгы кызына тотты да «ике»ле куйды! Инша язылган дәфтәрне өйдә онытып калдырган өчен. Мәктәп белән өй арасы – 500 метр, кайтып килим әле, дим.

– Юк, онытып калдыргансың икән, башкалар белән бертигез җәзасын да аласың, – диде.

Бик зур сабак булды ул миңа. Кирәк-ярагыңны җыеп йөрергә генә түгел, масаймаска, тыйнак булырга да өйрәтте.

Инша язарга ярата идем үзе: 18 битле бер дәфтәргә бары ике тема «сыя» иде. Ә менә матур язу минеке түгел инде. Башыңда шулкадәр фикер, әйтәсе сүз булганда бармаклар ничек матур итеп язарга өлгерсен инде, йә?! Нурзидә апа һаман шул язуны матурларга тырыша, сызгалаган өчен билгемне дә төшерә иде әле хәтта.

– Язуыгыз энҗе бөртеге кебек булсын! Ул сезнең күңел көзгесе, – ди иде укытучы. Мәктәпне тәмамлаганга инде 24 ел узган. «Истәлекләр дәфтәре»н карап утырам: барыбызның да язуы бертөрлерәк, әмма шул ук вакытта кем язуы икәнен дә танып була. Хәтта егетләр дә шундый матур итеп язган! Язмыйча, кулыңа каләм алуга Нурзидә апа сүзләре искә төшә: күңелне матур итеп күрсәтәсе килә.

«Ике»лесе истә, тик Нурзидә апаның ачуланганын хәтерләмим. Укучы берәр ярамаган эш эшләсә, ул аның белән үзе күзгә-күз калып сөйләшә башта. Нигә шулай кылануының сәбәбен ачыклый. Аннан үз киңәшен бирә, тик бервакытта да сыйныф алдында сүкми. Безнең иң шаян малайлар да татар теле дәресендә үзгәреп китәләр иде. Юк, алар укытучыдан курыкмый. Алар аңа ышана, ни генә булса да укытучы белән аңлашып булачагын белә, үз итә иделәр.

…Театр атналыгына һәр мәктәп спектакль әзерләргә тиеш икән. Тагын Нурзидә апага чабабыз: нинди әсәр сайларга, ничек куярга? Батулла-

## Чишмәгә кадәр биш чакрым. Бер көтү бала ияртеп, берүзе ни йөрәге белән чыгып киткән икән ул?!



**Абдуллина Нурзидә Шәрәф кызы.**
**■ I категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.**
**■ Тормыш девизы: «Укучылар өчен һәр дәрес ачыш, һәр дәрес могҗиза булырга тиеш!»**

Фотолар: Нурзидә Абдуллина архивыннан

ның «Кичер мине, әнкәй» драмасын сәхнәләштердек бер елны. Көн саен кич репетициягә төшәбез. Үз вазыйфасына кермәсә дә, Нурзидә апа да безнең белән: ул, режиссер кебек, һәр хәрәкәтне, һәр сүзне дөресли, уйнап күрсәтә, кем нәрсә киясен уйлый. Миңзифа роле өчен район күләмендә «Хатын-кыз ролен иң оста башкаручы» дигән диплом күтәреп кайттым бит тәки!

– Иртәгә каникулның беренче көне, өйдә тик ятмагыз. Көндезге бердә чаңгыларыгызны киеп, савытлар алып безнең өй янына килегез, чишмәгә барып кайтабыз.

Каникул алдыннан уза торган линейкада Нурзидә апа шундый белдерү ясый.

Чишмәнең иң ерагына авылдан биш чакрым бараса. Бер көтү бала ияртеп, берүзе ни йөрәге белән чыгып киткән икән ул?! Тезелешеп, Нурзидә апа салган эздән шуабыз. Ул, вакыт-вакыт туктап, арттагыларның хәлен белә. Аннан тагын кузгалабыз.

Бераз баргач, барыбызны бер тирәгә җыя да, шушы урын турында сөйли башлый. Кортлык чишмәсе, Әсән тавы, Икеара басу... Алар ник шулай аталган, авыл янындагы посадканы кем утырткан — барысын да сөйли. Аннан тагын кузгалабыз.

Арып-талып чишмәгә килеп җиткәч, Нурзидә апа үзе барыбызның да шешәләренә су тутырып бирә. Мондый сәяхәттән соң йокының тәмлеләгән белсәгез! Әле шул чишмә тавышы колакта бик озак чылтырап тора, юлда ишеткәннәр төшкә керә... Ә җәйге каникулда чәйләр, тәм-том салган биштәрне асып, шул чишмәгә велосипедта барабыз. Чишмә янында тамак ялгап алгач, «Куышлы», «Әбәкле», «Йөзек салышлы» уйнап алабыз. Чишмәдән соң Нурзидә апа безне өч кенә өйле Тәмле Чишмә авылына алып керә. Аның тарихы, халкы, бүгенге авылларның киләчәге турында сөйли... Тәмам хәлдән тайгач, кояш баешында өйгә кайтып керәбез. Мондый онытылмас сәяхәтләр безне берләштерә, укытучыга якынайта иде.

...Миңа һөнәрне дә Нурзидә апа сайлашты. Хәер, миңа гына дип әйтү дөрес булмас. Берничә укучысын театр училищесына җитәкләп үзе алып барды, имтиханга әзерләнгәндә киңәшләрен бирде ул. Аның укучысы Алсу Хәбетдинова бүген Татарстанның атказанган артисты. Безнең авыл мәктәбендәге яшь коллективта барысы да аның укучылары. Башка район һәм шәһәрләрдә ул укыткан татар теле укытучылары әллә ничә дистә. Ә миңа, җиденче сыйныфтан ук, син яза беләсең, журналистикага барырсың, ди торган иде. Ул чакта тере журналист күргән юк, аның ни эшлисен дә белмим. Алай да Нурзидә апа киңәше белән район газетасына, балалар газеталарына хәбәрләр, язмалар әзерләп җибәрә башладым. Газетада үз исемеңне күрү бик рәхәт икән лә! Укытучым алып барган «Яшь хәбәрчеләр» түгәрәгенең иң актив әгъзасы булдым. Авылда минем каләм язмаган кеше сирәк булгандыр.

«Һәр кешенең матур сыйфаты бар ул, күрә белергә кирәк», – дип өйрәтә иде укытучым. Нурзидә апа мине район газетасына экскурсиягә дә алып барды. Газетаны ничек эшләгәннәрен шунда беренче тапкыр күрдем. Редакция тормышына беренче адым шулай салынды. Аннан «Алтын каләм» бәйгесендә җиңеп, Казан дәүләт университетының журналистика факультетында белем алдым. Инде 18 ел – газетада, үз эшемне бик яратып эшлим.

Нурзидә апа бүген лаеклы ялда. Хәер, аның ял итәргә вакыты да юк. Кышын чаңгы-чана шуу бәйрәме уздыруда катнаша, җәй буе велосипедта йөри. Кичләрен авыл апаларын җыеп, авыл әйләнә. Мәдәният йортындагы бер генә чара да аннан башка узмый. Юбилей, туйга баручылар башта аның янына сугыла, чөнки Нурзидә апа бик матур итеп котлау текстлы, шигырьләр язып бирә. Ул бүген дә китапханәгә йөри. Яңа чыккан китапларны да, классик әдәбиятны да укый. Спектакльләр, аларның куелышы белән дә кызыксына. Тел, әдәбият, мәдәният язмышы өчен борчылып яши.

Бүген уйлыйм да, шуны аңлыйм: Нурзидә апаның эш алымнары аңа булган хөрмәтебезне арттырган икән ләбаса. Укучыларын үз итеп уйнапкөлеп йөргән, кирәк чакта ярдәм кулы сузган, киңәшен биргән, адашканда юл күрсәтеп җибәргән укытучыны ничек хөрмәт итмисең инде?! Әнә шул үзенә булган хөрмәте аша Нурзидә апа туган телебезгә, әдәбиятыбызга, мәдәниятебезгә, милли гореф-гадәтләребезгә, йолаларыбызга карата мәхәббәт уята алды бездә. Үз балаларымның мәктәптәге хәлләрен тыңлаганнан соң, күп кенә укытучыларның бала күңелен яулый алмаулары борчый мине. Әйе, бүгенге балалар башка, аларның кумиры булу өчен бер генә түгел, биш башка югары булырга кирәктер. Тик бала күңелен кешелеклелек, ярдәмчеллек, самимилек, гадилек һәм мәхәббәт белән тизрәк яулап буладыр... Безне үз артыннан ияртә алган Нурзидә Шәрәф кызы кебек!

РЕКЛАМА. ИП ХӘБИБУЛЛИН И.Г. ОГРН 320169000095025

МАСТЕРСКАЯ ОЛЕСИ МУСТАЕВОЙ

ШАМПУНЬ ОБЛЕПИХОВЫЙ

УВЛАЖНЕНИЕ И МЯГКОСТЬ

чәчләргә куелык һәм купшылык өсти

чәчләрнең һәм баш тиресенең барлык төренә дә туры килә

каты суда да яхшы күбекләнә

# ЧӘЧЛӘРНЕҢ СӘЛАМӘТЛЕГЕ, МАТУРЛЫГЫ ҺӘМ КУПШЫЛЫГЫ




master-om.com



PRESSA

# «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» АҢЛАТА

Республиканың төп басма матбугаты «Ватаным Татарстан» газетасына – 105 ел. 1918 елның 12 мартында «Эш» иҗтимагый-сәяси газетасы дөнья күрә башлый. «Социалистик Татарстан» исеме белән озак еллар чыкканнан соң, үзгәреш еллары вакытында ул «Ватаным Татарстан»га әйләнеп, укучыларга тагын да якыная. Хәзер, яратып, «Ватаным» өйгә килә», дип кенә сөйләшәбез. Элек чыккан газета битләрен актарып карасаң, узган гасыр тормышын, халыкның нәрсә белән яшәгәнен, хакимиятнең ул чордагы сәясәтен күз алдына китерергә була. Димәк, ул Татарстан сулышын ташка бастыра. Чор үзгәрә, халык та үзгәрә, газетадагы темалар да, күтәрелгән проблемалар да башка. Бүген укучы нинди уйлар белән яши, аны нәрсә борчый, халык хөрмәтен яулар өчен матбугат нинди булырга тиеш? Газетаның баш мөхәррире Гөлнара САБИРОВА белән әңгәмәбез шул хакта.



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

**Абруйлы журналист, яраткан укытучыбыз Миңназыйм абый Сәфәров, хәтерлисеңдер, журналистика ул – халык белән хакимият арасындагы күпер, дип әйтә иде. Халыкның да өметен акларга, хакимият белән дә маңгайга-маңгай бәрелмичә яшәргә кирәк. Республиканың төп газетасы буларак, сезгә ике ут арасында яшәү ничегрәк?**

– Дәүләтне яратырга мөмкин, яратмаска мөмкин, әмма барыбер син аның бер өлеше, һәм аның ни эшләве барыбызны да кызыксындыра. Еш кына: «Дәүләт басмасы Рәиснең кая барганын яза да бирә. Аларга шуның өчен акча түлиләр», – дигән фикер ишетергә туры килә. Дәүләт басмаларына карата мондый негатив фикерне кабул итмим. Һәм шуңа инанам: дәүләтнең үз басмалары булырга тиеш. Әйе, без хакимият карарларына бәя бирмибез, безнең эш – аны аңлату. Рөстәм Миңнеханов ислам иленә очрашуга бара икән, максатыбыз бу сәфәр турында мәгълүмат бирү түгел, ә ерак авылда яшәүче апаның тормышында аның нинди чагылыш табачагын язу. Пандемия чоры да, бүгенге вазгыять тә халыкка аңлату җитмәвен күрсәтте. Әйе, мәгълүмат ташкынына, фейкларга күмелеп яшибез. Хәзерге чорда классик журналистиканың ни өчен әһәмиятле икәне ачыклана. Без аналитика белән шөгыльләнәбез. Журналистыбыз Рәшит Фәтхрахманов бар безнең. Аны аерым бер катлам моңа кадәр дә кабул итте, укыды. Әмма, Рәшит абый үпкәләмәсен, минемчә, аның журналистикасының чәчәк аткан чоры бүген, чөнки бөтен кеше аңларга тели: ни өчен Ватан һәм Ватанны саклау төшенчәсе әһәмиятле; икътисад бүген нинди хәлдә; акчаны ничек сакларга?.. Менә шушы сорауларга җавапларны халыкка татарча аңлатучы бердәнбер журналист ул бүген, һәм ул бездә эшли. Җомга санында бары тик аналитика гына хәзер. Башка татар матбугатында кузгатылмаган темалар күтәрелә анда. Аналитиканы, бигрәк тә дөнья сәясәтенә һәм икътисадына анализны бары тик рус басмаларыннан гына укып була дигән стереотипны җимердек без. «Ватаным Татарстан» – тормышның бөтен ягын дөрес итеп яктырткан иң ышанычлы мәгълүмат чарасы. Горурланып әйтәм: бездә фейклар, хайп юк. Хайп эзләп игътибар яуламыйбыз, эшлибез икән, төбенә кадәр төшәбез.

**Халыкның гозерен хакимияткә җиткерүче дә бит әле ул матбугат. Укучы хатлары буенча барып, саллы язмалар эшләп, гаделлекне тантана иттерә алабыз дип мактана аласызмы?**

– Горурлана алабыз. Без хат килгәнне дә көтеп тормыйбыз. Әйе, безгә әле дә почта аша хатлар килә. Газетада «Укучы сүзе» дигән рубрикабыз да чыга. Интернеттан безне тәүлегенә 11-12 меңнән артык кеше укый. Социаль челтәрләрдә аккаунтларыбыз бар. Укучыларыбыз шулар аша йә ышанган журналистлары аша мөрәҗәгать итә, шәрехләмә язып калдыра. Менә шуннан да халыкны нәрсә борчыганын беләбез. Ул үзенә күрә бер көзге. Һәр язма астына язылган шәрехләмәләрне укып барабыз, әле журналистларга аларга җавап бирү дә йөкләнгән. Халык белән элемтә булырга тиеш! Без – дәүләт басмасы, һәм халык гозерен тыңлау, проблемаларын хәл итү – бурычыбыз. Кукмара районында мәктәп ябылу, халыкның җир кишәрлекләрен саклап калу, фермерлар белән район җитәкчеләре арасындагы аңлашылмаучылыкларга аңлатма кертү кебек проблемаларны күтәрдек һәм хәл итәргә ярдәм иттек. Менә хәзер җирлекләрдә чиста су проблемасына багышланган язмалар сериясе чыга. «Ватаным Татарстан»ның тагын бер өстенлеге бар: теләсә кайсы дәүләт органына мөрәҗәгать итә алабыз. Үтенечебез игътибарсыз калмый.

**Гөлнара, син чирек гасыр диярлек басма матбугатта эшлисең. 20 ел элек укучыларны нәрсә борчый иде дә, газета хәзер нинди проблемаларны күтәрә?**

– Университетны тәмамлаганда журналист тикшерүе буенча диплом якладым. Ул чорда халык гозере, нигездә, шәхси иде: суд системасында гаделсезлекләр, хуҗалык рәисе белән каршылыклар, үзен рәнҗетүләр... Дөнья белән халыкның тормыш дәрәҗәсе дә үзгәрде. Хәзер аны шәхси проблемалары алай ук борчымый, аң дәрәҗәсе үсә, ул глобальрәк фикер йөртә. Күршесе белән ике арадагы ызан турында уйламый ул, ни өчен авылда халык саны кими дигән сорауга җавап эзли. Журналист тикшерүе дә билгеле бер кеше проблемасын гына күтәрми, ә җәмгыятькә кагылышлы мәсьәләләрне тикшерә. XXI гасыр – гуманитар фәннәрне һәм культураны үстерү гасыры, ди галимнәр. Эчке культурасы булган кеше һәрвакыт уйланачак, үзенә кызыксыз эштә эшләмәячәк, баш иеп тормаячак, үз фикерен әйтәчәк. Кешенең эчке культурасы үскән саен, икътисад, сәнәгать, мәдәният алга китәчәк, тормыш яхшырачак.

**Фикерне дәвам итеп, баш редактор гына түгел, Татарстан Журналистлар берлеге рәисе урынбасары буларак та сиңа үземне борчыган сорауны бирим әле. Ул матбугатка гына түгел, мәдәният өлкәсенә дә кагыла. Бүгенге көндә журналист халык артыннан барсынмы, әллә халыкны үзе ияртсенме?**

– Халыкны ияртергә тиеш! Мәдәнияттә дә шулай булырга тиеш. Дөрес аңлагыз: бу әле халыкны тыңламаска, аның ихтыяҗлары белән кызыксынмаска дигән сүз түгел. Һич тә! Аяныч, шундый бер чор булды: без иярдек. Халыкка шул кирәк дигән фикер өстенлек алды. Беренче чиратта татар кешесе һәм милләт турында уйлыйм мин. Әйе, халыкка кызык дип, күп әйбер турында язарга була. Ул бик җиңел юл, артык уйлап баш ватасы юк. Әмма, бәхеткә, безнең укучы башка... Әгәр берәр җырчы белән бәйле гайбәт, җинаять турында язма чыгарабыз икән, моны язмагыз,

мондый мәгълүматтан арыдык, дип фикерләрен җиткерәләр. Алар күп балалы, үрнәк гаиләләр турында, яктылык белән сугарылган язмаларны, Марат Кәбировны, Наил Шәрифуллины рәхәтләнеп укый, сораулар бирәләр, үз фикерләрен җиткерәләр. Укучыларга уйландыра торган язмалар кирәк бүген. Халыкка иярүчеләргә кызганып карыйм мин. Халык артыннан ияррергә була, әмма шундый көнгә килеп җитәргә мөмкинбез: ул зомбилашачак. Без сөйләгән эчке культуралы халык үсеш турында уйлый, ә зомбилашкан халыкка берни кирәкми. Миннән дә начаррак яшәүчеләр бар әле дигән фикер белән үзен тынычландырып кына яшәячәк ул. Андый халык белән киләчәктә нишләрбез, алар нәрсә белән кызыксыныр? Аңа бит матбугат та кирәк булмаячак. Төп миссиябез – милләтне рухи яктан үстерү турында онытмыйбыз. Шуңа күрә дә күп нәрсәләргә, бигрәк тә мәдәният, әдәбият мәсьәләләренә милли яктан карыйбыз.

**Бүген татар журналистикасының вәкаләте менә шул булырга тиеш дип уйлыйсыңмы?**

– 100 процент! Бигрәк тә дәүләт матбугатының. Шәхси куллардагы матбугаттан моны таләп итә алмыйбыз, ул үз акчасына үзе теләгән әйберне эшли. Әмма бүген алар тема сайлау ягыннан кайбер дәүләт матбугаты чараларыннан күпкә өстенрәк, чөнки алар – эшмәкәрләр. Кая барасын беләләр, киләчәге турында уйлыйлар. Көчле медиаменеджер Раиф Усманов белән фикерләшәбез һәм безнең фикерләр туры килә. Берничә елга алдан уйлап эшләргә кирәк. Яхшы, син бүген шушы ташкынга иярдең, ә 5–10 елдан газетаңны укучы булачакмы? Бүген татар матбугаты нәрсә телим шуны эшлим дип түгел, дәүләттән алган акчасын милләт файдасына юнәлтергә, халыкның милли үзаңын тәрбияләп, үз милләте белән горурланырга кирәклеген аңлатырга тиеш. Бу уңайдан җиң сызганып эшләргә рухландырып та торалар бит. Соңгы ике-өч ел татар матбугаты өчен, гомумән, ренессанс чоры булды дияр идем. Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе җитәкчесе Марат Әхмәтов барыбызга да зур мөмкинлекләр ачты, грантлар ярдәмендә күпме яңа проектлар, сәхифәләр туды. Бу бит республика җитәкчелегенең матбугатка мөнәсәбәтен дә күрсәтә!

**Бүген массакүләм мәгълүмат чаралары тармагында шәхес-журналистлар, журналист фикере дигән төшенчә яңгырый башлады...**

– «Татмедиа» агентлыгының еллык коллегиясендә «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясенең генераль директоры, Журналистлар берлеге рәисе Илшат Әминов уйландыра торган проблема күтәрде: бүген журналистикада шәхесләр юк. Ә без мактана алабыз: бездә шәхесләр бар. Габделбәр Ризванов, Риман Гыйлемханов, Наил Шәрифуллин, Рәшит Фәтхрахманов, Фәния Әхмәтҗанова, Марат Кәбиров – барысы да бездә. Яшьләр өлкән коллегаларыннан үрнәк ала, бер-берсенә карата хөрмәт белән эшли. Ни дисәң дә, алар бездән күпкә гыйлемлерәк, тәҗрибәлерәк журналистлар.

**Бүген синең шәхес-журналистларың бар, ә иртәгә? Тәҗрибәле журналистларны алыштырырдай яшь буын үсеп киләме газетада?**

– Үсәләр. Зөһрә Садыйкова, Эльвира Вәлиева, Динә Гыйлаҗиева, Чулпан Гарифуллина, Сәрия Мифтахова... Гөлинә Гыймадованың әңгәмәләрен укып карагыз. Андый форматтагы интервьюлар башка юк. Гөлгенә Шиһапова нинди киңкырлы эшчәнлек алып бара. Бүген журналист булып эшләү бик катлаулы.



Күпкырлы булу шарт. Язарга да, видео-фото да төшерергә, монтажларга һәм шуның белән бергә әле шәхес тә булырга, фикерләргә дә тиеш. Фикерләү өчен белемле булу кирәк. Белемле булу өчен укырга һәм өйрәнергә вакыт булу мөһим. Вакыт – бүген иң кыйммәт нәрсә. Журналистта шәхес тәрбияләү бик четерекле әйбер. Бөтен журналисттан да шәхес үстереп булмый, чөнки фикерләү куәсе роль уйный. Фикерле журналист ул – «штучный товар». Әмма журналистның шәхес булмавыннан аның кыйммәте кими дигән сүз түгел әле, журналистиканың төрле функцияләре бар бит. Шәхес-журналист – редактор өчен бүләк ул. Мин ул яктан «Сөембикә» журналының тирәнлеген яратам. Өстән-өстән генә язу юк анда. Журналга хас аналитикага ия ул.

**Бүгенге көндә журналистика хатын-кызлар кулында дисәң дә була. Моның, әлбәттә, тискәре яклары да бар. Хатын-кыз ир-атка караганда башкачарак фикерли. Без укучыларыбызга берьяклы гына караш таратмыйбызмы?**

– Бу бик борчый торган мәсьәлә. Әйе, ирләр аз, моны танырга кирәк. Безнең газета тарихында журналистлар арасында хатын-кызлар эшләмәгән чорлар булган. Бүген, кызганыч, әйдәп баручы журналистлар – хатын-кызлар. Кайвакыт планеркада, беренче урынбасар Илнар Хөснуллиннан кала, гел хатын-кызлар утырабыз. Ярый әле үзхәбәрчеләребез, белгечләр фикере аша ир-ат сүзе керә безнең газетага. Нишләмәк кирәк – бүген журналистика шундый хәлдә. Хезмәт хакын күпме генә арттырырга тырышсак та, ирләргә тормыш алып барырлык түләү юк безнең өлкәдә. Аннан соң бүгенге тиз үзгәрүчән журналистика хатын-кызга күбрәк хастыр. Ул бит эшли дә, өен дә карый, баласын да тәрбияли, ирен дә рухландыра, җәмгыять тормышы белән дә яши...

**Гөлнара, газетагыз тарихында син – беренче хатын-кыз баш мөхәррир. Бу зур мәртәбә дә, җитди җаваплылык та. Дүрт ел элек әлеге тәкъдимне ничек кабул иттең?**

– Шәмси Хамматов, Мөнир Әһлиуллин, Габделхак Шәмсетдинов, Миңназыйм Сәфәров кебек олпат мөхәррирләрдән соң мине, яшь әле ул, дип, җитди кабул итмәүчеләр дә булгандыр. Әмма моны тигез җирдә очраклы гына кабул ителгән карардыр дип санамыйм. Аннан соң хезмәт юлым да йөземә кызыллык китерә торган түгел, киресенчә булган очракта шундый җитди басманы җитәкләргә тәкъдим итмәсләр иде. Эш тәҗрибәм дә бар иде: «Шәһри Казан»да, «Сөембикә» журналында баш мөхәррир булдым. Миңа кадәр булган мөхәррирләрнең эш тәҗрибәсенә таянып, традицияләрне онытмыйча, бүгенге көн таләпләренә җавап биреп эшләргә тырышам. Без – олпатлардан өйрәнгән буын. Исмәгыйль Шәрәфиев шәкерте булуым белән бик горурланам. Газетада эшләгән ветераннар белән аралашып торам. Мөнир Әһлиуллин, Илсөяр Хәйруллина, Люция Фаршатова, Асия Юнысова, Әхәт Сафиуллиннарны редакциягә чакырабыз, газета турында фикерләрен тыңлыйбыз. Безгә алар фикере мөһим. «Ватаным Татарстан»га баш мөхәррир булу тәкъдимен үзем өчен бер сынау итеп кабул иттем һәм сынатмаска тырышам.

**«Ватаным Татарстан» газетасына – 105 ел. Дәүләт рупоры буларак нәшер ителгән газета кайсы ягы белән халыкны үзенә тартып тора? Бүген 16 мең тираж җыя аласыз икән, димәк, хөрмәт бар.**

– Районнар буйлап йөргәндә: «Ватаным Татарстан»да законнар гына бастыралар», дигән фикерне ишетергә туры килде. Аннан соң һәр барган җиргә газета тарата башладык. «Кызыклы икән бит», дигән сүзләр ишетелде. Әлбәттә, эчтәлеге үзгәрде. Рәсми әйберләрне дә рәсми түгел итеп бирәбез. Миңа калса, халыкка якынайдык. Аның тормышы белән яшибез. Алда әйткән иярү түгел ул. Гаиләләре, тормышлары белән кызыксынабыз. Укучыларыбызның өйләренә кереп, алар белән гади телдә аралашабыз. Газетада үзләрен күбрәк күрәләр. Алар өчен төрле бәйгеләр дә оештырабыз. Укучылар мәхәббәтен шулай яулыйбыз дип уйлыйм.

**Гөлнара, син бит әле үтә дә мәгънәле шигырьләр язучы, шагыйрә дә. Иҗатка вакыт каламы?**

– Юк. Баш мөхәррир йөкләмәләр генә биреп утыручы түгел. Мин газетага кергән бар мәкаләне үзем укып, редакцияләргә тырышам. Полосада булса да укып, язманы сызып-бозып, кире салдырган вакытлар еш була. Әле бит зур коллектив өчен җаваплымын да. Билгеле, шәхси иҗатыма вакыт калмый. Проблемалар, бурычлар хәл итеп йөреп, күңелдәге нечкәлек тә кими төшәдер...

**Шулай да фикерләреңне шигырь белән әйтергә яратасың бит...**

– Әйе, яратам. Журналистикага карата фикеремне моннан бер ел элек яздым.

*...Бәгырьне айкарлык сүзләрнең*
*Бәһасе калмаган бу җирдә*
*Мин, наив, җылылык эзлимен*
*Һәм... мәгънә телимен бирергә.*

■ Коллегаларыбызны «Ватаным Татарстан» газетасының юбилее белән чын күңелдән котлыйбыз. Тирән эчтәлекле язмалар, кызыклы геройлар, җиңел сәфәрләр насыйп итсен. Каләмегез үткен булсын! Яңа иҗади уңышлар, һөнәри осталык, күтәренке рух, гаиләгездә иминлек, бәхет, исәнлек-саулык телибез.

Фото: Анна Арахамия

PRESSA

# КҮҢЕЛ КҮЗЕ УЛ – ФӘЛСӘФӘ



Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, халык язучысы, драматург, режиссёр РАБИТ БАТУЛЛАның тормыш кагыйдәләре

Мин объектив каршында күп булган кеше, ләкин һәрвакыт каушыйм. Миллион тамашачы карый бит сине! **ОБЪЕКТИВ – ТАМАШАЧЫНЫҢ КҮЗЕ УЛ.** Мин ул кешеләрне күрәм. Диктор объективка карый, ә кешене күрми. Бериш сөйләүчеләр сәхнәдән сөйлиләр, ә кешене күрмиләр. Димәк, ятлаганны сөйлиләр. Җаннарында җылы юк тамашачыга карата. Синең сүзеңне тыңлыйлармы – бу бик мөһим бит. Тамашачыны тоеп була: тыңлыймы, кызыкмы аңа? Әллә сүзең, борчак сипкән кебек, диварга гына сибеләме?

Син дәрес аңлатасың. Ә бер малай әле тәрәзәгә карый, әле кызларның чәченнән тарта. Бастырып, мин нәрсә сөйләдем дип сорыйсың – сөйләп бирә! Бар шундыйлар: тыңлаган булып, күзеңә карап утыра, ә уе бөтенләй башкада. Хәзер генә нәрсә әйттем, дип сорыйсың – белми. Менә шуннан килеп чыга инде күңел күзе дигән әйбер. Моны балаларга да аңлатырга кирәк. **КҮҢЕЛ КҮЗЕ ДИГӘН АЕРЫМ БЕР ДӘРЕС БУЛЫРГА ТИЕШ.** Күңел күзең күрмәсә, маңгай күзе – ботак тишеге, дигән бабайлар. Ә күңел күзе күрсен өчен тәрбия кирәк. Ата-анадан, әби-бабадан тәрбия булырга тиеш. Аллам сакласын күңел күзе сукыр җитәкчеләрдән, укытучылардан, ир белән хатыннан. Андыйлар вакыйгаларны маңгай күзе белән генә күрә, төбенә төшенә алмый, фәлсәфәсен белми – шуңа күрә зыян эшли. Олы-олы башлыкларны күрдек. Аларның күңел күзе сукыр иде. Күңел күзләре күрмәгәнгә күрә карарлар кабул иткәндә халык мәнфәгатьләрен уйламыйча хәл иттеләр. Миңа калса, зур дәрәҗәләргә куйганда, депутат итеп сайлаганда кешенең күңел күзен тикшерергә кирәк. Миһербанлы кешеме ул, әллә халыкны талый торган комсыз олигархмы? Мин үзем күңел күзе турында Коръәнне укый башлаганнан соң аңладым. Үкенү, тәүбәгә килүгә китерә күңел күзе. Күңел күзе ул – фәлсәфә.

Мәдрәсәләрдә белем алмаса да, Мәгъсүмә әбием бик укымышлы иде. Тормыштан мисаллар белән күп әйберләрне аңлата иде әби. Капкадан чыкканда: «Йөзебезгә кызыллык китерәсе булма, матри!» – дия иде. Бәетләр, мөнәҗәтләр бик күп белә, үзе дә чыгара. Курайда, гармунда, кубызда уйный, «Сак-Сок», «Сөембикә»ләрне җырлый. Театр одного актёра иде ул. Минем актёр булып китүемдә әби гаепледер дип уйлыйм. Гармунчылар авылы без. Ялына торгач, әти миңа хромка алып бирде дә, мин дә берничә көй өйрәндем. Монда тагын әби тәрбия бирде. Тавыкларга җим салып йөри иде. Мин җылы мунчада өзгәлим генә гармунны, ачуым килеп тартам – көй чыкмый! «Улы-ы-ым, интектермә инде гармунны. Бер җыр көе өйрән син, бер бию көе. Шул җиткән туй үткәрергә», – ди. Һәм ул хаклы булган. Әби әйтә иде: **«УКЫЙ БЕЛМӘСӘҢ ДӘ, ӨЕҢДӘ КОРЪӘН ТОТ – БАШКАЛАР УКЫП БИРЕР; УЙНЫЙ БЕЛМӘСӘҢ ДӘ ГАРМУН ТОТ – БАШКАЛАР УЙНАР».** Гомер буе онытмыйм шуны. Бу бит постулат!

Син кайсы халыктан дип сорарга мөмкиннәр. Шуңа әзер бул. «Татарлар менә нинди икән!» дип калырлык булсын. Аның өчен халкыңның музыкасын, җырларын, тарихын, йолаларын белергә кирәк. **БАШКА МИЛЛӘТЛӘРГӘ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ НИНДИ ИКӘНЕН СӨЙЛӘР ДӘРӘҖӘДӘ ГЫЙЛЕМЕҢ БУЛЫРГА ТИЕШ!** Биш-алты җөмлә белән үзеңнең кем икәнеңне аңлатып бир. Кайчан төзелгән беренче татар дәүләте? Безнең эрага кадәр 209 елда Кытайның төньягында беренче татар дәүләте оешкан, аның башлыгы Төмән хан булган. Улы – Баһадур. Шәҗәрәләре сакланган. Эдуард Паркер дигән автор, Кытайда яшәп, документларын өйрәнеп, татарлар турында китап язган. Китап 1923 елда русча чыккан. Искиткеч бай тарихлы без!

Кәлимулла бабам тома сукыр иде. Беренче Герман сугышыннан бер күзсез кайта. Авылда тимерчелектә эшләгәндә тимер кыйпылчыгы чәчрәп, икенче күзе дә сукырая. Шушы сукыр бабайның да тәрбиясе булды! Миңа 7 яшьләр чамасы. Бабай белән мунчага керәбез. Иң эссесенә алып бара. Шартлап ярылырдай мунча инде. Чишенә бу. «Чишен, улым. Шәҗәрәңне капла», – ди. Үзе дә чөйдән билбау алып бәйли. «Бабай, күрмисең бит, нигә каплыйм», – дим. «Мунча иясе күрә. Мунча иясе булмаса, фәрештәләр күрә. Фәрештәләр булмаса, Аллаһы Тәгалә күрә!» Менә нинди җавап. Бәйлим. Тәрбияме бу? Тәрбия! **ХИКМӘТ – ӘДӘПЛЕЛЕККӘ ӨЙРӘТҮДӘ. БУ ХАЛЫК ТӘРБИЯСЕ.** Башка мөселман илләрендә ирләр мунчага кергәндә алъяпкыч бәйли. Төрекләр, Кырым татарлары, мәсәлән.

**ТАБЫН ЯНЫНДА ЙОЛАЛАР ТУРЫНДА СӨЙЛӘШЕРГӘ КИРӘК. АНА ТЕЛЕН ДӘ, МИЛЛӘТНЕ ДӘ ЙОЛАЛАР КОТКАРА АЛА.** Хатын кеше – иренә, ире хатынына исеме белән эндәшергә тиеш булмаган. Табу. «Әтисе», «атасы», «Үзе кайткач килерсез». Бу – йоланың бер чаткысы. Хатынга беркайчан да Рузия дип әйткәнем юк: «әнисе», «карчыгым», дим. Ул да «әтисе», «атасы», дип эндәшә. Йола ул – язылмаган канун. Конституциядән дә өстен.

Атам Мөхлисулла, анам Мөкаррәмә 16 ел укытучы булып эшләгән кешеләр. Бөек Ватан сугышында әсирлеккә эләккән әтине сугыштан кайткач мәктәптән җибәрделәр. Әсир кеше совет балаларын укытырга тиеш түгел янәсе. Әсир хатыны да укытырга тиеш түгел икән – аны да эштән алдылар. Әтинең булганлыгы! Үзе умартачы, үзе балыкчы, тире иләүче, үзе күн итек ясый, олтан сала, бүрәнәләр күтәреп, мунчаны берүзе җиткерә; беркем елкы суймый – әти елкы суя. Аерым бер оешмаларга чакырып мыскыллауларга түзәлмичә, Пермь якларына эшкә чыгып китте. Бик яхшы балта остасы, ташчы иде. Үз көче белән шунда ике катлы йорт салды, «Москвич» алды, телефон кертте. Җәй саен машинасында авылга кайта иде дә, өстеннән донос язган кешеләрне сыйлый иде. Әти таш атучыларга аш белән җавап кайтарды. Әгәр үпкәсен белдергән булса, тегеләр сөенер иде. **КӨНДӘШЕҢНӘН СЫЙЛАНУ, АНЫҢ ТОРМЫШЫ ҖИТЕШ ИКӘНЕН ТАНУ КҮПКӘ КЫЕНРАК.**

**БАЛАНЫҢ ХЫЯЛЫН КҮЗӘТЕП, УКЫТУЧЫЛАР ДӨРЕС ЮНӘЛЕШ БИРЕРГӘ ТИЕШ.** Бөтен кеше дә сәләт оеткысы белән туа. Менә шул оеткыны тоя белергә кирәк. Ул оеткы нәрсәгә сәләтле? Оеткы + хезмәт = сәләт. Тырышлык аркасында кеше сәләтле була. Сәләт + хезмәт = та-

Фото: Анна Арахамия

лант. Сәләтле булып, тагын да тырышып эшләсәң, син инде талант. Хәзер тагын да күбрәк эшләргә, талантлы икәнеңне исбатларга кирәк. Менә шуннан соң син даһига, аннары инде бөеккә әйләнәсең. Бу – минем формула. Язучыларны укып, болай гына мин дә яза алам бит, дим. Яздым. Күрделәр. «Юл буенда зәңгәр чәчәк»не иң беренче Мөхәммәт Мәһдиев күреп бәяләде. Батулла бу әсәре белән татар әдәбиятында үз биеклеген яулады, диде. Хикәя Гаяз Исхакый бүләген алды.

Кайчак үзең укыган мәктәпнең исемен генә әйтү дә җитә. Зәй төбәгенең Түбән Биш авылы мәктәбендә актёр Наил Дунаев, шагыйрь Мөдәррис Әгъләм, Олимпия чемпионы, чаңгычы Фёдор Симашовлар укыды. Чын укытучылар белем бирде безгә! Математика укытучыбыз Василий Зингаров абый үзе генә дә ни тора! Математика буенча никадәр галимнәр чыкты безнең мәктәптән! Без бер мәктәптән өч малай – мин, Наил Дунаев, Хәмзә Арсланов – киттек тә бардык Мәскәүгә, бардык та кердек Щепкин исемендәге югары театр училищесына! Бик гаҗәп булды ул. Ленинград, Мәскәү мәктәпләрен алтын медальгә бетергән укучылар үлә-бетә имтиханга әзерләнә, ә мин Дунай белән кәрт сугам. Бөтенесе аптырый. Безнең борыннар югары. **АГАЧ МӘКТӘП КАЙЧАК КАЛАНЫҢ ТАШ МӘКТӘПЛӘРЕННӘН ӨСТЕНРӘК БУЛА.** Безнең мәктәп университет булган! Академия театрына биш спектакль белән кайттык. Ике ел эпизодларда актёр, аннары режиссёр булып эшләдем, 25 спектакль куйдым. «Йомычкачылар» – щепкинчыларны шаяртып шулай йөртәм – мине әйбәт актёр иде диләр, үзем алай санамыйм. Театрга Батулла җитми дисәләр, кире кайткан булыр идем. Мин язучылыкка киттем.

Татар бар җирдә хәтәр бар, диләр. Тамырыннан ялгыш гыйбарә. Хәтәр – сугыш, куркыныч бар дигән сүз. Ә мәкаль буенча кайда татар, шунда начар дигән бәя тагылган безгә. Хәтәр бар җирдә татар бар – монысы дөрес. Сугышлар барган җирдә татарлар гел алгы сызыкта бит. Беренче, Икенче бөтендөнья сугышларында, Әфганда, Чечняда татарлар күпләп кырылды. БАМда, КамАЗда булсын, бөтен авыр эшләрдә татарлар иде. Илһам Шакиров белән Урта Азиядә концертлар куеп йөрдек. Шунда күрдек: Кырым татарлары белән Казан татарлары агу чыгара – Чирчикта таудан терекөмеш агып чыга. Анда яшәүчеләрнең гомере 40–50 ел нибары. **ХӘТӘР БАР ҖИРДӘ ТАТАР БАР!**

«Сак-Сок» бәете – әдәбиятыбызның, тарихыбызның, музыкабызның башлангычы, безнең төп умырткабыз, иң беренче әдәби-музыкаль әсәребез. Ул гаиләдә, балалар бакчасында, мәктәптә, институтларда, аспирантурада өйрәнелергә тиеш. Безне «Сак-Сок» бәете тәрбияләп үстерде. Ана әйтә, «минем сүздән чыкмагыз», ди. Ана тәрбияләргә, җәза бирергә хокуклы, ләкин каргарга тиеш түгел. Каргыш үз башыңа төшә. Бүгенге көндәге проблемалар монда. Бер тимер ук өчен ике игезәк бала сугыша. Аналары, күзем күрмәсен сезне, дип, боларны каргап, очыра. Ике кошка – Сак белән Сокка әйләнеп, очып китә малайлар. Аталары кайткач, «кайда балалар», дип сорый. «Мин аларны каргап очырдым», ди хатын. Ата бәхетсез, ана бәхетсез, ике бала бәхетсез. Кире кайта да, үзара күрешә дә алмыйча, караңгы салкын урманда яшәргә мәҗбүр алар. Нинди каргыш! Беркем ала алмый каргышны! Урман иясе дә, Тәңре дә, Аллаһ та ала алмый! Чөнки ана кеше Аллаһны белми. Бу – матриархат чоры әсәре. Бәет исламга хәтле үк иҗат ителгән булырга тиеш. Чөнки Алла сүзе юк. Исламны кабул иткәннән соң бөтен әсәрләр дә Аллаһны мактау, мәдһия белән башланырга тиеш булган. Ана үзе алиһә: каргый белә, көчкә-сихергә ия. Мәүлет айларында абыстай кайтып киткәч, әби шушы бәетне курайда уйнап сөйли иде безгә. Менә нинди тәрбия! Бүгенге көнгә язылган әсәр! Башка халыкларда юк бит ул! Әсәрләр иҗат итәргә, балет куярга, опера язарга, картиналарда күрсәтергә кирәк. **«САК-СОК»НЫ БЕЛМӘГӘН КЕШЕ ҮЗЕН ТАТАР ДИП САНАРГА ТИЕШ ТҮГЕЛ.**

Нәрсә ул картаю? Чәч агару, җыерчыклар чыгу яисә аксап йөрүме? Чәч агару картаю түгел: 18 яшьтә дә агарырга мөмкин ул чәчләр. Чәч коелу, шәп-шәрә баш калу да картаю түгел әле: чәч иртә дә коелырга мөмкин, ракета гаскәрләрендә хезмәт итүчеләрнең, мәсәлән. **КАРТАЮ ГАЛӘМӘТЕ – ЧӘЧ АГАРУ ДА, ЧӘЧ КОЕЛУ ДА ТҮГЕЛ, ШУЛ КАРТАЮНЫ ЯШЕРЕРГӘ ТЫРЫШУ УЛ.**

Шүрәле тискәре образмы, әллә уңаймы, дип сорыйм балалардан. Нәрсә әйтергә белмиләр, ык-мык килләр. Укытучылары Шүрәленең архи-уңай образ икәнен аңлатмаган. Былтыр дигән кеше ни өчендер айлы төндә ат җигеп бояр урманына бара. Нәрсә, көндез ярамаганмыни барырга? Браконьер ул, караклыкка бара, бушка гына үзенә төяп кайтырга... Шунда Шүрәле килеп чыга. Курыкканга – куш, койрыгы белән – биш! Урлашканда Шүрәле дә куркыныч булып күренә. Юлчыларны кытыклап үтерәм, ди. Үтерми. Ул шаян. Куркытыр өчен әйтә! Мантыйк буенча, Былтыр – браконьер, Шүрәле – табигать сакчысы. Рәссамнар Шүрәленең асылын, Тукайның әсәрен аңламаганнар. Бакый Урманченың Шүрәлеләре күп: шундый сөйкемлеләр, матурлар, шаяннар! Туфан Миңнуллинның «Җанкисәккәем» спектаклендә дә урманда – Шүрәлеләр, авылда кызлар яши. Алар дуслашалар. **СӘНГАТЬНЕҢ МИССИЯСЕН АҢЛАТА БЕЛҮЧЕ УКЫТУЧЫЛАР КИРӘК БЕЗГӘ!**

Улларым Нурбәк белән Байбулатны татарга хезмәт итсеннәр дип үстердем. Икесе дә хореография училищесын тәмамлады. Нурбәк – бию сәнгатендә, Питерда балетмейстерлар курсларында укыды. Байбулат – кино сәнгатендә. Мәскәүдә кино мәктәбен тәмамлады, кинорежиссёр. Ул бик күп кыска метражлы фильмнар, СТС кинокомпаниясе заказы буенча Россия футболы турында 17 серияле «Большая игра» фильмын төшерде. «Сокращение» фильмы гел конкурсларда, фестивальләрдә йөри. Мин дә, әниләре дә һич тә аларның сәнгатькә китүен теләмәдек, ләкин **ТЕЛӘККӘ КАРШЫ БАРЫП БУЛМЫЙ.** Икесе дә рус мәктәбен тәмамладылар, татарча укыйлар, татарча сөйләшәләр, татарча уйлыйлар. Оныкларның да телләре татарча ачылды.

Эльмира ЗАКИРОВА әзерләде.



« Тулысынча укыгыз

# ТУГАН ҖАНЛЫЛЫК



**Минем әнием Хәтимә, мөгаен, башкалардан әллә ни аерылып та тормыйдыр – гап-гади авыл хатыны ул. Беренче карашка аерылмыйдыр...**

А...Авылда урамнан барган бала-чаганы да туктатып сөйләшү: «Кая киттең әле?» – дип сорау гадәте бар бит.

– Әбиләргә!

...Үзебез яшәгән Түбән очтан Югары очка йөгергәндә: «Әбиләргә», – дигән сүзне ничәмә-ничә тапкыр кабатладык икән без?! Әле студент чагымда да телемдә бар иде ул сүз. Әни шулай өйрәтте: «Әбиләреңә барып килегез әле», – дия иде. Югыйсә Минҗиһан әбине беребез дә күреп белмибез...

Кыска гомерле була ул – яман шеш авыруы аны 48 яшендә үк алып китә. Сугышларны кичеп кайткан Нуретдин бабабыз бер кочак бала белән кала. Төпчек кызы Назирәнең беренче класска укырга барган елы гына була әле. Бабай: «Өйдә башка хатын-кызны күз алдыма да китермим... Кемне алсам да, балалар өчен ул инде үз әниләре булмаячак», – ди. Шулай итеп, башкага өйләнми. Олы улы – Гыйльметдин инде Чаллыга китеп эшкә урнашкан була. Иң кечкенә сеңлесен ул: «Әйдә, минем янда укырсың», – дип, үзе белән шәһәргә алып китә. Башта ризалашкан кебек булган бабай, бераздан: «Артык балам юк», – дип, кызын кире алып кайта.

Ә әнигә бу вакытта 19 яшь. Безнең Питрәч ягында – Шәледә һәм аның тирәсендәге авылларда кыз урлау гадәте булган элек. Әни белән әти икесе дә Чытыда туып-үсәләр дә, егет белән кыз кебек моңарчы очрашып, озатышып йөрмәгәннәр. «Мин әтиегезне бөтенләй белми дә идем», – ди әни. Ә әти белгән, күз салып йөргән, күрәсең – бер кичне ул 18 яшьлек әниебезне урлап китә. Менә шулай яңа гаилә оеша. 19 яшендә әни инде үзе әни булган – мине тапкан. Аннан озак та тормый әби үлеп киткән... Һәм безнең яшь-яшь әниебез ике йорт өчен җаваплылыкны үз иңнәренә алган. Үземне белә-белгәннән хәтерлим: нәрсә генә пешерсә дә, әни аны төреп, башта бабайга, туганнарына илтә иде. Соңрак ике арада без – балалар йөри башладык. «Суынганчы алар авыз итмәсә, күңелем булмый», – дия иде әни. Әти дә гел сорап кына тора: «Менгездегезме?» «Гарәфетдин белән тормышта төрле хәлләр булды, әмма ул беркайчан да, туганнарыңны карыйсың, аларга булышасың дип, мине битәрләмәде», – дигән сүзләрне әни гомер буе сөйләде. Әтигә мең рәхмәтле булып сөйләде...

Миңа кайчак әнинең балалары өчәү – мин, сеңлем һәм энем генә түгел, ә без бертуганнар бик күп кебек тоела. Аның абыйсын һәм эне-сеңелләрен кушсаң – унау! Әни һәрвакыт аларның туганнары – әни урынына калган апалары булды: тыңлаучы, юатучы, киңәш бирүче, шатлыкларын уртаклашучы... Энесе Галәметдин абыйның безгә төшеп, әнигә: «Мин бүген кыз алып кайтам!» – дигәне бүгенгедәй истә. Туганлыкның бөтен нәрсәдән өстен икәнен кечкенәдән шулай күреп үстек.

Безнең бабай гомере буе кибетче булып эшли, склад мөдире була. Әнине дә үз янына ала – эшкә өйрәтә ул. Һөнәрле итә! Райпо кибетләре ябылганчы сәүдә системасында эшләде әни. Аннан инде колхоз эшенә чыкты. Безне ул беркайчан узындырмады, иркәләмәде, эшкә өйрәтеп үстерде. Ул да, әти дә гел: «Эшләгәнегез безнең өчен булса, өйрәнгәнегез үзегез өчен», – дип кабатладылар. Нәрсә сорасак та: «Үзегез эшләп алыгыз», – диделәр.

Әни белән әти бик матур яшәделәр. Әти укырга ярата иде. Без кайтышка өстәлгә бер кочак китап, газеталар куя – кайсы битен ачарга икәне күрсәтелгән була. «Балалар, сез боларны укырга тиеш», – ди. Татар теленә – әдәбиятка тартылуым аңардан килгәндер. Мин холкым белән дә әтигә якынрак. Ә әни – башка! Мәсәлән, мин аның беркайчан елаганын – безгә күз яшен күрсәткәнен күргәнем булмады. Елагандыр ул, тик безнең алда түгел. Андый чакта тышка чыгып китә иде ул... Әтинең күңеле күпкә йомшаграк иде. Әнине исә язмыш сынаулары яшьли ныгыткандыр...

Безнең әнинең белмәгән эше юк бугай аның. Бүген дә гөрләтеп бакчасын үстерә. «Әни, җиде дистәне тутырасың бит инде, кечерәйтик азрак», – дип карыйм. «Бакча буш торырга тиеш түгел», – ди ул башка сүз әйтергә урын калдырмаслык итеп. Йон эрләп бирмәссеңме, Хәтимә апа, дип бөтен авыл аңа килә. Эрли! Оекбаш бәйләү – аның яраткан эше: безгә, безнең балаларга, туганнарына, аларның балаларына, оныкларына... Әти исән чакта җәен икәүләп мәтрүшкә җыярга чыгып китәләр иде. Күз җитсә – гөмбәгә. Аннан – баланга!

Өч баланың берсе – мин генә төп йорттан еракта яшим. Кияүгә чыккач, торырга иремнең туган ягына – Әгерҗегә кайттык. Кунакка килгәч, әти белән әни миннән түгел, иң элек аңардан сорыйлар иде: «Айзат улым, хәлең ничек? Ничек яшисез?» – диләр. Эшем гел командировкалар белән бәйле булды – юлдан кайтып кермим. Ә алар: «Кызым, син ничек йөрисең?» – димиләр, «Кияү, ничек түзәсең?» – диләр. Телефоннан сөйләшкәндә дә, иң элек аның хәлен белешәләр: «Кияү ничек, эштән кайттымы?» Аптырый идем моңа, яши-яши генә аңладым: бигрәк зирәк булганнар...


Әти ике ел элек, авырып, вафат булды. Әни үзе генә калды. Чакырсак та, беребез янына да килми: «Нигезне калдырмыйм», – ди. Хәер, бөтенләй үзе генә түгел ул. Энесе Галәметдин абый үзләренең төп йортлары урынына яңа өй күтәрде: безгә – аларның, аларга безнең тәрәзәләр күренеп тора. Әни атнага бер тапкыр аларга менеп төшми калмый. «Уты күренми, Хәтимә апа нишли икән?» – дип, абыйның хатыны Дамирә апаның да күзе гел тәрәздә. Нинди күмәк эш булса да, бергә эшлиләр – шулай канга сеңгән.

Әнинең алты туганы (энесе Фәләхетдин 1991 елда юл фаҗигасенә очрап, вафат булды) өчен безнең йортның капкалары һәрвакыт ачык. Туганнар барысы да кайтып йөри: сеңелләре Әлфия, Әлфинур, Назирә апалар, аларның балалары, кияү-киленнәре. Әни өчен инде алар җаннарын да ярып бирергә әзерләр... Туган җанлылыкка чын үрнәктер безнең әни. Энебез Рамил авариягә очрап, озак вакытлар хастаханәдә ятты. Аны аякка бастыручы кеше сеңлем Ләйсән булды. Без дә әни кызлары...

Балачактан, яшьлектән ераккарак киткән саен, яхшырак күренә – бәхетле гаиләдә үскәнбез.

Вәсилә САФИУЛЛИНА,
Әгерҗе районының мәгариф идарәсе җитәкчесе.





Илсөя ЗАҺИРОВА – табиб-педиатр, инфекционист, паразитолог, нутрициолог, бөтен гаилә өчен детокс-чистарыну программалары белгече

Күп авыруларның дөрес тукланмау белән бәйле булуын көндәлек эшемдә исбатларга туры килә миңа. Шунысын искәртергә кирәк, пациентлар арасында үз балаларым да бар. Аллергия, дерматит, иммунитетның түбән булуы, озак вакыт йөткерү, томау төшү кебек еш очрый торган авырулар – баланың сәламәтлегенә турыдан-туры йогынты ясый торган чирләрнең берничәсе генә. Алар барысы да туклануга бәйле. Кызганыч, витаминнар һәм минералларның җитмәве бүген өлкәннәрдә дә, балаларда да эпидемиягә тиң. Вакытында һәм даими рәвештә рационны дөрес продуктлар белән баетмасак, организм пазл кебек тарала башлый – башта бер витамин җитми, аннары икенчесе, шулай итеп, минералларга кытлык башлана. Нәтиҗәдә, төрле авырулар калкып чыга: шикәр авыруы, ревматоидлы артрит, подагра, калкансыман биз авырулары кебек гормональ тайпылышлар...

Бүген югары концентрацияле витаминнар куллану – зарурлык. Замана кешесенең организмы чистарынуга, иммунитетын ныгытуга һәм көндәлек рәвештә файдалы матдәләргә мохтаҗ. Менә шуңа күрә Эмизны һәркемгә киңәш итәм.

Безнең гаиләдә Эмизны олылар да, балалар да эчә. Эмиз – полифинол буенча чемпион дип әйтер идем. Анда бик көчле табигый антиоксидантлар бар. Алар виноградның җимеш йомшагыннан гына түгел, кабыгыннан, төшләреннән, тармагыннан ясала. Нәкъ менә виноградның сөягендә һәм тармагында полифинолларның һәм B, A, E, K, C витаминнарының иң зур концентрациясе тупланган. Эмизда спирт юк, ул әчетмичә ясый торган технологияләр ярдәмендә җитештерелә. Кырымның экологик чиста районнарыннан кул белән сайлап җыелган йөзем, чыннан да, игътибарга лаек. Эмизның составында шикәр һәм консервантлар юк. Эмиз ясау технологиясе барлык витаминнарны, минералларны, полифенолларны саклап кала.

Эмизның шундый бай составы организмның кан һәм бавырны чистарту үзлекләрен эшләтеп җибәрә. Токсиннар, шлаклар чыгарыла, кан тамырлары чистара, аларның сыгылмалылыгы, кан йөреше яхшыра. Полифенолларның күзәнәкләр алмашына уңай йогынтысы нәтиҗәсендә, кеше авырган очракта да тизрәк аякка баса.

2022 елда «Эмиз» сәүдә йорты» эчемлекләре иң яхшы продукт дип табылды һәм «Проэкспо» халыкара күргәзмәсендә «Азык-төлек товарлары» номинациясендә алтын медаль яулады. Шулай ук «Татарстанның иң яхшы товарлары һәм хезмәтләре» исемлегенә кереп, Россиянең иң яхшы йөз товары лауреаты булды.

«Эмиз» сәүдә йорты» «Хәләл» стандарты нормалары һәм таләпләренә туры килү сертификатына ия.

**МАХСУС ТӘКЪДИМ – ИКЕЛӘТӘ ФАЙДА!**

**Алты шешә ЭМИЗ Таврический (0,75 л) алсаң,**

**унике шешә BAZR лимонады – бүләккә**

~~12 400 р~~

**7200 р**

**www.emiz.ru**

Адрес: Казан шәһәре, Ю. Фучик урамы, 52 а йорты, телефон 8-800-444-09-37

РЕКЛАМА













РАМАЗАН АЕНДА
ЭЧКЕ ЧИСТАЛЫККА ИРЕШ
РЕКЛАМА
ЭМИЗ
EL'SA
ЭЛИКСИР
ЭМИЗ
Премиум
Концентрированный безалкогольный продукт, содержащий полифенолы винограда 45 г/л для энотерапии
ЭМИЗ
Таврический
ЭМИЗ
премиум



# БЕЗ – КҮҢГӘРНЕКЕ!



Лилия
ГӘРӘЕВА

Бүгенге заманда күрелгән хәлмени – Күңгәр авылында балалар бакчасына чират! Шәһәр яки район үзәге булса, болай аптырамас та идең. Бакчаны төзегән вакытта авылда моның кадәр күп бала туар дип уйламаганнар, күрәсең. Ә Күңгәргә ләкләкләрнең бер генә елны да килми калганнары юк. 2012 елда – җиде бала, 2013 елда – алты… 2018 елда – сигез бала туган. Узган ел гына да ләкләкләр биш тапкыр килеп киткән бу авылга.

Күңгәр – кызык авыл икән ул! Юлны өйрәткәндә безгә шулай аңлаттылар – Югары Шашыларның бәрәңге бакчалары Түбән Шашыларның бакчасына терәлә. Мәктәп чатыннан сулга киткән урам Түбән Шашы булса, уң кулдагысы – Күңгәрнеке.

Без Түбән Шашы дигәненә, Гөлгенә һәм Рафил Сибагатуллиннар гаиләсе яшәгән йортка килдек бүген. Әле үзләре белән танышканчы ук, авылдашларының алар турындагы җылы-матур сүзләре килеп ирешкән иде инде.

### *Рафил*

1989 елгы ул. Үзе дә шушы Күңгәр авылы егете. Бабасы Рәфкать Сибагатуллин – «Искра» колхозының Ленин орденлы беренче тракторчысы була.

– Гаиләбездә укытучылар юк иде. Әтием Фәрит – механизатор, әнием Фәридә бухгалтер булып эшләде. Мин дә алай, үскәч, укытучы булырмын дип уйламадым, – ди Рафил. – Хәтерлим әле, башлангыч классларда укыганда укытучыбыз Җәүһәрия апа Вәлиева: «Киләчәктә кем булырга телисез?» – дигән сорау биргән иде. Класстагы алты малайның бишесе, торып басып, шофер булабыз, диделәр. Ә мин: «Апа, мин колхоз рәисе булам. Менә бу шоферларга эш бирәм!» – дидем. Шофер булам дигән шул биш классташның берсе генә шәһәргә китте, калганнарыбыз бар да авылда төпләндек.

Унберенче классны тәмамлаган яшь егет сайлау алдында кала. Кем булырга, нинди һөнәр алырга? Әле аларын төгәл генә күзаллавы булмаса да, бер нәрсәне тәгаен белә – ул шәһәрдә яшәмәячәк! Шуңа күрә алган белеме дә авылда яшәү өчен кулай булырга тиеш!

– Авылда калыр өчен укытучылыкка киттем дә инде, – ди әңгәмәдәшем. – Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогика көллиятендә укыдым. Спортны кечкенәдән ярата идем, физкультура укытучысы булам, дидем. Авыл балалары кечкенәдән спортта бит алар, – дип елмая Рафил. – Авылда атлетиканың авыр төре белән дә, җиңел төре белән дә шөгыльләнеп үсәсең.

Рафил Сибагатуллинның хезмәт кенәгәсендә бары ике генә язу. Беренчесе – 2010 елда Күңгәр урта мәктәбенә физик культура укытучысы итеп эшкә алынганлыгы турында. Икенчесе – 2018 елда язылганы. Ул елны мәктәпнең элеккеге директоры Наил абый Габидуллинны хөрмәтләп лаеклы ялга озатканнан соң, эстафета таягын Рафил кабул итеп ала. Менә шул көннән бирле шушы мәгариф учагына ялкын өстәп торучы ул.

– Күңгәр мәктәбе – элек-электән үк Әтнә районындагы иң атаклы мәктәпләрнең берсе булды, – дип сөйли директор. – Аны 1966 елда бөтен республикага билгеле Фәйзи ага Галиев төзеткән. Фәйзи ага – районыбызның легендасы. Заманында ул җитәкләгән «Искра» колхозы республикадагы иң беренче миллионер колхоз була. Аның тырышлыгы белән безнең як авыллар инде 1980 нче еллар башыннан ук газ яга. Хәзер колхозыбыз аның исемен йөртә.

«Колхоз» дигән сүзне укыгач, гаҗәпләнмәгез. Әтнә – күмәк хуҗалыкларны саклап кала алган районнарның берсе. Биредә инвесторлар юк. Һәр хуҗалык үз җирен үзе чәчеп, уңышын үзе җыя. Терлек фермалары да ябылмаган. Озак еллар Әтнә муниципаль районын җитәкләгән Габделәхәт Хәкимов тырышлыгы монысы. Бу район көненә 320 тонна сөт тапшырып, республикада сөт буенча икенче урында тора.

Бәлки, әнә шул колхозлар таралмаганга Әтнәдә авыллар шулай ныктыр? Әле санап утырдык, Күңгәрдә генә дә яшь гаиләләр саны егермедән арта икән. Ә яшьләр – авылларның терек суы ул!

> *Телне гаилә генә саклый алмый. Телне мохит һәм ихтыяҗ саклый. Татар авылларында телебезне яшәткән мохит тә, аңа ихтыяҗ да бар әлегә.*

– Күңгәр мәктәбендә 107 бала укый, шуларга минем белән кушып 18 педагог белем бирә, – дип, әңгәмәбезне дәвам итә Рафил Фәритович.
– Тугызынчы сыйныфтан соң безгә тугыз авылдан балалар җыела. Укыту, тәрбия татар телендә алып барыла.

Сүз уңаеннан әйтеп үтик әле, журналист, «Юлчы» проектының авторы һәм алып баручысы Альберт Шакиров, талантлы шагыйрә Гөлүсә Батталова, җырчы Азат Фазлыев, атаклы көрәшче Рафил Әхмәтхановлар да Күңгәр мәктәбен тәмамлаучылар. Бер мәктәптән соңгы вакытта гына шуның кадәр шәхес чыккан икән, димәк, чынлап та мактанырлык урын бар монда. 2014 елда ул Республикада «Иң яхшы авыл мәктәбе» дигән исемгә лаек була. 2020 елда Мәктәп волейбол лигасы ярышында күңгәрлеләр беренче сезонда ук җиңү яулап кайта. Авылдашлары да әйтеп тора, коллегалары да раслый: биредә, чынлап та, спортка хөрмәт зур. «Яшерен-батырын түгел, элек физкультура, тормыш иминлеге дәресләренә чын фән итеп карамадылар. Ә Рафил аны чын фән дәрәҗәсенә күтәрә алды», – ди алар. Хәзер әнә мәктәп укучылары гына түгел, авыл яшьләре дә волейбол белән «җенләнә». Җиңгән өчен командага бирелгән акчаларны өй шартларында укучы балаларга өләшәләр. Авыл егетләренең уртак инициативасы ул. Волейбол ярышларына әзерләнүдә абыйлы-энеле тренерлар Илдар һәм Надил Әхмәтовларның роле бәяләп бетергесез.

### *Гөлгенә*

«Ул – безнең коткаручы фәрештәбез!» – ди аның турында авылдашлары. Авылдашлары гынамы соң, райондашлары дип әйтү дөресрәк булыр. Ә бит үзенә нибары 29 яшь кенә әле аның.

Гөлгенә дә шушы Күңгәр авыл җирлегенә караган Түбән Шашы авылыннан. Резеда апа белән Фәрхат абый Сәгъдиевләрнең төпчеге ул. Гел «биш»ле билгеләренә генә укып, мәктәпне алтын медальгә тәмамлаган

PRESSA








кызның сайлаган юлы билгеле. Ул табиб булачак! Үзләрендә ничә еллар эшләгән тәҗрибәле, белемле, шифалы куллы Нәҗия апасы кебек!

– Бик ярата идем Нәҗия апаны. Кечкенәдән үк аның кебек, ак халатлы табиб булам дип хыялландым, – дип сөйкемле елмая Гөлгенә. Табиб белеме алмаган булса да, шушы бер елмаюы белән генә дә дәвалый алыр иде ул кешеләрне. Аллаһы Тәгалә туганда ук аны табибә булырга яралткан. Тавышында – йомшаклык, күңелендә – шәфкать, ә карашында тәвәккәллек, кыюлык бар бу кызның.

Укуны гранит ташны кимерүгә тиңлиләр. Уку – энә белән кое казу, диләр. Әйе, кайсы белем дә тырышлык белән генә бирелә, ләкин медицина университетында уку?! Татар мәктәбен тәмамлап бит! «Мәктәптә татарча укып, институтларга кереп булмас», – дип фикер йөрткән әти-әниләр өчен монысы.

Казанда нинди генә яхшы клиникаларга чакырсалар да, ул эшкә авылга – Әтнә район үзәк хастаханәсенә кайта. «Сырдарья Имамиевна кайтты!» – дип каршы алалар яшь белгечне. Сырдарья Измайлова – Татарстанның атказанган табибәсе, Әтнә хастаханәсендә бик озак еллар эшләгән тәҗрибәле терапевт. Үзен әнә шундый легендар шәхескә тиңләүләре Гөлгенәгә бер яктан канатлар куйса, икенче яктан җаваплылык та өсти.

– Бездә гаҗәеп кешелекле табиблар эшли, – дип, эшен яратып та, беркадәр сагынып та (әлегә ул декрет ялында – *авт.*) искә ала яшь ханым. – Һәрвакыт, һәр адымымда, һәркем ярдәм кулын сузарга гына тора. Авыруны кабул иткәндә, нидәндер шикләнеп, үземнән тәҗрибәлерәк табибны чакырсам, белеп торам – юк димәячәк. Төнлә икән, төнлә булса да килеп җитәчәк.

Ординатурада укыганда Казанның «Рубин» клубында тәҗрибә узарга туры килә Гөлгенәгә. Анда яшь, сәламәт спортчылар. Булса, шул травмалар, имгәнүләр генә була ала. Ә андый гына чирләрне дәвалавы артык катлаулы түгел. «Кал, – диләр аңа, – районда ни бар анда?» «Анда – үземнекеләр!» – дип, кабул иткән карарында нык тора яшь табибә. Үземнекеләр!

Табиб кеше – кайда да табиб. Ял итәме ул, бәлеш сала яки кунакта чагымы – биргән антына ул һәрчак тугры. Авылдашлары аны, безнең фәрештәбез, дип йөртә дип язуым буш сүзләр түгел. Температурам бар, йөткерәм яки йөрәк чәнчә дип кенә авыл халкы эшен ташлап хастаханәгә китми. Ул күршедәге Гөлгенәгә керә. Авырыксынмый Гөлгенә – карый, тыңлый, киңәшләрен бирә... Балалар авырып китсә, өйләренә үзе бара. Үзенекеләр бит!

Мунчада юынып ятканда беркөн ишек шакыйлар. «Гөлгенә, иремә кинәт кенә нидер булды: шабыр тиргә төшеп, хәле китте», – дип инәлә бер авылдашы. Өстенә халат кына кия дә, сумкасына кирәкле даруларын салып, аның артыннан йөгерә Гөлгенә. Авыруга бер карау белән хәлнең җитдилеген аңлый – инфаркт! Шундук ашыгыч ярдәм чакыртыла, Гөлгенә иң беренче күрсәтелергә тиеш булган ярдәмне күрсәтә. «Бәхетегез! Ярты сәгатькә генә соңарган булсагыз да, сезне исән алып калып булмас иде», – диләр авыруга Казан табиблары. Йокларга ятканда телефонының тавышын тагын да көчәйтеп ята хәзер Гөлгенә. Авыр очраклар күбесенчә төнлә була.

– Ковид вакытында ярый әле авылыбызда Гөлгенә булды. Нишләр идек без ансыз? – ди күрше апалары. – Өйдә дәвалап булырлык булса, өйдә дәвалады. Хастаханәгә салырга кирәксә, ашыгыч ярдәм чакыртты. Рәхмәтебез чиксез аңа, исән генә була күрсен!

## *Гаилә*

Яшь укытучы Рафил беренче елын мәктәпкә эшкә кайтканда Гөлгенә әле 11 нче сыйныфта гына укый. Гыйшык уты кайсысының күңеленә беренче төшкәндер – Рафилнекенәме, Гөлгенәгәме? Ләкин Гөлгенә мәктәпне тәмамламый торып, хисләрне беркемгә дә сиздердем юк! Бары әнисе Резеда апа гына сизенә. Кызының тәртипле, инсафлы, яхшы нәсел баласы белән дуслашуына сөенә ул, билгеле. Гөлгенәнең әтисе Фәрхат абый да гомер буе балаларга белем биргән кеше – физика укытучысы. Ике укытучыга – кияү белән бабайга уртак телне табуы кыен булмый.

Алты ел очрашып, бер-берләрен тәмам өйрәнгәч кенә, 2016 елның август аенда Сибагатуллиннар йортына килен төшә. Кыз сорарга барган көнне үк ике як әти-әни үзара килешәләр: «Безнең күршедәге урын буш. Шунда йорт салырлар».

Ир-егет йорт салырга, агач утыртырга, малай үстерергә тиеш, диләр бит.

Йортын менә дигән итеп салган Рафил. 180 квадрат метрлы, керсәң – чыгасың килмәслек гаҗәеп матур аларның яшәгән өйләре. Агачын да утырткан. Берне генә дә түгел! Күңгәрне яратучы тегә ләкләк тә ике тапкыр килеп киткән инде аларга.





Икесендә дә малай алып килгән! Олы уллары Вахит, кечесе Гадел. Гаделләренә әле алты гына ай.

– Исемнәрен үзем куштым, – дип, горурланып әйтә Рафил. – Мәгънәле, матур исем булсын дип сайладым.

4 яшьлек Вахит инде хәрефләрне таный, саннар белә. Белмичә, кем баласы соң ул!

– Безнең Рафилнең дүрт өе бар, – ди Гөлгенә, ирен район сессиясенә озатып, үзебез генә калгач. – Берсе – үзебез яшәгәне, берсе – мәктәп, икесе – безнең әти-әниләрнеке.

– Улым, безнең өйдә ватылган әйберләрне кем төзәтә әле? – дип сорый дәү әниләре Вахиттан.

– Әти!

Сабыйның шушы өч аваздан гына торган бер сүзендә никадәр горурлык яңгыраганын ишетсәгез иде сез!

Икесенә өч кызыл диплом Гөлгенә белән Рафилнең. Мәктәптә эшли башлагач, урта һөнәри белем генә җитмәсен аңлаган Рафил Казан федераль университетына кабаттан укырга кереп, аны да кызыл дипломга тәмамлап чыга. Гөлгенә исә медицина университетын кызыл диплом белән тәмамлый. Белемнәре генә түгел, тормышлары да, эшләгән эшләре дә «биш»лелек бу гаиләнең.

### *Авыл*

Авылда яшәп калган гаиләләргә бирелүче иң баналь сораудыр инде – авылда калганыгызга үкенмисезме?

– Кая ул, нинди үкенү?! – ди әңгәмәдәшләрем икесе бертавыштан.

– Казанга сессияләргә барганда гына да тизрәк авылга кайтасы килә иде минем, – ди Рафил. – Үзебезнең фермалар янына кайтып җитеп, җилләреннән авыл исен сизгәч, яшәү клапаным ачылган кук була.

– Авылыбыз бигрәк матур бит, – дип, иренең сүзләрен куәтли Гөлгенә дә. – Атау дип аталган бик матур плотинабыз бар. Эштән арып киткән чакларда берәр сәгатькә шунда барып утырсаң, тәнеңнең һәр күзәнәгенә рәхәт бер энергия сеңә. Шәһәрдә шундый матурлык, шундый иркенлек, шундый һавалар бармыни?!

Мәктәп белән танышырга кергәч, каршыдагы алмагачларга, карлыган куакларына сокланып узган идек. Язын ничек матур буладыр монда!

Мәктәпнең биш гектар җире бар икән. Гомер-гомергә сазлыклы булган шул урынны сукалатып, киптерү өчен канаулар казытып, печән чәчтергән Рафил. Әлбәттә инде, күмәк хуҗалыкның да ярдәме зур булган бу эштә. Чабып-киптереп, тыгызлап төрелгән печәнне һәр укытучының өенә кадәр китереп бирәләр хәзер. Мал-туар асраган укытучыларның печән әзерләү кайгысы калмаган.

Күңгәрне язын ак чәчәкләргә, күзен хуш искә күмгән элеккеге алма бакчасы бик картайган булган инде. Авыл яшьләре шул агачларны төпләп, яшь үсентеләр утыртканнар. Бердәмлек тау күчерә, диләр бит. Зират чистарту өмәләрендә дә утыздан ким җыелмыйлар. Авыл кырыендагы плотинаны да кемдер килеп чистартыр әле дип көтеп ятмыйлар. Узган ел 50–60 капчык чүп җыйганнар шул тирәдән.

Берара Рафил авыл Сабан туе комиссиясен дә җитәкли. Бүләк җыюдан башлап, мәйдан кору, уеннар оештыру, бәйрәм узгач барысын да кабаттан җыеп алу өчен шушы комиссия җаваплы. Әле соңгы ике елда гына рәислектән баш тарткан. «Рәис булмаса да, Сабан туе алдыннан кайтып та кергәне юк», – ди өйдәгеләр.

– Иртәгә Сабан туе дигән көнне балалар бүләк җыя. Бездә «Байлар өйдәме?» дип атала ул. Капка төбеннән карап торам. Безнең Яшьләр урамының башыннан ук тотынып, урам тутырып 250–300 бала килә. Зурраклар да бар, апасы яки абыйсы җитәкләгәне дә, бала арбасына утырганы да... Артларыннан җигүле ат килә. Аның да арбасы тулы бала. Болар бит барысы да шушы үзебезнең җирлектә туып-үскәннәрнең балалары. Алар барысы да авылда яшәп калган булса, бүген мәктәбебездә 107 бала түгел, 300 бала укыр иде, дим, – ди Рафил.

Авылда яшьләрнең аз калуына да, мәктәпнең укытучылар коллективы олыгая баруга да, яшьләргә авылда эшләргә эш урыннары аз булуга да күрсәнә ул. Яшьләрне авылда калдыру өчен өстәмә дәүләт программалары булса, кече бизнесны үстерү өчен шартлар тудырылса, читкә китүчеләр сирәк булыр иде, ди.

Бүген өч студентлары педагогика юнәлешендә белем ала. Кире үзебезгә кайтыгыз дип, максатчан укыталар икән аларны. Тик өч укытучы гына кадрлар мәсьәләсен хәл итә алмый. Киләчәктә рус теле, математика, химия-биология, физика укытучылары да кирәк булачак.

...Безнең Күңгәргә тагын бер киләсебез була әле. Бу юлы инде Вахит турында, аның авыл өчен куйган тырышлыгы турында язарбыз. Без аңа шулай дип сүз бирдек.

«Балаларыгыз авылда калабыз дисәләр?» дигән соравыбызга: «Ә без аларны шулай дип үстерәбез дә!» – дип җавап бирде бит әти-әниләре!



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз. Фото һәм видео: Анна Арахамия.

PRESSA



# ТАТАР ЯУЛЫГЫ

Алсу КӘРИМОВА

**Татар хатын-кызы тормышында яулык – алыштыргысыз аксессуарларның берсе. Аш-су янында кайнашамы, кеше арасына чыгамы, намаз укыймы – аның башында яки иңендә һәрчак яулык булыр. Һәр очрак өчен аерым ул: төсе, бизәге, фасоны үзгә. Яулык татар кешесе өчен гадәти аксессуарларның берсе генә түгел, ул символик әһәмияткә дә ия. Еш кына ерак сәфәрдән кайтканда ирләр – хатыннарына, буй җитеп килгән кызларына; егетләр сөйгән ярларына, әниләренә бүләккә нәкъ менә яулык сайлаган. Берләшкән Дәүләтләр Берлеге Рәссамнар берлеге, Россия мөселман эшмәкәрләре һәм Россия мөселман дизайнерлар берләшмәсе әгъзасы, дизайнер, «Tatarscarf» брендына нигез салучы Елена ГАБДРАХМАНОВА белән татар бизәкле яулыклар турында сөйләшәбез.**

Фото: Анна Арахамия

**Елена Владимировна, үземне дә, укучыларны да иң нык кызыксындырган сораудан башлыйм әле. Татар яулыкларына мәхәббәт кайчан, ничек уянды сездә?**

– Тумышым белән Бөгелмә ягыннан мин. Әйе, бөтенләй башка мохиттә үстем, тәрбияләндем… Һөнәрем буенча – сынлы сәнгать укытучысы. 1985 елдан башлап төрле мәктәпләрдә белем бирдем. Ә бервакыт күңелгә нидер җитмәвен тоя башладым. Бөтен кешегә дә файдалы ниндидер матур эш эшлисе килә… 90 нчы еллар иде ул. Балаларын түләүле түгәрәкләргә йөртергә халыкның акчасы юк. Мин исә бер теләк белән янам: шәһәребезнең барлык балаларын бушка рәсем сәнгатенә өйрәтәсем килә. Моны бары тик телевидение аша тормышка ашырып булганны аңлап, өзми-куймый җирле телеканалның ишек төбен таптарга керештем. Һәм бер ай дигәндә рөхсәт алдым, спонсорлар да таптым! Әлеге тапшыруыбыз зур уңыш белән барды, рейтинглары бик югары иде. Тора-бара рәсми рәвештә мине телевидениегә эшкә алдылар, хәтта коммерция бүлеге җитәкчесенә кадәр күтәрелдем.

Аннан язмыш мине Казанга китерде. Башкалада да башта реклама юнәлешендә эшләдем. Акча җиткерә алмагач, берара подъезд да юдым… Ә 2009 елда Казан дәүләт университетына укытырга чакырдылар. Яулыкларга таба тәүге адымым менә шунда башланды дияргә була. Бүгенгедәй хәтерлим, 2016 ел иде ул. Студентлар белән бер лекциядә татар костюмы турында сөйләштек. «Татар хатын-кызы костюмын игътибар белән карагыз әле, – дим. – Монда нәрсәдер җитешми кебек». Студентлар аптыраšта. «Бар элементы үз урынында, бик матур», – диләр. Мин дә бирешмим: «Бу беренче карашка гына шулай. Калфак бар, камзул бар, читек бар, ә яулык кайда?»

Минем үзем өчен дә шаккатмалы иде бу ачыш. Татарлар декоратив гамәли сәнгать буенча алга киткән халык булган. Нинди югары дәрәҗәдә ювелир эшләнмәләр ясаганнар. Күннән аяк киемнәре тегү техникасын әйтмим дә – дөньяда бер! Ә яулык исә – юк! Дөрес, шәл бар. Тик ул яулык түгел. Сүз монда бизәкле яулыклар турында бара.

Сез миңа яулык бөркәнгән татар хатын-кызларының борынгы фотосурәтләрен күрсәтерсез. Тик алар ябынган ак җирлеккә эре чәчкәләр төшкән яулыклар – Павлов-Посад яулыклары. Халык телендә аларны «француз яулык» дип йөрткәннәр.

**Чынлап та, кызык: ни өчен татар халкы үз милли бизәкләре төшкән яулык булдырмаган? Сәбәбе нидә дип уйлыйсыз?**

– Бу хакта сәнгать белгечләре белән дә сөйләшкәнем булды. Уйлый торгач, татар халкы бизәкле яулык ясауны бик гади, артык элементар эш дип санаган, шуңа аның белән вакланып тормаган дигән нәтиҗәгә килдек. Башкалар эшләгәнне генә сатып алган ул.

Ә без студентларым белән шул бушлыкны тутырырга булдык. Юк икән, димәк, татар яулыгы тарихын менә бүгенге көннән – XXI гасырдан башлыйк, дидем. Алар бер-берсен уздырып, бу теманы өйрәнә башлады. Ниһаять, фәнни хезмәтебезне яклап чыктык: чын татар бизәкләре төшкән яулык моделен булдырдык. Проектны уңышлы якладык, сөендек. Һәм… бу эш берничә елга онытылды.

**Ә аңа яңадан тотынырга нәрсә этәргеч булды?**

– Грантлар язу буенча курсларым бар иде минем. Чыгыш ясаганда еш кына яулыклар проектын мисал итеп китерәм. Берсендә ерак районнан килгән география укытучысы мине «комфорт зонасы»ннан чыгарга мәҗбүр итте. «Елена Владимировна, барысы да шәп! Сатыгыз миңа биш яулык, укытучыларга Казаннан бүләк итеп алып кайтам», – диде. Югалып калдым. Әйе, проект бар, уңышлы да, ләкин аны гамәлгә ашырганым юк. Ә теге укытучы бик үҗәт булып чыкты – бүләк яулыкларны алып кайтып китте ул! Шулай итеп, вакыйгалар үзеннән-үзе мине бу юлга этәрде: 2019 елдан исә тулысы белән үземне шушы шөгыльгә – татар яулыкларына багышларга булдым.

**Халык арасында танылу исә берничек тә кинәт кенә була алмыйдыр…**

– Юк, әлбәттә. Беренче тапкыр халык алдына «Хәләл маркет» кысаларында чыктык. Бүгенгедәй исемдә, анда катнашу өчен ким дигәндә 40 яулык бастырырга кирәк иде. Минем өчен шундый зур сан иде бу ул чакта… Аннан инде безнең белән «Печән базары» кызыксына башлады. Башка күргәзмәләргә дә чакырдылар. Тора-бара, дүрт эшмәкәр берләшеп, Каюм Насыйри урамында сату мәйданын арендага алдык. Минем өчен шактый зур тәҗрибә булды ул чор. Клиентларыбыз артты, инде аерылып «башка» да чыктык. Тиздән икенче кибетебезне ачарга җыенабыз. Бер үк вакытта социаль челтәрләр, маркетплейсларда да эшебезне җәелдереп җибәрдек. Командамда инде 30 лап кеше эшли. Бүгенге көндә без сатып алучыга бизәкләре бер-берсен кабатламаган 200 дән артык төрле яулыклар тәкъдим итәбез.

**Хезмәткәрләрегезне ничек сайлыйсыз?**

– Аллаһ Тәгалә үзе аларны юлыма чыгара… Сатучыларны эшкә алганда иң беренче аларга нинди сорау бирәм дип уйлыйсыз менә?

**«Эш тәҗрибәгез бармы?» – дип сорыйсыздыр…**

– Мин алардан: «Татар халкының мәдәниятен яратасызмы?» – дип сорыйм. Минем өчен иң мөһиме шул. Ә калганына кеше өйрәнә – үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм.

Мондый эштә бар нәрсәне үзең генә тарту дөрес түгел – кешеләргә ышанырга өйрәнергә кирәк. Ләкин моның өчен үз эшеңнең һәр этабын энәсеннән-җебенә кадәр белергә тиешсең. Әйткәнемчә, командамдагы һәркем безнең идеягә мөкиббән. Әйтик, яулыкларга тартмалар ясаучы егет миңа үзе тәкъдим белән чыкты. «Яулыкларыгыз искиткеч, ләкин аларны салган тартманы сыйфатлырак итеп күрәсе килә, әйдәгез, үзем ясап карыйм», – диде. Безнең хәтта реклама видеолары ясар өчен махсус музыка язучыбыз да бар!

Максатыбыз – татар мәдәниятен популярлаштыру. Эшнең уңышлы баруы өчен, иң беренче чиратта, ниятең дөрес булу кирәк. Язылмаган шундый канун бар: әгәр эшләгән эшең җәмгыятькә файдалы икән, ул уңышлы булачак. Беренче чиратта акча эшләүне генә күздә тотасың икән – әллә ни ерак китә алмыйсың.

**Бизәкләр турында да сөйләшик әле. Белүемчә, борынгыларда һәр бизәкнең үз мәгънәсе булган. Һәр төс, һәр формага билгеле бер мәгълүмат салынган. Әйтик, түр кашагаларына чигелгән бизәкләргә карап тулы бер гаиләнең, хәтта нәселнең тарихын «укый» алганнар.**

– Милли орнамент – халыкның мәдәни коды булып тора. Ул инде генетикага салынган. Шундый мисал китерә алам. Беренче тапкыр зур күргәзмәдә катнашу өчен Мәскәүгә баруыбыз иде. Яулыкларны махсус бик югары элдем – ерактан күренеп торсын, дим. Безнең янәшәдә генә Павлов-Посад яулыкларын тезгәннәр. Халы-ы-ык... Карыйм: тирә-юньдәге берәүне дә күрмичә, халыкны ерып туп-туры безнең янга бер ханым килә. «Бу бит татар яулыклары! Мин бит үзем дә татар!» – ди. Менә монда инде маркетинг кагыйдәләре эшләүдән туктый – генетик код хәрәкәткә килә. Һәм мин моңа көннән-көн инана барам. Кеше туган телендә сөйләшмәсә дә, туган ягыннан читтә яшәсә дә, шул генетик код аны безгә тартып китерә... Ул күргәзмә безнең өчен дә бик уңышлы булган иде – халык янибыздан бер дә өзелмәде.

**Көндәшләргә ничек карыйсыз? Яулыкларыгызны «күчереп» алучылар белән ничек көрәшәсез?**

– Һәр яулык, һәр бизәк ул – безнең иҗат җимешебез. Аларны күчереп бастыру, плагиат белән шөгыльләнү – әхлак нормаларына сыя торган эш түгел. Тик дөнья бит бу – яулыкларыбызны күчереп эшләүчеләр дә очрый. Халык бу эшнең инде файда китерәчәген аңлады... Шуңа күрә һәр иҗат җимеше хокукый яктан якланган булырга тиеш. Бүгенге көндә бу мәсьәләне хәл иттек дип саныйм – яңа гына патент алдык. Безнең өчен зур һәм көтелгән яңалык! Ә конкурентларга килгәндә... Безнең максат татар яулыгын таныту бит. Ныклабрак уйлап карасаң, аларның барысы да  безнең шушы максатны тормышка ашыру өчен эшли булып чыга! Моңа хәзер тыныч карыйм. Һәр кешенең үз сатып алучысы. Бүгенге көндә исә рухи яктан тагын да югарырак баскычка мендек: конкурентларыбызга ул яулыкларны үзебезнең производствода ук бастырабы Ни өченме? Мин аларның сыйфатлы булуын телим. Яулыкларны туристлар бик күп ала. Әгәр алар алып киткән яулыклар начар сыйфатлы булып чыга икән, шәһәребез кунакларында Татарстан турында нинди фикер туачак? Павлов-Посад яулыкларын да бер фабрика гына чыгармый бит.

**Татар халкын, аның мәдәниятен танытуга, декоратив-гамәли сәнгатен үстерүгә шактый зур өлеш кертәсез. Эшегез, тырышлыгыгыз бәяләнәме?**

– Әйе дип саныйм. Мин Европа дизайнерлары союзы әгъзасы да булып торам. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы белән дә, Бөтендөнья татар конгрессы белән дә тыгыз элемтәдә эшлибез.

**Үз эшен башларга ниятләүчеләргә нинди киңәшләр бирер идегез, Елена Владимировна?**

– Әйткәнемчә, иң элек эшең башкаларга файдалы, кирәкле булырга тиеш. Уңышлы эш башлауның алгоритмы болайрак дияр идем: ният, социаль әһәмияте һәм ихтыяҗ булу, фәнни якын килү, ягъни бу эшне яхшылап өйрәнү. Мин үзем башта суга кердем, аннан соң гына йөзәргә өйрәндем *(көлә)*. Холкым шундый. Хәер, бу да начар алым түгел. Тик һәркемгә дә туры килмәскә мөмкин. Аннан, янәшәдәге кешеләрнең нинди булуы да мөһим. Безнең тормышка әйләнә-тирәдәгеләрнең йогынтысы бик зур. Сәләтле, ихлас, уңышка ирешкән кешеләргә карап үзебез дә үсәбез. Тагын менә нәрсәгә әзер булырга кирәк: уңыш та, уңышсызлык та синең тирә-юнеңне бик «чистарта». Көнләшүчеләр, сине үз файдасына кулланучылар үзеннән-үзе әкренләп коела. Бүген янәшәмдә – иң ышанычлылар, миңа үрнәк булырдайлар гына калды. Моның өчен Аллаһы Тәгаләгә чиксез шөкермен – ул кешеләрнең һәркайсы белән горурланам. Гомумән, юлымда очраган һәркемгә рәхмәтлемен: аларның барысы да безне нәрсәгәдер өйрәтә...

Ә иң мөһиме – хәләл кәсеп кагыйдәләренә таянып эшләү. Әйтик, товарның кимчелекләре булса, бу турыда сатып алучыга алдан ук әйтергә кирәк. Алдашмаска, үзеңә күбрәк кеше җәлеп итү максатыннан конкурентларның товарын хурламаска...

**Сезнең һәр сүзегездән ислам диненә ихтирам бөркелеп тора. Исламга килүегез ничек, нинди юллар аша булды?**

– Ислам динен 2009 елда кабул иттем. Бу юлга күндергәнче Аллаһы Тәгалә мине төрлечә сынады. Тик хәзер аңлыйм: ул мине шул рәвешле хак юлга өндәгән.

Ә намазга басарга бер укучым этәргеч булды. Университетта укыткан чагым. Барлык студентлар эшләрен яклап бетерде, бер кыз гына калды. Аны үземә чакырдым. Шунда ул очраклы рәвештә студентлар белән эшләгән яулык эскизларын күреп алды. Кызыксынуы шунда ук йөзенә чыкты... Сүзебез үзеннән-үзе яулыкларга күчте. Шунда ул аларга бизәкләр ясап карарга теләвен әйтте... Гүзәлия бүген күп яулыкларыбызның дизайнеры. Тик минем өчен ул дизайнер гына түгел, рухи юл күрсәтүчем дә. Аның аша Аллаһка тагын да якынайдым – намазга бастым. Бу юлда, гомумән, һәммә эшләремдә миңа ирем белән кайнанам да, әти-әниләрем дә бик зур таяныч.

Аллаһы Тәгаләгә таянырга, һәрчак Аңа тапшырырга өйрәнергә кирәк. Тәкъдир дигән әйбер бар, язмыш бар. Нинди генә талантлы, булдыклы булсак та – барысы да Аллаһы Тәгаләдән. Шуны аңламыйсың икән, ул сине тормышның төбенә төшереп тә куя ала. Яулыкларга тотынганчы кайда гына эшләмәдем. Гади хезмәткәрдән җитәкче дәрәҗәсенә дә күтәрелдем. Аннан, әйткәнемчә, подъезд да юдым, кайтып ятар урыным булмагач (әти-әнине борчыйсым килмәде), машинада да йокладым. Болар хакында сөйләргә оялмыйм. Шушы үткән юлым, алган тәҗрибәм мине бүгенге көнемә китерде.

Хәзерге вазгыять бүгенге көн белән яшәргә өнди. Әйе, дөнья безнең планнардан гына тормый, күрәсез... Бар да Аллаһ кулында – ул бар теләкләребезне дә ишетә, күрә. Минем бер дустым бар. Берара гел зарланды. «Арыдым, ял итәсем килә», – диде. Теш алдырырга барган җирдән аңа ялгыш инфекция эләгеп, шуннан соң ул бер-бер артлы өч операция кичерде, өч атнага якын хастаханәдә ятып чыкты. Менә шулай «ял итте»... Шуңа күрә Галәмгә һәркайсына «Амин» диярлек теләкләрне генә җиткерик.

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

# NIKAH DRESS STUDIO

НИКАХ ӨЧЕН ДИЗАЙНЕР КҮЛМӘКЛӘРЕ СТУДИЯСЕ

**Никах туен кабатланмас итеп үткәрүне профессионал дизайнерларга тапшырыгыз! Лилия ГАЙСИНА һәм аның командасы – үз эшенең осталары.**



**Уникаль һәм уңайлы, еллар буе татар кызларына махсус җайлаштырып ясалган өлгеләр буенча тегелгән киемнәр. Аларны өч ел дәвамында безнең кәләшләрнең буй-сын үзенчәлекләрен истә тотып ясадык.**

Кәләш өчен тулы образ тудыру мөмкинлеге. Кәләш өчен барлык әйберне бездән алсагыз, никах көнне киемнәрне әзерләп, үтүкләп куябыз, кәләшне киендерәбез. Яулык бәйләү – бүләккә!

**Кәләш башка милләттән булган очракта да ярдәмгә ашыгабыз. Барлык традицияләрне аңлатып, никахка тулысынча әзерлибез. Никах өчен бүләкләр дә бар бездә!**

Никахка кияү һәм кәләш ягы туганнарын бер стильдә киендерү мөмкинлеге бар. Җаныгыз теләгән түбәтәй, калфакны да бездә табарсыз!

**Шәхси заказлар буенча тегәбез. Сездән хыял – бездән әзер күлмәк!**

Сыйфатлы киемнәр – иң зур горурлыгыбыз. Шуңа күрә безгә яңадан әйләнеп кайталар. Безнең белән бер тапкыр эшләгән гаиләләр икенче балалары белән яңадан безгә килә.

**Размерлар төрлелеге. Башка җирдә булмаган размерны бездә табачаксыз! 36–70 нче размерлы киемнәр тегәбез.**

Милли традицияләргә туры китереп, төрле милләт костюмнары тегәбез. Озын җиңнәр, бай бизәкләр, кабатланмас модельләр – көндәлек эшебез.

**Клиентлар өчен кулай бәя булдыру – эшебезнең төп юнәлеше.**

Ирләр өчен мөселманча костюмнар – безнең производствоның тагын бер яңа юнәлеше. Заман белән бергә атлыйбыз!

**«НУРЛЫ»** мөселман галереясы
Казан, Париж Коммунасы ур.,
25/39 нчы йорт,
уңнан икенче павильон.
**8-999-169-74-20**
**8-927-413-15-03**

РЕКЛАМА







# НӘСЕЛЕБЕЗНЕҢ ЙӨЗЕК КАШЫ

**Шагыйрә, драматург, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Гөлшат ЗӘЙНАШЕВАның тууына быел 95 ел. Бу язмамда мин, күренекле шагыйрәнең туганы буларак, кайбер хатирәләрем белән уртаклашырга телим. Гөлшат апа белән безнең туганлык болай. Аның әтисе Хисам абый белән әнием Мәһруйның әнисе бертуганнар. Кемдер өчен ерак кардәшләр кебек күренсәк тә, чынбарлыкта без бик якын туганнар булып, гомер буе аралашып яшәдек. Гөлшат апабыз бик туган җанлы, киң күңелле, мәрхәмәтле зат иде. Шәхсән үзем татар әдәбиятын, сәнгатен, җырларын ихлас яраттым, хатыным Венера да шундый калыптан. Бу уртаклык нәселебезнең «йөзек кашы» булган Гөлшат апабыз белән безне тагын да якынайтты.**





Марс
ГАИТОВ

Нәшриятта басылып чыккан һәр китабын – ә алар егерме өчәү – Гөлшат апа җылы автограф язып һәрвакыт безгә бүләк итте. Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган «Илле җыр» китабында ул болай дип язган: «Кадерле туганнар, Марс, Венера, Алсу! Җыр яратасыз, парлап җырлап та утырасыз. Шулай җырлый-җырлый сау-

сәламәт булып озак яшәгез, бәхетле яшәгез! Иң изге теләкләр теләп – Гөлшат апагыз Зәйнашева. 24.09.1988 ел».

Кызыбыз 1963 елда, без әле Минзәлә районында яшәгәндә туды. Гөлшат апа тәкъдиме белән аңа Алсу исеме куйдык. Шул чакта Гөлшат апа бер генә кичкә безгә килде. Минзәлә драма театрына чираттагы яңа пьесасын да алып килгән. Дүрт чакрым араны ул кичен, кояш баеганда, юлы-ние белән яңа гына сөрелгән басу аша җәяү үткән. Соңыннан сөйләде: «Буразналар» җырының сүзләре күңелендә шул чакта, басуда туган икән. Күренекле композитор Җәүдәт Фәйзи аңа дәртле, моңлы көй язды – ул җыр популяр булып китте.

Гөлшат Хисам кызы Зәйнашева 1928 елның 13 гыйнварында Чаллы кантоны (хәзер Тукай районы) Иске Теләнче авылында Әнвәр һәм Хисам Зәйнашевлар гаиләсендә өченче бала булып дөньяга килә. Хисамның әтисе Хөснетдин Рәсәй армиясендә озак еллар солдат хезмәтендә була, 29 яшендә рус-төрек сугышында катнаша, батырлыгы өчен алтын медаль белән бүләкләнә һәм авылына кайта. Йосыф Хәлфин дигән байның кызы Хәлимәгә өйләнә, кәләш аңа мул бирнә белән килә. Хөснетдин үзе дә булдыклы кеше була: тиз арада бирнә акчасына ике катлы мәһабәт йорт җиткерә. Беренче катын кызыл кирпечтән сала: анда кибет урнаша. Йортның икенче катын нарат бүрәнәдән күтәрә: киң, күп тәрәзәле, якты итеп... Булачак шагыйрә Гөлшат шушы кояшлы өйдә туа. 1940 елларда ул йортта мин дә берничә мәртәбә кунак булдым. Узган елның сентябрендә кызым Алсу белән Гөлшат апа туган авылга кабат бардык, йорт нигезен фотога төшердек. Беренче каттагы кирпеч кибет һәм корылма әле исән, ә икенче каты инде сүтелгән.

Хөснетдин хаҗи гаиләсендә җиде кыз, ике малай туа. Чибәр кызлары тирә-күрше авыл егетләренә кияүгә чыгып таралыша, төп йортта төпчек улы Хисам кала. Ул Зәй районы Биш Субаш авылы кызы Әнвәргә өйләнә,

## Гөлшат апа соңрак ачынып: «Менәргә иде Урал тауларына» җырым өчен, йә Хода, күпме эләкте миңа?!» – дип язды...

гаиләдә дүрт кыз (өченчесе Гөлшат), бер малай дөньяга килә. Хисам абый оста гармунчы, шигырь ярата, әңгәмәдәше белән сөйләшкәндә дә шигъри җөмләләр куша. Әнвәр апа һәрчак моңланып, җырлап эшләргә ярата. Әти-әнисенең шундый күркәм гадәтләре, нәсел геннары кечкенә Гөлшатка да күчкән, күрәмсең.

Әтиле-уллы Зәйнашевлар 1917 ел инкыйлабына кадәр авылда бердәнбер кибет тоталар. Хөснетдин ага өч тапкыр хаҗга бара. 1917 елгы Октябрь түнтәрелешеннән соң совет хөкүмәте хосусый сәүдәне катгый тыя: Зәйнашевларларның да кибетләрен тартып алып, сельпо дигән оешмага тапшыралар. Барлык кирәк-яракны Хөснетдиннең универсаль, бай кибетеннән сатып алып көн күргән авыл халкы кыен хәлдә кала, чөнки күп тауарлар дефицитка әйләнә. Зәйнашевлар совет хакимиятенә каршы булмый. 1929 елда авыл халкын көчләп, колхоз оештыралар, гаилә аңа кушыла: атын, мал-туарын, авыл хуҗалыгына кирәкле инвентарен колхозга тапшыра. Ә 1930 елда хәлле крестьяннарны «кулак» дип репрессияләү чаралары киң колач җәя. Бу кара исемлеккә 82 яшьлек Хөснетдин хаҗи да эләгә... Юлда ук үләчәк, дип, Хисам абый әтисен өендә калдыруларын сорый, аның урынына үзем китәм, ди. Аны биш елга хөкем итеп, Соловкига озаталар... Күп җәфалар чигеп, хөкем срогын тутырып, капчыгына Сталин рәсемле Мактау кәгазьләре салып, 1935 елда авылына кайта ул. Кайтса, әтисен, дүрт баласын, хатыны Әнвәрне өйдән куып чыгарганнар... Хәл җыярга да өлгерми кала: Хисам абыйны тагын кулга алып, икенче мәртәбә шул ук сөргенгә озаталар. Ул инде кире әйләнеп кайтмый... Әтиләре киткәч, 1935 елда бишенче бала – Фатыйма туа... 1989 елда Гөлшат апа әтисенеңаклануы, реабилитацияләнүе турында Татарстан прокуроры Кафил Әмиров имзасы белән белешмә алды. Биш бала атасын юк иткән өчен дәүләт аларга 8 мең сум (!) акча түләде: Гөлшат апа аны туганнарына өләште, үзенә бер тиенен дә калдырмады.

Берсеннән-берсе кечкенә дүрт бала белән йорт-җирсез, ач-ялангач калган әнисе 2 яшьлек Гөлшатны иренең бертуганына – Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында яшәүче Маһнуй апага асрамага бирергә мәҗбүр була. Гөлшат бу гаиләдә ачлы-туклы үсә, апасының ире Хөрмәкәй эчүгә сабыша, еш кына тавыш чыгара, дәрес әзерләргә комачаулый.

Башлангыч мәктәптән соң биш чакрым җәяү йөреп, Гөлшат күрше Хуҗәмәт авылында укый. 1942–1945 елларда Минзәлә педагогика училищесында белем ала: 14 яшеннән үз көнен үзе күрә. Кешеләргә идән юа, бәрәңге бакчаларын казый... Алар, берничә кыз, янгын сүндерүчеләр каланчасы астындагы җылытылмый торган бүлмәдә яшиләр. Кышкы салкыннарга түзәр чама калмагач, кирпеч ватыклары җыеп, Гөлшат кечкенә генә «голландка» миче чыгарып куя. Ул гел «биш»легә укый, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, сәхнәдә җырлый, шигырьләр сөйли; үзе дә шигырьләр яза башлый, алар стена газетасында урын ала һәм район матбугатында басылып чыга...

1945 елда Гөлшат, кабул итү имтиханнарын уңышлы тапшырып, Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Тырышлыгы белән аерылып тора: «бик яхшы» билгеләренә генә укый, үзешчән сәнгатьтә актив катнаша, сәхнәдә моңлы итеп җырлый, шигырьләр сөйли. Аны «шагыйрә», «җырчы» дип йөртәләр.

# Шагыйрәнең кабер ташына аның васыяте уелган: «Кешеләр, яратыгыз бер-берегезне, ярату озайтыр гомерегезне!»

Әмма ул «халык дошманы» кызы... Беркөнне аны институт директоры Йосыф Туишев кабинетына чакыртып, тетрәндергеч хәбәр әйтә: «Гөлшат, мин сезне институттан чыгарырга мәҗбүр, НКВД таләп итә». Аны «халык дошманы» кызы булуда һәм институтка кергәндә әлеге фактны яшерүдә гаеплиләр. 2 яшьтә әти-әнисеннән аерылуга дучар ителгән ятим бала исә әтисен бөтенләй хәтерләми дә...

Бу җан әрнеткеч вакыйганы яшь кыз бик авыр кичерә, әмма югалып калмый. Шунда ук Казан театр училищесына укырга керә. Берничә айдан соң институт директоры Гөлшатны эзләтеп таба һәм яңадан укуын дәвам итәргә мөмкинлек бирә. (Бик миһербанлы кеше булган Йосыф ага.) 1949 елда институтны тәмамлагач, бик җаваплы эшләрдә хезмәт итә Гөлшат апа. Татарстан радиосында 16 ел дәвамында башта әдәби-драматик, соңрак музыкаль тапшырулар мөхәррире була. Биредә ул язучылар, композиторлар, күренекле сәнгать эшлеклеләре белән аралаша, үзе дә иҗатка кереп китә, җыр текстлары, шигырьләр яза. Аннан соң Татарстан китап нәшриятында мөхәррир, кадрлар бүлеге башлыгы, язучыларның Тукай клубы директоры булып эшли, иҗатта да үрләр яулый.

1953 елда Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга кергәч, Гөлшат апа белән мин якыннанрак таныштым. Ул чакта алар кызы Асия, ире Мөхәммәт белән Некрасов урамында ярымподвалдагы бик кечкенә бүлмәдә яшиләр иде. Ә мин аларга якын гына Маяковский урамында – якташым Лотфикамал апаларда көн күрәм. Гөлшат апаларга баргалый башладым. Бүлмә кысан булса да, киң күңелле апам мине якты чырай, тәмле чәй белән каршы ала, тормышым, укуым белән кызыксына. Кайчак ул җыелышка китә дә, мин Асияне карыйм, дәрескә әзерләнәм. Кулымда химия китабын күреп, берсендә 3 яшьлек Асия: «Бу нинди китап?» – дип сорады. «Химия», – дим. Шуннан соң ул мине «Химия абый» дип атады, килгәнне тәрәзәдән күрсә: «Химия абый килә!» – ди икән. Гөлшат апаларга сабакташым, дустым, музыка училищесы студенты Илһам Шакиров белән дә баргаладык, шул танышу алга таба аларның иҗади дуслыгына китерде.

Студент вакытта Матбугат йортына – Тукай исемендәге язучылар клубында узган җомга кичәләренә бик теләп йөрдем. Гөлшат апа – аның директоры, кичәләргә гел чакыра иде мине. Бервакыт ул иҗат иткән «Рамай» пьесасын язучылар берлегенең драматургия секциясендә тикшереп фикер алыштылар. Гөлшат апа җыелышка мине дә дәште. Кызыксынып тыңлап утырдым. Утырышны күренекле драматург Таҗи Гыйззәт алып барды. Язучылар Мирсәй Әмир, Әнәс Камал чыгыш ясап, әсәрне хупладылар. Башкалар, җитешсезлекләрен күрсәтеп, тагын да камилләштерү юлларын атадылар. Гөлшат апа ул әсәрне яңабаштан язып, театр сәхнәсенә менгерде.

1958 елда институтны уңышлы тәмамлап, Яңа Юл районы дәүләт сортлар сынау участогында мөдир булып эшли башладым. Бәхетемә, ул бездә – хәзерге Тукай районы Иске Дөреш авылында урнашкан иде. Гөлшат апа белән элемтәбез исә өзелмәде. 1959 елда ул безгә кунакка кайтты. Хәл-әхвәл белешкәч, чәйләр эчкәч, әйтеп куйды: «Марс энекәш, басуларыңны күрсәт әле миңа». Без аның белән тарантаска утырып басу-кырларга юнәлдек. Август аеның кояшлы, матур көне, игеннәрне урып-җыю бара. Гөлшат апаны бөтен нәрсә кызыксындыра. Басуларда күкрәп үскән бодайларга соклана, игенчеләрне мактый. Мин әбәткә туктаган комбайнчыларга, шаяртып: «Менә, егетләр, сезнең хакта җыр язарга Казаннан шагыйрә Гөлшат Зәйнашева килде, сынатмагыз!» – дим.

1960 нчы еллар башында Гөлшат апа сүзләренә композитор Мансур Мозаффаров көй язган «Менәргә иде Урал тауларына» җырының (аны консерватория студенты Илһам Шакиров башкарды) текстын өлкән язучылар А. Шамов, Г. Әпсәләмов, Ф. Хөсни, Н. Дәүли, З. Мансур пессимизмда гаепләделәр. Имеш, «Урал таулары биек түгел бит ул, коммунизм төзегән чорда шунда менәргә хыяллана икән Гөлшат Зәйнашева, менсен!» Бу – шигырьне бары тик сәяси караштан гына бәяләү иде... Яшь хатын-кыз шагыйрәгә ярдәм итәсе урынга, өлкән язучылар аны һәр җыелышта шул бер шигыре мисалында урынсыз тәнкыйтьлиләр, матбугатта да усал-усал фикерләр әйтәләр. Язучы Нәби Дәүли шушы популяр җыр сүзләренә, аның авторына каршы көрәшә башта. Әмма Гөлшат Зәйнашеваны СССР Язучылар берлегенә әгъза итеп алу тәкъдимен караган җыелышта чыгыш ясап, фикере үзгәрүе, ялгышын тануы турында әйтә, шагыйрәне Язучылар берлегенә тәкъдим итүне хуплый. Халык исә җырны яратып, җылы кабул итте, шигырь авторын яклаучылар, бу турыда мәкаләләр язучылар да аз булмады. Әлеге моңлы җыр әле дә яңгырый. Горур яңгырый!

Гөлшат апаның минем дустым, консерватория студенты Илһам Шакировка, башка яшь җырчыларга, сәнгатькәрләргә ярдәме күп тиде. Матбугатта сәләтле җырчылар турында күләмле язмалары, очерклары чыкты – аларга үсү, популярлашу өчен киң юл ачылды. Бик күп хезмәт куеп, мәшһүр композиторыбыз Сара Садыйкова турында өч китап бастырып чыгарды ул: «Сара Садыйкова» (1987), «Сагыналар сине чын дуслар» (1991), «Калфаклы

сандугач» (2002). «Үзем турында» дигән китапның авторы дип күренекле җырчы Әлфия Авзалова күрсәтелсә дә, чынлыкта ул китапны да Гөлшат апа язды. Ә менә үзе турында китап язарга уңайсызланды, тыйнаксызлык була, диде. Бик тыйнак, хәтта артык тыйнак иде шул ул...

Кинорежиссер Идмас Үтәгәнов белән алар «Салих Сәйдәшев» документаль фильмын иҗат иттеләр. Телевидение аны композиторның юбилей көннәрендә тамашачыга күрсәтте. Композитор Сара Садыйкова турындагы «Моңсара» (1996), «Моңнар дөньясына сәяхәт» (2006) документаль фильмнарына сценарийларны да Гөлшат апа язды. «Тузган тузгактан күчкәндә» күпсерияле телевизион фильмы да – аның иҗат җимеше. Тамашачылар яратты аны! Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев исеменнән сценарий авторы Гөлшат Зәйнашевага 50 мең сум бүләк тапшырылды ул чакта.

Гөлшат апа үзенең фамилиясе нишләп Зәйнашева икән, дип гаҗәпләнә иде. Әтисе – Хисам, бабасы Хөснетдин ләбаса! Маһнуй апа аңа: «Зәйнашева фамилиясе бик абруйлы, башкага алыштырма!» – дигән булган. Татарстан язучыларының бер җыелышында Гөлшат апа Сарман егете, шәҗәрәләр төзүче шагыйрь Дамир Гарифуллинга үзенең гозерен җиткерә: «Шәҗәрәмне тикшерә алмассыңмы? Нишләп фамилиям Зәйнашева икән?» Дамир, архивларда казынып, шагыйрәнең җиде буын шәҗәрәсен төзи һәм шуны ачыклый: алар нәселендә, чыннан да, 1769 елда туган Зәйнагетдин исемле бик булдыклы, абруйлы зат булган. Авылдашлары аның исемен кыскартып, «Зәйнаш» дип йөрткән. Шуннан башланган Зәйнашевлар фамилиясе. Кызганыч, бу турыда Гөлшат апа үзе ишетергә өлгермәде.

Гөлшат апа шәфкатьле, мәрхәмәтле, ярдәмчел кеше иде. Мәсәлән, Әлфия Авзалованың яшь бала белән салкын, юеш фатирда яшәвен филармония җитәкчеләренә ул әйтә – җырчыга яңа торак бирәләр. Гаиләләре ишәйгәч, өч бүлмәле фатир алырга да ярдәм итә ул аларга. Шагыйрь булырга хыялланган Фәнис Яруллинга ярдәме дә – үзе бер кыйсса. Җылы хатлар яза ул аңа, язучы булу өчен нинди әсәрләр укырга, кемнән үрнәк алырга дигән файдалы киңәшләрен бирә. Күренекле язучыларның китапларын сатып алып, почта аша җибәрә... Соңрак аның һәр язганын игътибар белән укып бара. Фәнис Ярулин аннан җыр язу серләрен ачуын сорый. Гөлшат апаның җавабы: «Җырның меңләгән серләреннән берсе – чын күңелдән, чын йөрәктән язу... Җырда тирән фикер гади генә, табигый генә әйтелергә тиеш. Җыр ул – поэзиянең иң авыр, иң нечкә бер тармагы».

Ни гаҗәп, Гөлшат апа үзе гомеренең күп өлешен кысан, тузган торакларда үткәрде. Ниһаять, 1990 нчы еллар башында аңа Мусин урамында ике бүлмәле «хрущевка» бирделәр. Күчәргә җыенып йөргәндә, таныш түгел бер ир кеше килеп, бушаячак бүлмәне күрсәтүләрен сорый. Күптән түгел төрмәдән чыккан бу кешене район башкарма комитетыннан җибәргәннәр икән. Фатирны карагач, ул: «Юк, мин мондый торакка риза түгел», – дип чыгып китә...

Гөлшат апабыз безнең гаиләне якын итә иде. «Марс энекәш, син миңа тормышта – бер терәк», – дигән иде бервакыт. Аңа зур терәк булдым дип мактана алмыйм, шулай да кайбер ярдәмем тиде. Элек күп нәрсә дефицит, акчаң булса да сатып алып булмый иде бит. «Татмелиоводстрой» трестында бүлек җитәкчесе булып эшләгән чак, танышларым аша Гөлшат апага чиратсыз гына суыткыч юнәттем берсендә. Бик куанган иде.

Г. Тукай исемендәге премиягә күптән лаек иде инде ул. Әмма Язучылар берлеге дә, башка оешмалар да ләм-мим – тәкъдим итүче юк. Бу эшкә мин алындым. Үзем инде 17 ел укытучы, доцент булып эшләгән Казан авыл хуҗалыгы институты коллективы исеменнән шул мәртәбәле премияне бирү комитеты рәисе Мансур Хәсәновка хат яздык, аны институт җитәкчеләре, укытучылар, студентлар имзалады. Мөрәҗәгатебезгә нигез бар: үзенең иҗаты белән Гөлшат апа безнең студентларга, укытучыларга бик таныш һәм якын. Ул елларда студентлар белән очрашуларга, әдәби-музыкаль кичәләргә язучыларны, артистларны чакыра идек. Гөлшат апа аларга бик теләп килә, кичәне оста итеп, юмор белән үзе алып бара: көлдерә дә, уйландыра да. Студентларыбызның күпчелеге – авылдан, Гөлшат Зәйнашева җырларын тыңлап, җырлап үскән балалар... 1991 елда Гөлшат апа ул мәртәбәле премиянең лаеклы лауреаты булды.

Бик бала җанлы иде ул, кызы Асиягә югары белемле музыкант булырга ярдәм итте. Гомумән, балаларны ихлас яратты. 1994–2004 елларда композитор Гөлнара Беляева белән балалар өчен иллед ән артык җыр иҗат иттеләр. Ул җырларны шагыйрәнең кызы, музыка укытучысы, хор дирижеры Асия Зәйнашева үзе оештырган «Айсылу» балалар вокаль ансамбле репертуарына кертте.

75 яше тулгач, Гөлшат апаны көчле инсульт аяктан екты, ул ике елдан артык каты авырды. Әмма гомеренең соңгы көннәренә кадәр камил акылында булды, кыенлык белән булса да сөйләшеп ятты. Яныннан кеше өзелмәде... 2005 елның 1 апрелендә арабыздан китеп барды ул. Ул көнне Татарстан радиосы иртәнге тапшыруларын шагыйрәнең «Китмә, сандугач» җыры (Рөстәм Яхин музыкасы) белән башлап җибәрде һәм кайгылы хәбәрне халыкка җиткерде... Г. Камал театры Гөлшат Зәйнашеваны соңгы юлга озатырга килгән халык белән шыгрым тулы иде.

Язмышы яралы булса да, Гөлшат апа дөнья ямен, яшәү кадерен белеп, тормышка гашыйк булып гомер итте. Малга, байлыкка кызыкмады. Аның байлыгы – табигать биргән мул таланты, гаиләсе, дуслары, халык мәхәббәте булды. Ул бәхетле иде!

Фото: гаилә архивыннан


Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА

Шагыйрә Рәсимә Гарифуллина – бик күп талантлар биргән Балык Бистәсе якларыннан. Балтач (Юлсубино) авылында туган, Югары Тегермәнлек мәктәбендә урта белем алган. Пермь өлкәсендә хәрби заводта эшләп, зур чынығу мәктәбе үткән. Университетның журналистика факультеты, Саратов Идел буе иҗтимагый-сәяси институты исә кыю журналист, зирәк җитәкче итеп әзерләгән. «Авыл офыклары» газетасында – журналист, районның халыкны эш белән тәэмин итү үзәгендә – директор, район хатын-кызлары берләшмәсендә – алыштыргысыз җитәкче... Аның эшчәнлеген әнә шулай бәяләп буладыр. Күпләр өчен ул – лирик һәм фәлсәфи шигырьләр, тарихи поэмалар иҗат итүче, эзотерика темасына язучы шагыйрә, «Бүген Ярат!», «Яшәү мәңгелек», «Минем куллар – синең кулда», «Йолдызлар юл күрсәтер», «Дөнья йөге», «Зәңгәр дуга», «Адашкан» исемле китаплары авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, «Бәллүр каләм», «Болгар радиосы», «Яңа татар җыры» премияләре иясе.

# САНДУГАЧТАН МОҢ АЛЫП...

### *Бүләк сандык*

Бүләк итеп бирәм сиңа
Серле сандык, кабул ит!
Сиңа тугры хезмәт итәр,
Кадерлә син, саклап тот!

Гади тартма гына түгел,
Могҗизалар тулы ул.
Бизәкләре сырлы-сырлы –
Чын осталар кулы ул.

Кәләш булыр җитү кызга
Сандык сатып алалар.
Бүләк бирнә әзерләгәч,
Шул сандыкка салалар.

Бирнәле сандык киленнең
Туйда иң зур бүләге.
Тулы сандык – тулы бәхет,
Әниләрнең теләге.

Тулы сандык кыз баланың
Дәрәҗәсен арттыра.
Сандык малы белән килсәң,
Өең елмаеп тора.

Мендәр, юрган, чиккән сөлге –
Бар да сандыкка сыя.
Кызы сандык тутырганда
Ана моңаеп куя.

Бүләк сандык булыр кызның
Туй мәһәрен саклаучы.
Сандык – яшьлек хатирәсе,
Килен хакын хаклаучы.

Алтын алка, энҗе мәрҗән
Урын алсыннар анда.
Туй балдагыңны салырсың
Бала юындырганда.

Бизәкле бирнә сандыгы,
Түгел ул гади тартма.
Кызыңа ал яңа сандык,
Кияүгә чыккан чакта.

Туй күлмәген салып саклар,
Әни бүләк итте, дип.
Үз сандыгыңны ачарсың:
Яшь гомерләр үтте, дип.

### *Чулман белән сөйләшү*

Чыктым да мин Чулман ярына
Җилләргә чәчләрем тараттым.
Серемне чиштем мин җилләргә:
Яраттым, яраттым, яраттым...

Мин торам биек яр читендә,
Йөрәгем ярсуын чак басып.
Чулман да минем күк ярсулы,
Айкала дулкыннар таратып.

Бастым да мин Чулман ярына,
Җилләрдә чәчләрем киптердем.
Дулкыннар син киткән яклардан
Ул кайтыр дип хәбәр китерде.

Дулкыннар иркендә акчарлак,
Чакыра юксынып, җан атып.
Җил белән сәламнәр җибәрәм
Мин сиңа сагынып, яратып.

### *Җавап көтәм*

Сандугачтан моңнар алам,
Җырыма көен салам.
Язмыш бүләк иткән юлдан
Яныңа үзем барам.

Аккошлардан – каурый алам,
Каурыен каләм итәм.
Каурый каләм белән язган
Сәламнәргә ни җитә?

Яман күздән пәрдә итәм
Ак болыт өрфиясен.
Каурый каләм белән язсам,
Беләм җавап киләсен.

### *Гомер буе яраттым*

– Кайтма, – димен, – кирәк түгел,
Мин көтмим сине бүтән.
Җаным сагышлардан тулып
Көткән көннәрем үткән.

Сулкылдап, әрнеп тора, бел,
Йөрәгем бәргәләнә.
Үзе сине кире кага,
Үзе гел өзгәләнә.

Кайтмасын ла, кире как син! –
Горурлык акыл сата.
Безнең болай аерылулар
Язмышта булган хата.

Юк, кайтмассың инде, көтмим,
Үзем синнән баш тарттым.
Кайтма, диеп куа-куа,
Гомер буе яраттым.


Илмира ГЫЙМАЕВА

Илмира Гыймаева – Байлар Сабасында яшәп иҗат итүче шагыйрәбез ул. Кай арада Язучылар берлеге әгъзасы булды да, кай арада китаплар чыгарып өлгерде! Шигырьләре, җырлары күпме! «Яңа татар җыры» бәйгесендә дә лауреат, «Татар радиосы» милли премиясе лауреаты да үзе. Узган ел «Ел хатын-кызы» бәйгесенең «Мәдәният һәм рухият» номинациясендә республика күләмендә җиңүче булып та сокландырды Илмира. Ә бүген сезгә бер шәлкем язгы шигырьләрен юллый. Күтәренке кәеф, елмаюлар, кызлар җыры, лалә чәчәкләре... Алар, бәйрәм бизәге булып, җаннарны иркәли.

# БЕЗ БҮГЕН – ЯКТЫ ЯЗ!

## *Март бураны безгә охшаган*

Март бураны башка, үзгә инде,
Безнең зат бит! Безгә охшаган!
Әле ярсый, әле елап ала,
Ул да бәгырь-назга сусаган.

Көйсезләнеп үзен күрсәтмәкче,
Тойсыннар, ди, аның хисләрен.
Очып-очып бөтерелә күктә,
Ватмак булып күңел бикләрен.

Март бураны март бураны инде,
Кошлар авазына бизәлгән.
Колакларга бөре көен көйли –
Җиленең дә җыры үзгәргән...

Он иләге аша үткәнмени –
Карлары да өрсәң очарлык.
Март бураны безгә охшаган шул,
Күңелендә һич юк усаллык.

Ничә көннәр инде март бураны
Дулый иртән, дулый кичләрдә.
Март бураны якты! Адаштырмый!
Бары саташтыра хисләрдә...

## *Бәйрәм киче һәм без*

Урамда – яз исе! Сиздегезме, кызлар!
Төнге күкне бизи кыланчык
йолдызлар.
Безнең күңелгә дә иләслек өсти яз,
Без йолдыздан кимме?!
Безгә дә кирәк наз!
Әйдәгез, онытыйк мәшәкать,
эшләрне!
Чын бәйрәм итик без бүгенге
кичләрне!
Сөйләшик, гөрләшик –
утырмыйк моңаеп!
Язмышның күзенә карыйк
без елмаеп!

Онытыйк өшеткеч салкын
күз карашын,
Кузгатмыйк йөрәкнең
әрнегән ярасын!
Онытыйк чирләрне,
яшьләтмик күзләрне!
Таратыйк биттәге ел салган эзләрне!

Онытыйк кайгыны,
хәсрәтне, ялгышны!
Онытыйк балалар өстәгән сагышны!
Рәнҗемик беркемгә!
Телик тик яхшылык!
Без чибәр! Без матур!
Чүп безгә каршылык!

Без гүзәл! Без сабыр! Без уңган!
Без булган!
Йөрәкләр, җаныбыз наз-сөюгә тулган!
Без – кызлар! Без – хатын!
Без – ана! Без – бала!
Кирәксә, без – урман! Күк!
Диңгез! Чүл! Дала!

Мәңге яшь күңелләр! Без – чәчәк!
Без – гөлләр!
Егылмыйк, дусларым,
йолкыса да җилләр!
Сиздермик ярсуны! Яшерик ачуны!
Тоймасын беркем дә
җандагы ташуны!

Урамда – яз исе! Сиздегезме, кызлар!
Гомерләр үтә дип үчекли йолдызлар!
Күтәрик башларны!
Сикертик кашларны!
Үч итеп елларга кочаклыйк язларны!

## *Лалә чәчәкләре*

Лалә чәчәкләре – бәйрәм бизәкләре,
Таҗларында сөю күзләре.
Елмая күңелләр, пышылдый иреннәр
Күптән көткән назлы сүзләрне.

Лалә чәчәкләре – мартның гүзәл яме,
Мәхәббәттән бии тамчылар.
Җанны кояш кочкан,
хыял күккә очкан,
Бәйрәм җырын көйли кар-сулар.

Лалә чәчәкләре – гүя яз җиләге,
Татлы хисләр тәме йөрәктә.
Без бүген – якты яз,
без бүген – серле наз,
Чәчәк тә без бүген, җиләк тә...





Гүзәл Әдһәм хикәяләрендә хатын-кыз бөтен җаны, матурлыгы, җылылыгы белән ачыла. Гади, шаян, бераз хыялый да геройларын укучылар яратып кабул итә. Педучилище, университет тәмамлаган, авыл мәктәпләрендә укыткан, фән кандидаты югарылыгына күтәрелгән, вуз укытучысы булып эшләгән язучының тормыш тәҗрибәсе бай. Мәктәп, укытучылар дөньясын аеруча үз итә, балалар өчен язылган хикәяләре ихласлыгы, җиңелчә юморы белән үзенә тарта. Тормышны, кешеләрнең психологиясен яхшы белүе сизелеп тора: Гүзәл Әдһәм хикәяләрен онытылып укыйсың.



Гүзәл ӘДҺӘМ

# ӨЧ МОНОЛОГ

(Хикәя)

Нурания иренең һәр иртәдә шалтыратуына күнегеп беткән иде. Шулай да ул телефон шалтыравыннан дертләп куйды, әмма Илдарның тавышын ишетү белән, әллә нигә күңеле йомшап, еламсыраган иркә тавыш белән аңа дәште:

– Әйе, әйе, тыңлыйм үзеңне... Ничек соң анда?

– Әйбә-ә-әт... Уяттым, ахры, сине.

– Китче, нинди йокы ди! Әллә кайчан торып, сыерны савып кердем инде.

– Хәлләрең ничек?

– Аллага шөкер, бар да яхшы...

Нурания, тәрәз яңагына сөялгән килеш, ишегалдында җим чүпләп йөргән тавыкларын күзли-күзли сөйли бирде, сүзләре, күңелендәге сагышлы назга уралып, моңсу гына талгын бер көйдәй агылды да агылды...

– Кыскартырга уйламыйлармы соң укуларыгызны?

– Уйлыйлар, уйламый ни... Барыбыз да авылныкы бит. Анда эш көтә...

– Эш дип инде... Гел Казанга барып булмый, әзрәк файдаланып кал... Театр-концертына йөр дигәндәй...

– Бардым, бардым, Камал театрында ике спектакль карадым инде. Мәктәп ничек анда? Бакчаларны чүп басмадымы?

Нурания көлеп куйды:

– И-и-и, тилекәем, үз бакчаңны сорар идең. Бер тамчы яңгыр төшкәне юк. Бәрәңгенең төбенә өяр чак җитеп килә.

– Анысына үзем дә кайтып өлгерермен. Кагылмый тор. Әлфия дә, бер генә экзаменым калды, дигән иде, ул да булышыр...

– Әлфия ничек соң?

Казандагы студент кызы исенә төшеп, күкрәк тирәсендә нәрсәдер келтерәп куйды.

– Ничек булсын – яшьләрчә! Нәкъ синең кебек – чибәр, җитез!

Хатынга бик рәхәт булып китте. Көтмәгәндә күңеле күтәрелеп, җанына дәрман өргән Илдарына да бер-ике назлы сүз юлларга торганда, исенә төшеп, әйтеп калырга ашыкты:

– И-и-и, онытып торуымны күр инде: сиңа хат бар...

– Нинди хат?

– Кем белгән инде аны. Мәктәп директорына диелгән.

– Министрлыктан-мазармы?

– Юк бугай... Охшамаган...

– Тагын берәр кагәзь-мазар сорауларыдыр. Ач, әйдә, укы... Булырлык булса, җавабын үзең генә әтмәлләп җибәрерсең...

Нурания конвертны ачты, Илдарына хатны тиз генә укып бирергә иде исәбе, тик әллә кайдан ниндидер кайнар агым, кинәт тынын буып, бөтен күкрәген умырып тотты.

Илдар аның саен ашыктырды:

– Йә инде, укы! Нинди хат ул?

Нурания җавап бирмәкче булып авызын да ачкан иде, тик теге кайнар дулкын әллә тавышын да көйдереп өлгергән инде, кисәк кенә кибеп киткән иреннәре үзен тыңламый дерелдәде.

– Нурания! Нурания, дим! Ник дәшмисең?

Нураниянең исә сүз әйтерлек тә егәре калмаган иде...

...Бераздан ул айнып киткәндәй булды. Аяклары хәлсезләнеп, бөтенләй идәнгә үк чүккән икән бит! Бер кулына телефонын кысып, икенче учына хатны йомарлаган килеш, хатын диванга барып чүмәште.

Телефон өзлексез шалтырады да шалтырады. Экрандагы «Илдар» сүзе дә бер кабынды, бер сүнде. Нурания кымшанмады да. Ул кымшана алмады. Хаттагы сүзләр, барлык егәрен умырып алып, аның бөтен тәненә хуҗа булып өлгергән, аяк-кулын да берни тоймас итеп таратып ташлаган иде.

«Исәнме, әтием! Бу хатны алгач, аптырап китәрсең инде син. Бу мин – синең кызың Илдария! Син исән икәнсең бит, исән! Минем ничек сөенгәнемне белсәң иде! Әни миннән моны нигә яшергәндер – белмим, минем куанычымның чиге-чамасы юк. Тизрәк күрешәсе килә. Сиңа сөйлисе сүзләрем шундый күп минем. Кызың Илдария. Уфа.»

...Тәрәзә буенда ул шактый озак басып торды. Телефоны аның саен шалтырады. Әнә шул шалтырау «б-р-р-р-р!», «бар!», «бар!», «кызы бар!» дип, аны үртидер кебек тоелды. Юк, телефонын алып иренә дәшә алмады ул. Ни дисен? Нәрсә дип дәшсен? Миен гел бер хәбәр чукыды: «Уфада Илдарның кызы бар икән! Исеме дә нинди бит! Илдария!»

Әлфиясе тугач, Нурания Илдарга: «Әйдә, Илдария кушабыз!» – дип әйтеп караган иде. Тегесе исә кырт кисте: «Юк! Әлфия булгач, Әлфия!»

«Менә нигә каршы килгән икән ул! Аның Уфада үз Илдариясе булган! Һәм тагын кемедер...»

Нуранияга салкын булып китте. Бөтен эче ялкын белән тулы булса да, калтырана-калтырана ул тагын диванга барып капланды.

«Илдары аңа хыянәт иткән! Хыянәт кенә дә түгел – аның Уфада кызы да бар!»

Әле иртән генә ул дөньяның иң бәхетле хатыны иде. Әле бер сәгать элек кенә йөгерә-йөгерә йорт тирәсендә кайнашты, сыерын сауды, тавык-чебешен ашатты, өен җыештырды. Күр инде хәзер кыяфәтен: яңарак кына бәхетле сагыш белән тулы күңеле, көтелмәгән хыянәттән мөлдерәмә булып, тышка ургыла. Нурания, күз яшьләренә коенып, тыелгысыз үкси башлады. Казанда курсларда укып йөргән иренең һәр шалтыратуына куанып, аның сүзләреннән җылынып, балкып йөргән җаны, хәзер инде боздай өшеп, бөтенләй туңып, әкренләп үлеп бара кебек тоелды аңа.

«Илдарның Уфада кызы бар!»

«Йа Хода! Ничек сизмәгән, ничек тоймаган ул иренең хыянәтен? Югыйсә гел бергә булдылар бит. Ял йортларына да Илдар ялгызы йөрергә яратмады: «Барабыз икән – бергә барабыз! Синең дә ялгызыңны гына җибәрү юк, үзем дә синнән башка бер аягымны да атламыйм!» – дип кырт кисә иде. Көннәре мәктәптә үтте, анда да бергә. Юк, иренең бер генә кыек эшен дә сизмәде ул. Һәм менә...»

– Төсең качкан. Авырыйсыңмы әллә?

Нурания дәшәрлек хәлдә түгел иде.

– Әллә жарың да бар инде? Уттай янасың бит!

Күршесе Разия боздай кулын аның маңгаена тидерде. Аны тыңларлык һәм аңларлык кеше табылуына куанып, Нурания ахирәтенә сарылды.

Кемгәдер сөйләү, уртаклашу гына җитмәгән икән. Бераздан ул тынычланып китте.

– Бигрәк көтмәгәндә булды ла... Хатны кулыма тоткач, аңгыраеп калдым.

– Йә инде, җебемә лә... Исеме ничек?

– Кемнең?

– Кызын әйтүем...

– Илдария...

– Илдария?!

– Илдария шул менә, Илдария!

– Матур исем... Илдар үзе нәрсә ди соң?

– Дими...

– Берәр сүз әйткәндер бит?

– Нәрсә әйтсен! Ул белми дә әле.

– Ничек инде – белми? Әйтмәдеңмени? Әллә берни дә сорашмадың?

– Үзе белән сөйләшә дә алмыйм! Телем әйләнми...

– Сөйләшә алмый, имеш... Сөйләшергә, аңлашырга кирәк!

– Кирәк тә... Көчем җитми...

– Бәлки, берәрсе шаярып кына салгандыр ул хатны. Сезнең матур тормыштан көнләшеп...

– И-и-их, шулай булса икән! Түгел шул! Түгел! Күңелем сизә... Аның кызы...

– Уфадан дисең инде...

Нурания дерт итте: «Барды Илдар Уфага, барды. Барды гынамы соң!» Институтны бетергәч, Илдар төгәл бер ел шунда хезмәт итеп кайтты. Ул елларда Нуранияга, аның кебек өзелеп егетен армиядән көтүче башка беркем дә юктыр кебек тоела иде. Ул гына, бары тик Нурания генә шулай ярата ала да, сөйгән егетенең кайтуын да түземсезлек белән ул гына шулай көтә ала...

– Кызы... кайчан кайта соң?

– Бүген... Кичкә таба... Белмим инде, ничек каршы алырмын да, ни диярмен...

– Тә-ә-ә-к, димәк, бүген кайта... Камыр куйдыңмы? Нәрсә пешерергә уйлыйсың? Мунчаң ягылганмы?

– Нинди камыр? Нинди мунча тагын?

– Хәер, анысы соңрак... Өлгерербез... Җәйге мунча берике сәгатьтә әзер дә була ул...

Нурания, шаккатып, ахирәтенә төбәлде. Тегесе аның саен сөйләнүендә булды:

– Гөбәдия пешер. Синеке бигрәк шәп – ашап туймаслык була. Каз итеннән бәлеш тә салырсың... Аннары... Тагын бер сүз әйтим әле үзеңә: Илдар кызы кайткач, караңгы чырай күрсәтмә аңа, яме. Сабыр булырга тырыш. Син үзеңне аның урынына куеп кара әле. Аннары... аның ни гаебе бар?

...Бәлеше пешеп, гөбәдиясе дә әзер булган бер мәлдә капкадан бер хатын килеп керде.





– Исәнмесез... – диде ул ишетелер-ишетелмәс тавыш белән, кыюсыз гына.

Ике хатынның карашлары очрашты.

– Мәктәп директоры Илдар Вахитовлар йортыдыр бит?

Хатын кыяр-кыймас кына сүзен дәвам итте:

– Мин Уфадан кайттым... Исемем – Зарима...

* * *

Зариманың керфекләре дерелдәп куйды. Ул, ап-ак түшәмгә төбәлеп, шактый озак ятты.

«Кайда соң ул? Күзне чагылдырырлык нинди аклык бу?»

Кояш нурында коенып утырган ап-ак бүлмә һәм шул нурларның яктысын меңнәрчә кат көчәйткән ак диварлар, Зариманың аңын томалап, хәтерен бутап җибәрде.

«Туктале! Нинди урын бу? Нинди көн соң бүген? Зарима нишли монда? Нигә ул шушы ак караватта ята?»

Кыз кинәт дерт итте. Хәтере яңарып, бөтен тәнен эсселесуыклы ниндидер дулкын урап алды.

«Ул үлде түгелме соң? Әйе, әйе! Ул суга батты бит! Зарима суга батып үлде!»

Аңа үзе бик тә, бик тә кызганыч булып тоелды.

«Аңа бит әле уналты яшь тә тулмаган иде! Зарима әле берәүне дә яратырга да өлгермәде. Аның бит хәтта егетләр белән үбешкәне дә юк иде! Хәзер инде боларның берсе дә булмаячак. Ул мәңгегә шулай калыр... Унсигез, егерме, утыз яшен дә тутырмас, бервакытта да әни дә булмас... Әни-и-и?! Әни булудан качып, шул адымны ясады түгелме соң?»

Кыз кинәт куркып кычкырып җибәрде: «Аа-а-а-а-а...»

Зарима кисәк башын күтәрде дә ап-ак ромашкаларга томырылып катып калды. Өстәлдәге пыяла банкага утыртылган бер кочак ромашка да аның кебек үк теп-тере иде, Зарима хәтта алардан агылган болын исен дә тойган кебек булды.

«Юк! Ул үлмәгән икән бит! Ул исән! Зарима исән!»

Бүлмәгә ап-ак халатлы бер кыз килеп керде.

– Йә, уяндыңмы инде? Ай-яй, озак йокладың!

Зарима куркудан калтырап куйды.

«Ул уянган! Мәңгегә уянасы килмәгән Зарима уянган! Теге афәт тә аның белән бергә уянгандыр! Ул да тередер! Бөтен вөҗүден өркетеп, котын очырып, шүрләтеп торган, аның карынына кереп урнашкан теге каза да яшидер. Каза... Бәла-каза... Бәла... Бала... Бала?» Зарима үксеп елап җибәрде.

Шәфкать туташы аны кочып алды:

– Абау, җаным, елап торуың күрче! Сөенергә кирәк! Теге солдат коткармаган булса, харап булган булыр идең бит... Бәхетең, ул күреп алган... Шулай ялгызың гына су керергә ярыймы инде! Әниең арт ягыңны кычыткан белән чәбәкләр әле менә.

Зарима көч-хәл белән телен әйләндерде:

– Әнием юк минем... Детдомнан мин...

Кызый, якын итеп, аны кочып алды:

– Исемең ничек соң синең?

– Зарима...

– Туган көнең белән, Зарима... Бүген синең икенче тапкыр туган көнең!

...Туган көннәрне яратмый иде Зарима, детдомда аны күмәк-күмәк үткәрәләр. Март аенда туучылар... Апрель аенда... Майда туганнар... Зариманың туган көне августка туры килә. Аның белән бергә тагын сигез бала. Тугызына да бертөрле бүләк бирәләр. Ул бүләкнең нинди булачагы бөтен детдом баласына бер ай алдан ук мәгълүм була инде. Анна-ры барысы да лимонад эчә, печенье-прәннек белән сыйлана... Уеннар һаман да шул, җырлары да бер үк...

*Как на Заримынины именины / Испекли мы каравай. / Вот такой вышины, / Вот такой нижины, / Вот такой ширины...*

Түгәрәктәге һәр бала уртада торучыны кыса, төрткәли башлый, усалрагы җаен табып чеметеп тә ала.

...*Каравай, каравай, / Кого хочешь – выбирай!..*

...Күзләре тагын ромашкаларга төште Зариманың. Бигрәк матурлар! Бер бәхетлесенә дип, иң-иң эреләрен генә сайлап җыйганнар... Ярата-яратмый дип, таҗ яфракларын берәмтекләп өзгәләп, фаразлап та алганнардыр... Ә Заримага бервакытта да чәчәк бүләк иткәннәре булмады... Беркайчан да... Һәм беркем дә...

Күзләре тагын яшькә күмелде.

– Бу ромашкаларны сиңа теге солдат китерде.

Зарима калтырап куйды:

– Солдат? Нинди солдат?

– Ул әле дә коридорда утыра. Синең уянганыңны көтеп... Хәзер чакырам!

«Юк! Ул бернинди солдатны да белми! Кирәкми! Аның берәүне дә күрәсе килми! Суга да ул үзе керде! Батып үләм дип керде! Нигә коткардылар аны? Нигә?»

Зариманың шулай дип кычкырасы килде, тик өлгерә алмый калды – шәфкать туташы инде чыгып та киткән иде.

...Ул елганың иң-иң киң җиренә керде. Детдомның иң оста йөзүче малайлары да ул тирәдә су коенмый иде. Зәңгәр җирлеккә ак ромашкалар төшкән күлмәге яр буенда калды Зариманың. Керде дә йөзеп китте. Бик озак йөзде Зарима. Әллә аңа гына шулай тоелдымы? Әллә гомеренең соңгы минутларын бераз гына сузарга теләп, шулай озак йөздеме ул? Елганың иң куркыныч җиренә җиткәндә, аның, чыннан да, бер тамчы да хәле калмаган иде инде.

Ул суга... үләргә дип керде. Кул-аягы хәрәкәтләнүдән туктап, гәүдәсе акрынлап төпкә киткәндә, Зарима гомеренең иң матур мизгелләрен искә төшерергә тырышты. Тик андый чак хәтергә килмәде. Үзен аулакта куаклар арасына сөйрәгән, сасы куллары белән авызын томалап, тынын буган кабахәт адәмнең, әлегә кадәр беркем дә кагылмаган күкрәкләрен кармалавы, кызның бөтен тәнен авырттырып ермачлавы гына хәтергә сеңеп калган... Нинди адәм иде ул? Зарима аңышмыйча да калды. Аңына килгәч тә куак төбендә шактый утырды әле. «Нәрсә булды соң бу? Аны нишләттеләр?» Төшенеп алгач, бу урыннан ераграк качасы килеп чапты да чапты ул...

Шул вакыйганы онытырга күпме тырышты ул! Оныттым бугай дип, үз-үзен алдап, бәхетсез тәкъдиренә буйсынган бер мәлдә Зарима үзенең авырга узганын белде. Әле уналтысы да тулмаган кыз бала монысын ук күтәрә алмады. Әнә шушы вәхшилек Заримага яшәргә ирек бирми иде...

Ул бик бәхетле әни булырга хыялланган иде. Аның кызы дөньяның иң-иң чибәре булыр, ә улы исә иң батыр, куркусыз егет булып үсәр. Хыялдагы үз йорты, аның чәчәккә төренгән бакчасы Зариманың төшенә әллә ничә рәт керде


Рәсем: Наталья Васильева

инде. Ул балаларының әтисен үлеп яратыр... Дөньяда әле беркем дә алай яратмагандыр!

...Зарима әнә шундый бәхет турында хыялланган иде...

Монда елганың иң-иң тирән җире иде. Кызның гәүдәсен әнә шул төпсез тирәнлек акрынлап үзенә суыра башлады. Бәхетсез кызның мәсхәрәләнгән гәүдәсен... Тирәнрәк төшкән саен, су да салкыная барды. Көчләнгән Зарима шул упкында өшеп, мәңгелектә югалыр күк иде...

Аяклары су төбенә тигәндә дә, әле югарыга этелерлек егәре бар иде аның. Әмма ул теләмәде... Хыялларын чәлпәрәмә китергән шул пычрак һәм шакшы чынлыкка кире кайтырга теләмәде. Шунда ниндидер көч, чәченнән умырып, аны өскә сөйрәде. Аякларының су төбеннән аерылуын тоеп, ул тыпырчына башлады, үзен югарыга өстерәүче теге билгесез дәрманнан арынырга теләп, бәргәләнде...

Су өстенә калкып чыккач та чәбәләнде әле Зарима.

– Җибәр! Тимә! Җибәр! – дип, ычкынырга теләп тырмашты. Үзен коткаручының кай җирендер тешләп тә алды.

– Тиле кызый! Дөньядан туйдыңмы?

– Мин барыбер үләм! Җибәр!

– Юк! Хәзер үлмисең инде!

Зарима бәргәләнде-бәргәләнде дә, кинәт хәлсезләнеп, аңын югалтты...

Солдат егет кулында бүген дә бер кочак ап-ак ромашка иде.

– Син кем? Ни кирәк сиңа?

Егет елмайды:

– Безнең якта ромашканы ничек атыйлар – әйтимме?

Кыз дәшмәде.

– Ак тәлинкә – сары май! Матур исем бит!

– Ишетәсем дә килми!

Зариманың иреннәре дерелдәде:

– Мине син коткардыңмы? Ник коткардың? Нигә?

Ишек тавышына икесе дә борылып карады. Градусник тотып, шәфкать туташы кергән икән.

– «Нинди солдат?» ди бит. Үзен коткаручыны да танымый. Ярый әле якында ул булган, ашыгыч ярдәм машинасын да чакырткан. Югыйсә берьюлы ике кешенең гомере өзеләсе булган икән лә!

Зарима дерт итте. «Аның авырлы икәнен беләләр! Беләләр! Аның карынындагы бала – теге вәхшинеке бит! Нинди бәхетсез ул!!!»

Ә егет берни булмагандай сөйләнә дә сөйләнә:

– Мин синең йөзгәнеңне ярдан күзәтеп тордым. Син шундый оста йөзәсең!

Кызга таба иелә төшеп, ярым пышылдады:

– Синең... аягыңны көзән җыерды бит?.. Шулай бит?

Солдат егет Заримага төбәлде.

Кыз дәшмәде. Йөзе, күзләре, карашы белән сүзсез генә егеткә кычкырды ул: «Минем үләсем килә-ә-ә-ә!!! Син беләсең бит! Мин үзем теләп... Нигә алардан яшерәсең?»

Шәфкать туташы чыгып киткәч тә озак дәшми ятты ул.

Ә егет әллә ниләр сөйли:

– Такташны укыганың бармы? Шигырьләре искиткеч!

*«Нигә? Нигә? Синең шаян күзләр / Күзләремә болай багалар? / Нинди көчләр, сөйлә, нинди көчләр / Керфек очларыңнан тамалар?»*

Кыз татарча шигырь дә, җыр да белми иде: детдомда өйрәтмәделәр. Аңлый да, сөйләшә дә, әмма шигырьләр белми.

Егет үзенең туган авылы, аның матурлыгы, тиздән, армия хезмәтен тутырып, Наратлыга кайтачагы турында сөйли.

«Болар миңа нигә кирәк? Нигә сөйли ул?»

Тик кызның: «Сөйләмә!» – диясе килми. Бу сәер егетне тыңлавы әллә нигә рәхәт аңа.





– Минем сөйгән кызым бар.... Нурания исемле... Без аның белән бер класста укыдык... Институтта да бергә... Мин – әдәбият факультетында, ә ул – биология укытучысы... Ул да шигырьләр ярата, үзе дә яза...

Егет кинәт шигырь укый башлый:

– «*Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбарәттер йөрәк, –*
*Парә-парә кисмәсә, гыйшык-мәхәббәт кайчысы*», –

монысы – Тукай...

Шунда ул ниндидер җыр да көйләп ала:

*– Яшь наратла-а-ар көе-е-е-н җырла-а-а-п китт-е-е-ең,*
*Көмеш кыңгы-ы-ы-раулы-ы-ы пар а-а-а-тта...*

Нинди матур көй! Нинди моң! Зариманың да аңа кушылып җырлыйсы килеп китә...

Икесе дә тынып калган бер мизгелдә Зарима аңа дәште:

– Синең исемең ничек?

– Илдар...

– Ә мин – Зарима...

...Илдар Зарима янына больницага тагын бер тапкыр килде әле. Анысы инде – хушлашырга. Кызның күңелендә ул укыган шигырьләр уелып калды: *«Ана булу – бөек исем! / Нәрсә җитә ана булуга! / Хатын-кызның бөтен матурлыгы, / Бөтен күрке – ана булуда!»*

...Зарима кыз бала тапты. Аңа Илдария дип исем кушты.

* * *

Илдария ун яшькә кадәр әтисез үсте. Әтисен күргәне булмаса да, ул белә: аның әтисе, иптәшләрен коткарып, батырларча һәлак булган. Әнисе аңа гел сөйләп торды: «Синең әтиең искиткеч батыр, мәһабәт ир-егет иде. Әтиеңне бервакытта да онытма!»

Онытамы соң! Әнә әтисе стенадагы рәсемнән елмаеп карап тора. Кызганыч, бу аның бердәнбер фотосы. Нигә рәсемгә төшәргә яратмады икән ул? Илдария көзгедәге үз сурәтеннән әтисе белән уртак чалымнарны табарга тырыша. Әнисе сөйләгән мәһабәт ир-атка охшыйсы килә аның. Исеме дә әтисенекенә охшаш бит аның – Илдария!

Соңрак, әнисе Самат абыйга кияүгә чыккач та, аны берәү дә ирексезләмәде. «Әти дип әйт!» – дип мәҗбүр итүче дә булмады. Энекәше Илнар «Әти!» дип дәшкәндә, ул «Самат абый!» диде. «Сезнең гаиләдә ничә кеше?» – дип сорасалар, Илдария: «Бишәү!» – дип җавап бирде. Бишенчесе – рәсемдәге әти. Кыз шуңа гадәтләнгән. Ә өлкәннәр дәшмәде.

Мәктәптә укый башлагач, Илдария: «Нигә минем әби-бабаем юк?» – дип, әнисен тинтерәтеп бетерде. Әнә Ниязны бабасы машинада йөрткән, ә Айгөл әбисе белән зоопаркка барган. Тәнзиләнең әбисе исә онытына берсеннән-берсе матуррак күлмәкләр тегә. Илдариянең күлмәкләре дә, туфлиләре дә җитәрлек анысы, тик менә әбисе белән бабасы гына юк. Әнисе үзенең дә, әтисенең дә детдомда үсүен кат-кат кабатлый. Әбисе дә, бабасы да юк шул Илдариянең! Ә Наилнең бабасы барысын да уздырып җибәргән әнә: нинди матур сыерчык оясы ясап куйган.

Эх! Шул әби-бабасыз һәм әтисез тормыш!

Бүген алар өчәүләп Кара диңгез буенда ял итә. Әнисе, Самат абый һәм Илнар. Ә Илдария – Уфада. Самат абыйсының бер дә Илдариянең үзен генә калдырасы килмәгән иде, әмма кыз сүзендә нык торды: «Минем диплом алганны көтеп, ялыгызны әрәм итәсезме? Очыгыз! Имтиханнар тәмам, диплом аласы гына калды. Миңа дигән билет – кесәдә, атна дигәндә, яныгызга килеп тә җитәрмен», – диде.

Инде менә диплом да алынды, чыгарылыш кичәсе дә үтте. Ул – урта белемле шәфкать туташы. Тагын бер айдан эшли дә башлар. Һөнәрен ярата Илдария. Үзен дә яраттылар, практика үткән больницасына эшкә чакырып калдылар.

Өйдә ялгызы калса, эш юктан эш булсын дигәндәй, иске фотографияләр карарга ярата ул. Бүген дә шкафтагы тартманы тартып чыгарды да актарына башлады. Күзе фотолар арасындагы иске газетага төште. «Каян килгән ул? Моңарчы әллә игътибар ителмәгән, әллә бөтенләй булмаганмы? Газетаның числосы да Илдариянең туган елы белән туры килә икән. Егерме ел элек чыккан шәһәр газетасы! Кызык!»

Илдария саргаеп беткән газета битләрен актара башлады. Кинәт аңа әллә нәрсә булды: күзләре таныш рәсемдәге фуражкалы егеткә төбәлеп катып калды. «Әтисе түгелме соң ул? Әйе! Әтисе! Ничек моңарчы бу газетаны күрмәгән ул? Рәсеме дә стенада эленгән кебек. Аның әтисе бит! Вахитов Илдар диелгән! Вахитов? Әтисенең фамилиясе бүтән икән лә».

Илдария дөньясын онытты. Әтисе чынлап та гаярь егет булган икән! Әнә нәрсә язганнар бит: «...нче хәрби часть рядовое Вахитов Илдар суга батучы кызны коткарган өчен Мактау кәгазе белән бүләкләнде», – диелгән.

«Әнисе нигә бу газетаны элегрәк күрсәтмәде икән?»

Алдагы юллар Илдарияне бөтенләй аптырашта калдырды: «Батыр егет, хезмәтен тутырып, Татарстанга – Саба районындагы туган авылы Наратлыга кайтып китте», диелгән.

«Туктале! Нәрсә була соң бу? Әнисе бит аны, нәкъ үзе кебек, детдомда тәрбияләнде дигән иде. Шуңа күрә туганнары да юк дип аңлатты. Туган җире билгеле кешенең туганнары да булырга тиеш ләбаса!»

Ул ноутбугын тартып чыгарды. Илдариянең бармаклары клавишлар өстендә биеште. «Берьялгызы булмагандыр әле әтисе. Бәлки, Наратлыда берәр туганы яшәп ятадыр!»

...Татарстан... Саба районы... Наратлы авылы... Вахитов...

Илдариянең бармаклары бер генә секунд туктап торды...

Кинәт ниндидер эчке аваз: «Яз!» – дип пышылдады...

«Нәрсә дип язарга? Нинди исем?»

Бармаклар үзеннән-үзе хәрәкәткә килде...

...И ...Л ...Д ...А ...Р

Илдариянең бервакытта да мондый шомлы һәм борчулы халәт кичергәне юк иде. Ул, томырылып, компьютерга төбәлде. Бер секунд... Ике... Экранда Наратлы урта мәктәбе директоры Илдар Вахитовның бераз олыгайган фотосы пәйда булды...

* * *

...Уфа–Казан поезды бер сызгыртты да юлын дәвам итте. Әле яңа гына поездан төшкән пассажирлар, төрлесе-төрле якка юнәлеп, таралышып та бетте. Платформада исә өч хатын басып калды: Нурания белән Зарима икесе ике яктан аптыраган-каушаган Илдариягә сарылды.

Серле һәм сәер тынлыкны яңгыравыклы, көр ирләр тавышы бүлде:

– Ну-ра-ни-я-я-я!!!

Бу өчәүгә таба платформа буйлап Илдар йөгерә иде...

# ӘДӘБИЯТТА ЮАНЫЧ ТАБАМ...

**КИТАП УКУ УЛ...**

– Чынбарлыктан качу да, чынбарлыкны баету да ысулы. Минем өчен бу һәрвакыт актуаль. Әдәбиятта юаныч та табам, чынбарлык биргән сорауларга һәм җавапларга да тап булам.

**УКЫРГА МӘХӘББӘТ УЯТКАН КИТАП...**

– Мөгаен, Ркаил Зәйдулланың «Татар таҗы» дигән балалар китабыдыр. 2–3 нче сыйныфта укыганда әлеге китаптан татар ханнары һәм бөек шәхесләре турында беренче тапкыр белдем. Шуңа да балачагымның төп каһарманнары Сафагәрәйләр, Бату ханнар, Бачман батырлар иде. Соңрак, әлбәттә, әлеге исемлеккә Һарри Поттерлар да өстәлде. Әмма китапка мәхәббәт татар тарихын мәңгеләштергән китаптан башлануы минем өчен бик кадерле.

**МИНЕ ҮЗГӘРТКӘН КИТАП...**

– 8 нче сыйныфта укыганда Бернар Верберның «Империя ангелов» китабын укырга тәкъдим иттеләр. Бу – мин белем алган Актаныш районындагы сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернатка махсус чакырылган консультантның тәкъдиме иде. Китап диннәр һәм идеологияләр турында карашларымны шулкадәр киңәйтте ки, ахыр чиктә диннәрне өйрәнү белән шөгыльләнә башлавыма да шул сәбәпче булгандыр. Вербер бик үзгә стильдә һәм үзгә төрле темаларга яза. Аның кызыксынулар спектры миңа бик якын булып чыкты.

**ҮСМЕР ВАКЫТЫМДАГЫ ДУСТЫМ-КИТАП...**

– Әлбәттә, Булгаков! «Мастер һәм Маргарита»дан кайбер аеруча яңгыравыклы өзекләрне яттан да белә идем. Аерым алганда, Понтий Пилат тарихы минем өчен һәрвакыт тәэсирле булып кала. Балачакта берничә тапкыр укып чыккан китап – «Алып батыр маҗаралары». Батулла бу романга (формасы буенча повесть булса да, асылда, роман ул) күп мәгънәләрне сыйдырган. Үсмер чакта милли фэнтези кебек кабул итсәм, хәзер ул милли фәлсәфә чыганагы булып тоела. Үсмер вакытта Айдар Хәлим публицистикасы белән мавыга идем. Айдар абый минем өчен, беренче чиратта, публицистика остасы булды, аның «Гомеремнең ун көне»н – искиткеч хикмәтле китапны – 6 нчы сыйныфта укыган идем. 12 яшьлек малайга нигә кирәк булган ул, хәзер аңлый алмыйм. Әмма шул китапны укып чыкканнан соң Айдар абый белән хат алыша башладык.

**ӨСТӘЛ КИТАБЫМ...**

– Марк Аврелийның «Уйланулар»ы. Римның бөек императорларының берсе үзенә нәсыйхәт итеп язган уйланулар (көндәлек язмалары) гади бер татар кешесе өчен дә файдалы булудан туктамый.

Өстәлдә тормаса да, китап киштәсенең түрендә Дәрдмәнд тора. Дәрдмәндне гомер буе укырга һәм аңларга тырышырга кирәк. Шуңа аңа даими кире кайтам.

**ХӘЗЕР УКЫЙМ...**

– Хәзер мин Шәриф Камалның 1917 елга кадәр язылган мәкаләләрен һәм хикәяләрен укыйм. Аларның шактые киң җәмәгатьчелеккә таныш түгел. Шуңа күрә ике эшне берләштерәм: Шәриф абыйның тәмле прозасы белән ләззәтләнәм һәм текстларын бастыруга да әзерлим.

Көн саен укыла торган башка төр әдәбият – фәнни китаплар. Музей эшчәнлеге буенча да, үземнең фәнни темаларым – католик тәгълиматы, диннәрне өйрәнү фәне һәм фәлсәфә буенча күп укырга бурычлымын.

**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ЯРАТКАН ӨЧ ӘСӘРЕМ ҺӘМ АВТОРЫМ...**

– Галимҗан Гыйльмановның «Оча торган кешеләр»е, Фәүзия Бәйрәмованың «Алыплар илендә» повесте һәм «Кырык сырт» романы һәм, әлбәттә, Дәрдмәнд. Әмма бу бик шартлы исемлек, чөнки бөек әдәбиятыбыз тормышның һәр этабы өчен актуаль әсәрләр тәкъдим итә ала.

**БАСМА ҺӘМ ЭЛЕКТРОН КИТАПНЫҢ УҢАЙ ҺӘМ ТИСКӘРЕ ЯКЛАРЫ...**

– Үсмер чакта укыган әдәбиятның күбесе электрон җиһазларда укылды. Миңа шулай уңайлырак иде. Электрон китап тузан җыймый, аны саклар өчен киштәләр кирәк түгел. Электрон китап индустриясе күп телле: кесәңдә инглиз, рус, төрек әдәбиятларын рәхәтләнеп йөртә аласың. Татарча электрон китапларны укый алмыйм, татар китабын кәгазьдә уку рәхәтрәк.

Мин әле әкренләп аудиокитапларга да ияләшә башладым. Кайбер авторларны аудиода тыңлау рәхәтрәк.

**УКЫРГА КИҢӘШ ИТӘМ...**

– Шәриф Камалны! Гомумән, милли һәм дөньякүләм классиканы укырга кирәк. Борынгы әдәбиятта да хикмәтләр күп. Быел гына «Безнең мирас» журналы «Котадгу белек»нең татарча тәрҗемәсен чыгарды. XI гасыр мирасы булып безгә килеп җиткән әсәрне барлык төркиләр белергә тиеш дип саныйм.

Фото: Салават Кадыйров



Айдар ШӘЙХИН,
Татар әдәбияты тарихы музее һәм Шәриф Камал мемориаль фатиры директоры







Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

*Нык позицияле кешеләр була. Шуларның берсе – танылган галимә, тарих фәннәре кандидаты, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре, Фәннәр академиясендә гыйльми сәркатип булып эшләгән Зөбәрҗәт Газиз кызы Гарипова.*

Зөбәрҗәт ханым 1939 елның июнь аенда Казанда туа. Балачагы һәм яшьлек еллары Тукай урамындагы халык телендә «Шакир солдат йорты» дип йөртелгән йортта уза. Хисапчы булып эшләүче әтисе Газиз Нагаев 1941 елда Бөек Ватан сугышына китә һәм яу кырыннан әйләнеп кайтмый. 2 яшьлек сабый «әттә» сүзен дә әйтә алмый кала. Әнисе Галия сугыш башланганчы ательеда күлмәкләр тегә. Сугыш башлангач, биредә соры солдат шинельләре тегәргә керешәләр. Тегүчеләрнең төгәл эш сәгатьләре юк. Бәләкәй Зөбәрҗәт әнисе эштә чакта өйдә берүзе бикләнеп утыра. Яше җиткәч, Казанның 80 нче мәктәбенә укырга керә, тырышып укый. Аны тарихчы булырга өндәгән кеше – мәктәп директоры, тарихчы Мәрьям апа Зәйнуллина була.
1957 елдан Зөбәрҗәт Нагаева – Казан дәүләт университеты студенты. Университетны тәмамлагач, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына эшкә килә. Фәнни эшчәнлеге – Татарстандагы мәдәни тормышның күпсанлы чыганакларын барлау, аларны дөньяга чыгарып, халык арасында пропагандалау була аның. Автордаш һәм редактор буларак төзегән «Культурное строительство в Татарии. 1917–1941 гг. Документы и материалы»; «Культурное строительство в Татарии 1941–1970 гг. Документы и материалы» китаплары бүген дә фәнни кыйммәтен югалтмаган. Әлеге хезмәтләргә галимәнең «Развитие культуры в Татарии», Указатель литературы на рус., тат. языках (1917–1975 гг.) җыентыгы да өстәлде. Зөбәрҗәт ханым катнашында дөнья күргән «Деятели науки и культуры. (1917–1980 гг.)» дигән хезмәт аеруча игътибарга лаек.
Киң хронологик кысаларда эшләсә дә, Зөбәрҗәт Газиз кызының үзәк темасы – 1917–1941 еллардагы мәдәният тормышын өйрәнү. Бу әһәмиятле тармак моңарчы әле өйрәнелмәгән була, һәм галимә шушы юнәлештә беренче юлны сала.



Галимәнең тагын бер мактаулы хезмәте – «Татары за пределами Татарстана». Анда Татарстаннан читтә яшәүче татарларның 20–30 нчы еллардагы административ хокуклары, татар авылларының социаль-икътисадый хәле, татар төбәкләрендә сәламәтлек саклау эшенең торышы рус һәм башка милләтләр белән чагыштырылып бирелә.

Абруйлы коллектив белән бер гыйлем корабында йөзеп, милләтенең мәдәният тамырларын барлавы белән горурлана галимә Зөбәрҗәт Газиз кызы.

*Равилә МӨБАРӘКШИНА,*
*Татарстан Журналистлар берлеге әгъзасы.*
*Казан шәһәре.*

*И яратам инде укырга! «Сөембикә» журналын да даими укып барам. Кышын – шәһәрдә, җәен авылда торгач, киосклардан сатып алып укырга туры килә. Миңа шулай җайлы. Алдан ук әйтеп куям, журнал редакциясе бик яхшы эшли. Бик тә кешелекле, милләт җанлылар сез.*

Соңгы елларда диннәр тарихы, ислам дине белән кызыксынам. Үзем физика һәм математика укытучысы булып 38 ел эшләгәнгәдер, балалар тормышы, яшьләребезнең яшәү рәвеше, милләтебезнең киләчәге бик уйландыра. «Сөембикә» журналында бүгенге тормышыбыз турында мәкаләләр чыкса, аеруча сөенәм. Билгеле, барлык сәхифәләрне дә кызыксынып укып барам. Быелның гыйнвар санында чыккан «Икс, игрек, зет» язмасы (авторы – Лилия Гәрәева)

Фото: Газинур ХАФИЗОВ

мине кулыма каләм алырга мәҗбүр итте. Әлеге язманы кат-кат укып чыктым. Балаларыбызның бүгенге тормышы бик шәп яктыртылган анда. Күптөрле фикерләргә таянып анализлаган автор.

Үзем яшәгән әйләнә-тирәне күзәтүләремнән чыгып әйтәм: бүгенге балалар – эгоистлар. Турысын әйтәм, автор үпкәләмәсен. Бүгенге зет буыны – җансыз балалар буыны. Үткән гасыр балалары белән бүгенгеләренең төп аермасы менә шунда. Җаваплылык та юк. Гаилә корып, балалар табып, аларны милли рухта тәрбияләрләр дип фаразлап та булмый хәтта. Мәкаләдә: «балагызда шәхес күрегез, диелгән. Әйе, бик дөрес фикер, ләкин әти-әниләрнең күбесе бу киңәшләрне куллана аламы икән? Мөгаен, алмыйдыр.

Билгеле, балаларына бик дөрес тәрбия бирүче, хезмәт сөюче итеп үстерүче гаиләләр дә бар. Мисалга шул ук сандагы «Казыклар» (авторы – Алсу Шакирова) язмасын китерер идем. Рәхәтләнеп укыйсың Хәбриевләр турында. Бердәм булып өч ир бала үстерәләр. Йөзләрендә иман нуры балкып тора. Менә кемнәр безнең киләчәгебез! Их, шундый гаиләләр шәһәр-авылларда да күбрәк булсын иде.

*Рафаэль ЗАРИПОВ.*
*Мөслим районы, Тегермәнлек авылы.*

### *Тормыш шундый инде ул – туулар, табышлар, югалтулар белән ага да ага... Якты җиһанга килеп тукталыш ясаган бер генә адәм баласы да бу тойгыларны үз башыннан үткәрми калмыйдыр.*

Минем тормышымда да быел бик зур югалту булды. Чүпрәле районы Яңа Кәкерле авылы халкының Ак әбисе (бу бәяне аңа мин түгел, ә авылдашлары бирә) – әнием Зиннәтуллина Миңнебану Сәнәтулла кызы фани дөньяга күчте. 96 яшен тутырып, бер генә ай яшәде... Юк, үлмәде әнием, ул күчте. Бу җиһанда үз яшәешенең мәгънәсен тоеп, Ходай тарафыннан юкка гына яратылмаганлыгына инанып, кешелек дәвам итсен өчен, үзеннән соң тугыз бала, унтугыз онык, егерме дүрт оныкчык, аларга өстәп, татарның Ак әбиләренә генә хас пөхтәлек, ихласлык, кешелеклелек кебек сыйфатларны бер гасырга кадәр үзенең кыйбласы итеп танып, шуңа тугры булган зат турында «күчте» дип әйтү дөресрәк булыр. Әниемне соңгы юлга озатканда күз яшьләре белән елаган ир-атларны күрдем. Әниемне физик югалту гына түгел иде бу, аның белән бергә үткәнне, якты истәлекләрне югалту иде. Әниләрен күптән җирләгән һәр авылдаш өчен ул икенче әни була алды, акыллы сүз-киңәш өмет итеп килүчеләр аңа серләрен сөйләде, кайгышатлыклары белән уртаклашты. Авылның күптәннән шәһәргә күчеп киткән балалары да, алардан туган, инде бөтен булмышы белән шәһәрнекенә әверелгән яшь буын вәкилләре дә, әти-әниләре, әби-бабалары нигезен сагынып кайтканда, үткән белән бәйләнешне якынрак тою өчен Ак әбиләрен эзләп киләләр иде. Рәхмәт яусын аларга! Рәхмәт яусын әниемә кыен булган мизгелләрдә ярдәмгә килгән авылдашларыма! Укытучыларым Әмирҗан абый, Гөлира апа; туганнарым Әнүзә, Миңнәҗия апалар, Салихҗан, Равил, Илгиз, Зәйтүнә, Фирүзә; күршеләрем Илһамия, Гөлинә, Шамил, Нурислам абыйлар, Рәмзия, Гөлгенә һәм башка бик күп авылдашларым, чын күңелемнән зур рәхмәтемне җиткерәм сезгә.

Хатын-кызларның, сулкылдыйсулкылдый: «Син безне тәсбих тартырга, кул күтәреп дога кылырга өйрәттең», – дигәннәре әле дә колак төбемдә тора.

*«Моңсу булды, бик ямансу булды,*
*Ак әбине озаттык, кайтмаска.*
*Матур торып, озак яшәсә дә,*
*Сөйләргә дә авыр бу хакта.*
*Иртән көндәгечә чәен эчкән,*
*Боткасын да капкан аз-азлап.*
*Хәл алам, дип, башын куйгач та ул*
*Йокламыйча яткан бик озак.*
*Шул ятудан инде уянмаган,*
*Тыныч кына күчкән дөньядан.*
*Сигез бала, оньк-оныкчыклар*
*Мәхрүм калды газиз анадан»,* – дип язды минем укучым, озак еллар авыл мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән Гөлинә Насыйбуллина, әниемне озаткач.

Ул кара кайгылы көнне авылыбыз үзенең өч кешесе белән бәхилләште. Исхаков Рәфикъ һәм Хисмәтуллин



Рәмисләр дә шушы көнне вафат булды. Бер авыл өстендә никадәр хәсрәт! Аларның да якыннарының авыр кайгыларын уртаклашам.

Милләтебезнең бүгенге яшәешен саклап калуда татарның Ак әбиләренең дә роле гаҗәеп зур. Авыл халкы тормыш юлын сафлык, гаделлек белән узган кешене генә ак сүзе белән бәяли. Озын тормыш юлы үткән, зур тәҗрибә туплаган, халкымның акылзиһенен үзенә сеңдергән, гомере буе хәләл көче белән көн күргән, кылган гамәлләре аша тирә-юньдә зур хөрмәт казанган әнием – Ак әбиебез – безнең горурлыгыбыз. Без, аның балалары, һәрберебез кеше булу өчен иң кирәк сыйфатларны әниебездән алдык. Күңелне сагыш, моңсулык били. Нәрсәдер әйтелмәде, нәрсәдер үтәлмәде кебек... Бары тик авыл халкының әниемә булган хөрмәте генә йөрәкне күпмедер тынычландыра, Яңа Кәкерле авылының Ак әбисе халык хәтерендә озак яшәр, аңардагы рухи байлык буыннан-буынга күчәр дигән өмет уята. Бүгенге авылдашларымның изгелеген, рухи байлыгын, аларның үткән белән бәйләнеш эзләүләрен күрү күңелемдә, Ак әбиләр тагын туарлар, татар милләте беркайчан да ятим булмас, динебез, гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз чишмә суы кебек гел тулып, агып торыр, дигән ышанычны яшәтә.

*Әлфинур НӘҖИПОВА-ЗИННӘТУЛЛИНА.*
*Чүпрәле районы, Яңа Кәкерле авылы.*

***Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адр ес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru***





**Сорауларга Республика клиник хастаханәсенең акушер-гинекологы Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА җавап бирә.**

**Менопауза 30 яшьтә дә башланырга мөмкинме? Моны ничек аңларга?**

Күрем килүнең 30–40 яшьтә туктавы – вакытыннан алда башланган климакс дип атала. Аналык бизләренең вакытсыз картаюы нәтиҗәсе бу. Төрле авырулар, медикаментлар белән дәвалану китерә моңа. Иртә башланган климаксның симптомнары гадәти климаксныкы кебек, аларны хатын-кыз үзе дә сизәчәк. Беренчедән, менструация үзгәрә, канның күләме кими, цикл арасы озыная. Кайберәүләрдә төнлә тирләп чыгу, аналык җиңсәсендәге корылык, якынлык вакытындагы уңайсызлык, йоклап булмау, начар кәеф кебек симптомнар борчый.

**Күрем вакытында эчем нык авырта. Яшүсмер чакта: «Бала тапкач бетә ул», – дигәннәр иде. Ике балам бар инде, ә менструация әле дә бик авыр уза. Берәр кайчан бетәргә тиешме ул авырту?**

Күрем башланырга берничә көн алдан һәм күрем вакытында эч бераз авыртып тору – гадәти күренеш. Ул төрле ешлыкта, төрле дәрәҗәдә булырга мөмкин. Җиңелчә генә борчып торса, тормышыгызга авырлык китермәсә, борчылырлык урын юк. Моның өчен гинекологка мөрәҗәгать итү кирәкми дә. Әгәр инде сез авыртуны 10 баллы шкала буенча 7, 8, 9 балл бирерлек дип санасагыз, күңел болгану, эч китү, баш әйләнү, хәлсезлек, йокы килү кебек башка симптомнар да өстәлсә, гинекологка барыгыз. Башка авырту кебек, күрем вакытында эч авыртудан да профилактик чаралар бар. Даими гинекологка күренеп торыгыз, табиб киңәшләрен тотыгыз, контрацепция кулланыгыз.

**Циклның кайсы көне гинекологка мөрәҗәгать итәр өчен иң кулай дип санала?**

Моның өчен циклның беренче яртысы кулайрак. Менструация тәмамлангач, кан килү туктаганнан соң берничә көннән барсагыз яхшы. Гадәттә, менструация 6–8 көн дәвам итсә, табибка 8–12 нче көнне күренә аласыз. Йөклелек һәм бала тапканнан соңгы чорда көннәр исәпкә алынмый. Табиб сезгә УЗИ билгеләргә мөмкин. УЗИ да шул ук көннәрне уздырыла. Бу вакытта кече оча сөягендә урнашкан органнар төзелеше яхшы күренә.

**Бернәрсә дә борчымаса, цикл белән проблемалар булмаса, җенси мөнәсәбәттә бер ир белән генә яшәсәң, гинекологка даими күренеп тору мәҗбүриме?**

Бернәрсә борчымаса да, елга бер тапкыр күренеп торырга кирәк. Төрле гинекологик чирләрне, күкрәктәге патологияләрне, җенси юл белән күчә торган инфекцияләрне кисәтү, контрацепция билгеләү өчен, авырга узуны планлаштыру өчен гинекологка елга бер тапкыр күренеп тору зарур. 45 яшьтән соң, организмда яшь белән бәйле үзгәрешләр башлангач, ярты елга бер күренеп торырга кирәк. Бала таба торган яшьтәге хатын-кызлар шулай ук елга бер тапкыр УЗИ узарга тиеш. Микрофлораны тикшерү өчен елга бер тапкыр мазок тапшырырга кирәк. Профилактик күзәтү төрле авыруларны башлангыч стадиясендә үк күреп, дәвалау билгеләргә ярдәм итә. 21–65 яшьлек хатын-кызлар өчен өч елга бер тапкыр аналык муентыгыннан цитологик тикшеренүгә мазок тапшыру зарур. Очрагына күрә бу анализны ешрак та билгелиләр.

# СОРАУ—ҖАВАП

Республика клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Валерия Белова ярдәме белән әзерләнде.

**Кадерле укучылар!**
**«Сорау–җавап» рубрикасына сездән сораулар кабул итәбез.**
**Җавап бирүче белгечләр: педиатр, гинеколог, стоматолог, невролог, хирург-ортопед, кардиолог, иммунолог-аллерголог, гастроэнтеролог, эндокринолог, офтальмолог һәм башкалар.**

**Үзегезнең һәм балаларыгызның сәламәтлегенә кагылышлы сорауларыгызны – 8 (843) 2-22-09-77 телефоны аша, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт адресы буенча яисә ssuum@yandex.ru электрон адресына «Сорау–җавап» дип язып җибәрә аласыз.**

Фото: ru.freepik.com



Сорауларга республика балалар клиник хастаханәсенең неврологы Лилия ФАТЫЙХОВА җавап бирә.

**Кызыбызга 4 яшь. Күптән түгел тотлыга башлады. «Т» авазына башланган сүзләрне әйтә алмый, читенсенә, бакчада сөйләшергә ояла. Невролог бу проблема белән булыша аламы?**

Балаларның тотлыгуы нерв системасының аруыннан, какшавыннан барлыкка килә. Аларның нерв системасы әле өлгереп җитмәгән. Кайберләре стресска тиз бирешә. Бу – индивидуаль күренеш. Төрле тиклар барлыкка килә. Барысы белән дә невролог эшли. Барлык анамнезны җыйгач, ул дәвалау билгели.

**Улыбыз 2 нче сыйныфта укый, яшьтәшләреннән нык калыша. Ноотроп препаратлар куллана башласак, алар баш мие эшчәнлеген, хәтерне, фикерләүне яхшыртуда ярдәм итәрме?**

Бала мәктәптә тиз арыса, башкалардан калыша башласа, неврологка, психологка мөрәҗәгать итәргә киңәш итәм. Хәзер остеопат, нейропсихолог кебек яңа белгечләр дә бар. Боларның барысы белән дә эшләргә кирәк, чөнки артта калу сәбәпләре һәр балада төрлечә була. Кирәк дип тапсалар, белгечләр ноотроп препаратлар да, витаминнар да билгеләргә мөмкин. Балагыз физик яктан да үз яшьтәшләреннән калышса, еш авырса, хроник авырулары булса, болар да укудагы уңышларына йогынты ясамый калмый.

**Балага өч ай тулгач неврологка күрендек. Бала тапканда гипоксия булган, диде. Карап торышка алай дип әйтерлек сәбәп тә юк кебек, үз яшенә күрә алга китеше нормага туры килә. Табиб профилактика өчен дарулар язып бирде. Йөклелек чорым да тыныч узды, бала вакытында туды, Апгар шкаласы буенча 8-9 балл бирелде. Дәвалау нигә кирәк соң?**

Әни өчен бар да яхшы тоелса да, невролог гипоксия йогынтысын күргән дигән сүз бу. Невролог тайпылышлар күрә икән, димәк, игътибар белән анамнез җыйганнан соң, аның шикләре туган. Терапия шуңа билгеләнә. Кайбер препаратлар профилактика өчен, зуррак яшьтә, мәктәптә укыганда, яшүсмерлек чорында проблемалар чыкмасын өчен билгеләнә. Шулай ук ЛФК, массаж да ярдәм итәргә мөмкин.

**Балабыз алты айда ук өйдәге җиһазларга тотынып баса башлады. Бик иртә кебек. Умыртка баганасына зыян килмәс микән? Баланы бу омтылышыннан чикләргә кирәкме?**

Баланың иртә баса башлавы бигүк яхшы түгел. Аның мускуллары әле ныгып җитмәгән, басып тору өчен өлгермәгән, ләкин баланы чикләп тә булмый. Аның хәрәкәтләнәсе, үзен сыныйсы килә. Невролог, ЛФК табибы яки инструктор төрле хәрәкәтләр тәкъдим итсә, яхшы булачак. Бала үрмәләсен өчен, әни кеше үзе дә төрле мавыктыргыч, баланы кызыктыра торган уеннар уйласа яхшы. Арка мускуллары ныгысын өчен кирәк бу.

**Нәниләргә күчтәнәч!**
**Телефон камерасын QR-кодка якынайтып, аудиоформатта язылган әкиятне балагызга тыңлатыгыз.**



Республика балалар клиник хастаханәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Зөһрә Гыйбадуллина ярдәме белән әзерләнде.

# ЭШЛЕКЛЕ ЭТИКЕТ

**Эшмәкәр, җитәкче булмаган хатын-кызлар да эшлекле сөйләшү алып бармый калмый. Ул ниндидер зур проектларны гамәлгә ашыру турындагы аралашуны гына күздә тотмый, билгеле. Теләсә нинди рәсми аралашу – хәтта коллегалар арасында да – эшлекле сөйләшү ул. Бу төр этикет эш мохитендә үзеңне тоту кагыйдәләрен җыя. Гап-гади кагыйдәне белмәү дә уңайсыз хәлдә калдырырга мөмкин. Шуңа күрә дә эшлекле этикетны өйрәнү, һич тә булмаса, күзаллау хәзерге җәмгыятьтә бик мөһим. «ТриУмф» этикет мәктәбе җитәкчесе, этикет буенча белгечләр ассоциациясе әгъзасы Елена ГАЛИУЛЛИНАдан мастер-класс.**



**Юлдашың белән башкаларны таныштыру зарурмы?**

Якын кешеләр белән аралашканда, әлбәттә, таныштыру мөһим. Зур чараларда таныштырып тору кирәкми. Җыелып сөйләшеп торган кешеләр янына киләсез икән, бу вакытта юлдашың белән таныштырып китү зарур.

**Кем беренче исәнләшергә тиеш?**

Эшлекле мохиттә үзеңне дөрес тоту турында сөйләшәбез икән, статусы түбәнрәк булган кеше беренче исәнләшә. Мәсәлән, өлкән яшьтәге хезмәткәр хатын-кыз яшь ир-ат җитәкчене сәламли. Эшлекле даирәдә җенес билгесе, яшь буенча бүленешләр юк.

**Эшлекле очрашулар вакытында сөйләшүче булу яхшыракмы, тыңлаучы булумы?**

Кем белән нинди статуста очрашуыгызга карап хәл ителә торган мәсьәлә. Статусыгыз очрашкан кешенекенә караганда түбәнрәк булса, тыңлаучы булу яхшырак. Эшлекле сөйләшү килешүләр төзү турында икән, профессионал булуыгызны күрсәтү өчен сөйләүче булу файдалы.

**Кул бирешеп кайчан күрешергә кирәк? Беренче булып кем кул бирә?**

Кул бирешеп күрешү исәнләшүдән соң була. Бу – эшлекле даирәдә чит кеше тәненә бердәнбер тапкыр кагылу. Партнерлар арасында якынлык булдыру өчен болай күрешү алымы куллану мөһим. Статусы буенча түбәнрәк торган кеше беренче булып исәнләшсә, югарырак вазыйфа биләгән кеше кул бирә. Кунак кабинетка исәнләшеп керә, ә җитәкче кулын биреп күрешү өчен өстәл артыннан чыга. Көндәлек тормышта да бу рәвешле күрешү әдәплелек билгесе буларак кабул ителә. Яше буенча кечерәк кеше исәнләшә, өлкәне кул бирә. Ир-ат белән күрешкәндә, башлап хатын-кыз кул бирә.

**Эшлекле очрашулар вакытында телефоннан сөйләшергә мөмкинме?**

Әлбәттә, юк. Очрашуга килгәнсез икән, бөтен игътибарыгыз, хөрмәтегез әңгәмәдәшегезгә юнәлсен. Киресенчә булган очракта ихтирамсызлык билгесе итеп кабул ителәчәк. Әгәр дә инде җитди шалтырату көтәсез икән, «кичектереп булмый торган шалтырату көтәм, гафу итегез», дип, алдан ук әйтергә кирәк. Эшлекле, җитди сөйләшүләр вакытында телефон шалтыравына бүленәсез икән, бу инде тәрбиясезлек билгесе.

**Эшлекле аралашу вакытында нинди темаларга сөйләшергә мөмкин?**

Һава торышы, очрашуга килеп җитү турында сөйләшү һәрвакыт урынлы. Мәдәният, спорт хакында сүз алышырга мөмкин. Ике арада каршылыклар чыгармый торган темаларга өстенлек бирегез. Ничә яшьтә булу, сәламәтлек, балалар хакында фикерләшмибез. Шулай ук дин һәм сәясәт турында сөйләшмәү хәерле, чөнки һәр кешенең үз карашы. Югыйсә сөйләшү бәхәсләшү белән тәмамланырга мөмкин.

**Дресс-код саклау мөһимме?**

Дресс-код һәрвакыт мөһим һәм булачак. Кызганыч, бүген дресс-кодка артык игътибар ителми, бик еш кына аны хатын-кызлар сакламый – киенү рәвеше белән башкаларга эшлекле очрашуның үзе өчен бик әһәмиятле булмавы турында хәбәр итә. «Ни туры килде, шуны кидем дә килдем, миңа шулай уңайлы», – ди киемегез сезнең өчен. Шуңа күрә эшлекле күрешүгә әзерләнгәндә кая һәм нәрсәгә баруыгызны онытмагыз. Кием – имиджның бер өлеше. Онытмагыз: ул сезнең хакта тәэсир тудыруда зур роль уйный.

**Таныш булмаган кешеләр белән саубуллашырга кирәкме?**

Беренчедән, без һәрвакыт саубуллашабыз. «Инглизчә китү» – тәрбиясезлек. Ниндидер чарада таныш булмаган кешеләр белән булсагыз да, саубуллашып, оештыручыларга рәхмәт әйтеп китәргә кирәк.

# КҮЗЛӘРГӘ МАКИЯЖ

**Күзләргә дөрес ясалган макияж карашны тирәнрәк, серлерәк итә. Ул табигый матурлыкны күрсәтеп кенә калмый, имиджны да тулыландыра. «Күзгә көндәлек макияж ясау техникасын бер тапкыр өйрәнсәң, бер кыенлыгы да юк. Бары тик көн саен көзге алдына басып бизәнергә гадәтләнергә кирәк», – ди визажист Зөһрә ГАРИПОВА. Ул күзләрне буяу серләрен ача.**

■ Күзләргә макияжны махсус косметик чара – база сөртүдән башлыйбыз. Аны, күзне йомып, бармаклар йә кечкенә пумала ярдәмендә күз кабагына һәм каш асларына тигезләп сөртәбез. Шул рәвешле тән төсе тигезләнә, базага сөрмә (тень) дә яхшы ята.

■ Күзгә сөртә торган сөрмәләр төрле була. Без коры текстура белән эшләрбез. Моның өчен яссы пумала алабыз. Аны сөрмәгә буйыйбыз, артыгы коелсын өчен, кулга яки салфеткага тидереп алабыз. Шуннан соң гына ашыкмыйча буярга керешәбез.

■ Көндәлек макияжда пастель төсләр куллану яхшырак. Күз кабагына йомшак пумала белән шул төсләрдәге сөрмәне сөртәбез. Киләсе этапта көрән төстәге сөрмә кулланабыз. Аны күзнең өчтән бер өлешенә ягабыз. Аннан «дымка» ясыйбыз, ягъни күзнең тышкы почмагыннан өскә таба өлешен 1-2 мм чак кына каралтабыз. Шулай итеп күзне «күтәртәбез».

■ Соңыннан коңгырт-көрән сөрмә белән буйдан-буйга күз кабагының өске ягын аз гына каралтабыз һәм йомры төкле кечкенә пумала белән тигезлибез.

■ Кара гель-карандаш белән өске керфек төпләренең араларын буйыйбыз. Бер генә миллиметр да буш ара калырга тиеш түгел. Һәм коңгырт карандаш белән күзгә «ук» («стрелка») сызабыз. Бу – бизәнү техникасында иң авыры. Ныклап аңлар өчен, видеоны карарга киңәш итәбез. «Ук» бик матур килеп чыкмаса, аны пумала яки бармаклар белән өскә таба «тарттырабыз». Ул бар хатын-кызларга да килешә, дөрес итеп сызарга гына кирәк.

■ Макияжны тушь сөртеп тәмамлыйбыз, аны керфекләрнең очына түгел, ә түбәннән башлап сөртәбез. Кәеф өчен күз кабагына, күзнең эчке почмагына бераз хайлайтер тидерергә була. Аннан биткә румяна, бронзер сөртәбез, иреннәр турында да онытмыйбыз. Көн саен макияж ясап, матур булып йөрегез, үзегезне яратыгыз!



QR-код аша кереп, күнегүләрне видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.


2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

# Катлама



**Татар халкының борынгыдан сакланып килгән милли ризыклары арасында катлама рецепты да бар. Катламаны башка күп кенә төрки халыклар да пешергән, ләкин безнеке аларныкыннан үзгә. Пар өстендә пешерелгән катлама мантый, «ханум» белән дә охшаш. «Аш-су» сәхифәбезнең кунагы Альбина ФӘСХИЕВА: «Катлама миңа балачактан ук таныш, аны әнием еш пешерә иде. Аңа исә әбием өйрәткән булган», – ди. Альбина – журнал укучыларыбызга таныш кыз. Аның фотосы узган елгы апрель саныбызны бизәде. Яшь кенә булса да, милли аш-су остасы буларак танылып өлгерде инде ул. «Укытучым дип Нурҗиһан апа Галимованы саныйм. Аннан бик күп серләргә өйрәндем. Нурҗиһан апа – Юныс ага Әхмәтҗановның укучысы», – ди Альбина. Кунагыбыз Казанда яшәсә дә, Кукмара районы Поршур авылында туып-үскән. Поршур – керәшен авылы. Күрәсез, алар борынгы матур җырларыбызны гына түгел, борынгы рецептларыбызны да саклап кала алганнар.**

## *Кирәк*

**камыр өчен:** 1 йомырка / 200 г сөт (100 г су һәм 100 г сөт алырга була) / 2 аш кашыгы үсемлек мае / 400 г бодай оны / ярты чәй кашыгы тоз.

**эчлек өчен:** 1 кг тарттырган ит (фарш) / 400 г суган (кимрәк яки күбрәк тә куша аласыз) / 50 г сөт / чәй кашыгы ярым тоз / тәменчә борыч.

**соус өчен:** 200 г кибет каймагы (борынгылар катык кулланган) / бер тотам кинза яки башка төрле аш тәмләткеч үлән / тәменчә тоз.



■ Безнең эчлегебез инде әзер иде. Итне иттарткычтан чыгардык. Суганны исә блендерда ваклаттык, алай эчлек сусылрак була. Борынгылар исә туралган итне кечкенә агач тагаракка салып, махсус тимер тәпке белән тапаган. Андый тәпкеләрне авылларда әле дә күрергә була. Суганны исә вак угычтан уганнар. Әзер иткә суган, тоз, борыч, сөт кушып, яхшылап тугларга кирәк Ит озаклап туглаганны, кул белән бәргәләгәнне ярата.

**Эш барышы:**







■ Тирән эчле савытка йомырка сытып, чәнечке белән җиңелчә генә туглыйбыз. Йомырканың оешы беткәч, сөт, май, тоз салып, тагын бер болгатабыз.

■ Он салып, уклау белән җәярлек үзле камыр басабыз. 10 минут баскач, өстен каплап, 10–15 минут ял иттереп алырга кирәк. Камырны ике кисәккә бүлеп, һәрберсен уклау белән тәгәрәтеп җәябез. Токмач җәйгән кебек үк юкартып бетермәгез, калынлыгы 2-3 мм булсын.

■ Җәемне пычак белән урталай бүләбез. Һәрберсенең киңлеге чама белән 20 см тирәсе. Һәр кисәккә артык юка итми генә итне ягабыз. Эчлек бик калын да булырга тиеш түгел.







■ Катламаны аскы читеннән өскә таба тәгәрәтеп төрәбез. Буш итеп төрмәскә тырышыгыз. Шул ук вакытта артык тыгызлап та бетермәгез.

■ Мантый казаныгыз булса, катламаны шунда пешерүе уңай. Борынгы чорда сулы кәстрүл өстенә куелган тимер иләккә салып пешергәннәр. Иләк суга тиеп торырга тиеш түгел. Иләкнең өстен капкач белән капларга кирәк. Су кайнап чыккач, утны бераз киметеп, катламаны 40 минут парда пешерәбез.

■ Катлама пешкән арада соус әзерлик. Кибет каймагын касәгә салып, ваклап туралган кинза (үзегез яраткан башка үлән дә куллана аласыз), уылган сарымсак (теләсәгез), бер чеметем генә тоз салып, яхшылап туглярга кирәк. Элеккеге вакытта соусны катыктан ясаганнар.

■ Табынга катламаны кайнар килеш, 3-4 см калынлыгындагы кисәкләргә бүлеп чыгаралар. Янына каймаклы соус куялар.
Ашларыгыз тәмле булсын!



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия



Кәефнең шундый чагы була бит: ниндидер тәмле әйбер ашыйсы килә, ләкин плитә янында вакыт уздырасы килми. Өстәвенә, ул ашыйсы килгән әйбер диетик рецепт буенча да булса... Бу очракта мичтә пешкән груша барлык таләпләрегезгә дә җавап бирәчәк! Моның өчен грушаның каты сортын сайларга кирәк. Ә баллылыгын бал белән көйләрбез.

Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА



# Грушалы десерт

### Чикләвекле груша

Бу десертны әзерләр өчен ике груша һәм әстерхән, пекан йә фундук чикләвекләре кирәк булачак. Әстерхан чикләвеге алсагыз, сигезен ваклагыз, сигезен шул килеш читкә куеп торыгыз.

Грушаларны юыгыз, урталай бүлегез. Җайлап кына грушаның эчен алыгыз һәм шунда чикләвекнең вакланмаганын салыгыз.

Грушаларны пергамент кәгазе җәелгән табага тезегез, өстенә бал агызыгыз, дарчин (корица) сибегез. Шулай ук өстеннән вакланган чикләвек сибеп, 180 градуслы мичкә 20–25 минутка куегыз. Һәркемнең миче төрлечә кыза, игътибарлы булыгыз: грушалар йомшарырга, ләкин формасын югалтмаска тиеш.



### Эремчекле сыр белән груша

Грушаны алдагы рецептта язылганча әзерләгез, эчен алыгыз. Эчлек өчен эремчекле сырга бал салып болгатыгыз, груша эченә салыгыз. Эремчекле сырны каймак белән кушылган гади эремчеккә дә алыштырырга була.
180 градуслы мичтә 20–25 минут пешерегез.
Өстен уылган чикләвек йә анар төшләре белән бизәгез.

### Бри сыры белән груша

Бу рецепт гадәти булмаган тәмле ризык яратучыларга аеруча ошар.
Аның өчен «Бри» йә «Дор блю» дигән күксе сыр сайлагыз. Алар баллы груша белән бик яхшы туры килә.
Грушаның эчен, орлыкларын җайлап кына алыгыз: озынча буразналар калырга тиеш. Сырны борыслап турагыз, груша эченә тезеп чыгыгыз. Өстеннән бал агызыгыз. Груша 20–25 минут пешә. Әзер грушаның өстенә уылган чикләвек сибегез.

Фото: Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА

### *Грушаның файдасы*

**Грушада калорияләр аз: 100 грамм грушада нибары 50 ккал бар. Витаминнарга да бик бай ул. Организмның вирусларга, бактерияләргә каршы торуын көчәйтә. Холестерингә, атеросклерозга каршы да бик яхшы профилактика булып санала. Организмнан токсиннарны, шлакларны чыгаруда ярдәм итә. Эчәкләрнең микрофлорасына уңай йогынты ясый, ашкайнатуны, матдәләр алмашын яхшырта. Груша организмны иртә картаюдан да саклый әле. Чәчләрне ныгыта, тирегә уңай йогынты ясый. Груша йод җитмәгәндә, калкансыман биз белән проблемалар булганда да булыша.**

## *тест:* Үзегезгә куйган бәягез нинди?

*1. Бу эшне эшлисе түгел яки бу сүзне әйтәсе түгел иде, дигән уй сезне еш борчыймы?*
а) бик еш – 1 балл; б) кайчагында – 3 балл; в) беркайчан да – 5 балл.
*2. Сүз артыннан кесәгә керми торган акыллы һәм зирәк кеше белән аралашканда, сез:*
а) аннан да остарак булырга тырышам – 5 балл; б) аның белән осталыкта ярышмыйм, аның зирәклеген танып, телемне тыям – 3 балл; в) андый кешеләр белән аралашырга куркам – 1 балл.
*3. Үзегезгә якын булган бер фикерне сайлагыз:*
а) җәйлы гына ирешелгәндәй тоелган уңыш артында зур хезмәт ята – 5 балл; б) уңыш – күбрәк бәхет эше – 1 балл. в) катлаулы хәлгә тарысаң, иң мөһиме – мәсьәләне чишәргә тырышу яки вакыйгаларның җай килеп торуы түгел, ә бәлки янында тынычландыра һәм хуплый алырдай кешенең булуы – 3 балл.
*4. Сезгә карата ясалган пародия яки шарж күрсәтсәләр, сез:*
а) көләсез һәм ниндидер үзенчәлегегез булуына сөенәсез – 3 балл; б) партнерыгызда да ниндидер бер кызык нәрсә табып, аннан да көләргә тырышасыз – 5 балл; в) үпкәлисез, ләкин хисегезне белдермисез – 1 балл.
*5. Сез һәрвакыт ашыгасыз, гел вакытыгыз җитми яки сезнең генә көч җитмәстәй эшләргә* алынасызмы?
а) әйе – 1 балл; б) юк – 5 балл; в) кайчагында – 3 балл.
*6. Дус кызыгызга хушбуй сайлаганда, сез:*
а) үзегезгә ошаганын аласыз – 5 балл;
б) үзегезгә бик ошамаса да, дустыгыз сөенәчәк дип уйлаганына өстенлек бирәсез – 3 балл; в) рекламага ышанасыз – 1 балл.
*7. Үзегезне гадәти булмаган ситуацияләрдә калган дип (һәм бу ситуациядә сез үзегезне тормыштагыча тотмыйсыз) күзалларга яратасызмы?*
а) әйе – 1 балл; б) юк – 5 балл; в) кайчагында – 3 балл.
*8. Коллегаларыгыз (бигрәк тә үзегездән яшьрәкләр) күбрәк уңышка ирешсә, көнләшәсезме?*
а) әйе – 1 балл; б) юк – 5 балл; в) кайчагында – 3 балл.
*9. Сүз көрәштерергә яратасызмы?*
а) әйе – 5 балл; б) юк – 1 балл; в) кайчагында – 3 балл.
*10. Күзләрегезне йомыгыз да түбәндәге өч төснең берсен күз алдына китерергә тырышыгыз.*
а) зәңгәрсу – 1 балл; б) сары – 3 балл; в) кызыл – 5 балл.

**50–38 балл.** Сез үзегездән канәгать һәм үзегезгә ышанасыз. Башкалардан өстен булырга яратасыз, үз фикерегезне өстен чыгарырга телисез. Башкаларның үзегез хакында ни әйтүе сезне кызыксындырмый, ә менә бүтәннәрне тәнкыйтьләргә сезгә генә куш.
**37–24 балл.** Үз-үзегез белән килешеп яшисез. Авыр хәлләрдән чыгу юлларын таба беләсез. Сезнең хакта: «Үзеннән дә, башкалардан да канәгать» дияргә була. Сез үзегезгә дөрес бәя куясыз, аны башкалар хисабына күтәрмисез.
**23–10 балл.** Сезне үз-үзеннән канәгать кеше дип әйтеп булмый. Мөмкинлекләрегез, уңышларыгыз, кыяфәтегез, акылыгыз – берсе дә сез теләгәнчә түгел кебек. Акыллы кеше үзен гел тәнкыйтьләп торырга тиеш дигән фикерне сезгә кем сеңдерде? Үзегезне ничек бар шулай кабул итегез, үзеңне ярату начар нәрсә түгел ул.

## йолдызнамә апрель

***Кучкар.*** Энергия потенциалыгыз гадәттәгедән югарырак. Бу сезне гел яңа эшләргә, үзгәрешләргә тартып торачак. Максатка җиңелрәк ирешә торган вакыт, катлаулы мәсьәләләрне хәзер чишегез.

***Үгезбозау.*** Ыгы-зыгылы чор, айның беренче яртысы аеруча тынычсыз узар. Эштә игътибарлы һәм сак булыгыз, бар дипломатиягезне кулланырга туры килер. Шәхси тормышта исә күңелле үзгәрешләр көтелә.

***Игезәкләр.*** Уңышлар һәм күңелле үзгәрешләр чоры. Эш белән бәйле яңалыклар күп булачак. Бу ай уңышлы сәфәрләр, яңа танышулар белән исегездә калыр, мөгаен. Матди өлкәдә дә сюрпризлар көтелә.

***Кысла.*** Тырышлыгыгызның әҗерен күрер вакыт җитте. Көткәннән дә күбрәккә ирешерсез. Киләчәккә иң кыю планнарны кора аласыз – уңыш сезнең якта. Теләсә кайсы мәсьәлә сезнең өчен уңай хәл ителәчәк.

***Арыслан.*** Үзгәрешләрдән курыкмагыз, яңалыкларга ышаныч белән карагыз, яңа белемгә омтылыгыз. Тормышыгызның тагын да кызыклырак чоры якынлаша. Актив һәм уңышлы чорларыгызның берсе бу.

***Сөмбелә.*** Эштә дә, шәхси тормышта да бераз үзгәрешләр көтелә. Үзе актив, үзе катлаулы вакыт. Финанс тотрыклылыгына исәп тотарга ярамый. Алганга караганда, күбрәк бирергә туры киләчәк.

***Бизмән.*** Акча мәсьәләсе, очрашулар, дискуссияләр – күбрәк менә шулар белән мәшгуль булачаксыз. Партнерлык мөнәсәбәтләрен җайлау, элеккеге элемтәләрне ныгыту беренче урынга чыгачак.

***Чаян.*** Язмыш сезгә хәерхаһлы – бер дигән мөмкинлекләрне мулдан өләшә. Кемдер – һөнәр өлкәсендә, кемдер шәхси тормышта уңышка ирешәчәк. Тырышлыгыгызның әҗерен күрерсез, абруй казанырсыз.

***Укчы.*** Иң кыю планнарыгызга да курыкмыйча тотына аласыз. Әлеге чор гаҗәеп иҗади һәм эшлекле булыр. Әллә нинди катлаулы мәсьәләләр дә җиңел генә чишелеш табачак. Уңыш сезнең якта.

***Кәҗәмөгез.*** Гармонияле чор. Төп урында хуҗалык һәм көнкүреш мәсьәләләре торачак. Ләкин эшсөяр Кәҗәмөгезләр үзләренә һәрвакыт мәшәкать таба. Акча белән бәйле зур эшләрне кузгатмый тору хәерлерәк.

***Сукояр.*** Мөмкинлекләр һәм файдалы сөйләшүләр, килешүләр ае. Алга таба үсү өчен партнерларыгыздан яки коллегаларыгыздан бик зур этәргеч алырсыз. Элеккеге мөнәсәбәтләр яңарырга мөмкин. Үзегезгә яңа шөгыль табарсыз.

***Балыклар.*** Сез нәкъ магнит кебек: файдалы мәгълүматны, кирәкле кешеләрне үзегезгә тартачаксыз. Иң кыю планнарыгызны да тормышка ашыру өчен җае чыгар. Яхшы нәтиҗәләр дә озак көттермәс.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА, Алсу ШАКИРОВА әзерләде.









# ЕФӘКТӘГЕ СӘНГАТЬ

Рәссам, Россия һәм Татарстан Рәссамнар берлекләре әгъзасы Дилә Барышева менә инде 20 елдан артык – батик сәнгате юнәлешендә, 1991 елдан төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләрдә дә актив катнашып килә. Аның шәхси күргәзмәләренең саны гына да инде ике дистәгә якын!

2007 елда ул «Ел хатын-кызы» конкурсының «Мәдәният һәм рухият» номинациясендә җиңеп чыкты. 2017 елда исә Дилә Барышева Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре исеменә лаек булды.

– Яшел Үзәндә туып-үстем. Рәссамлыкка сәләтем – нәселдән, – ди оста. – Әтием Рәшит Галиуллин талантлы рәссам һәм график иде, 40 елга якын Яшел Үзән балалар сынлы сәнгать мәктәбен җитәкләде. Әнием Әлфия А. М. Горький исемендәге заводта икътисадчы булып эшләде, кызганыч, ул инде арабызда юк... Әни бакчабызда чәчәкләр үстерә, аеруча төрле пионнар ярата иде. Хәзер дөньядагы бар пионнар да миңа әнием хакында сөйли... Әтием исә миндә рәсем сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләде, ул остазым да, илһам чыганагы бүләк итүчем дә, иҗатташ дустым да иде! Башта сынлы сәнгать мәктәбен, 1983 елда – Казан сынлы сәнгать училищесын, 1996 елда И. Я. Яковлев исемендәге Чуаш дәүләт педагогика институтын уңышлы тәмамладым һәм 1987 елдан алып бүгенгәчә Яшел Үзән сынлы сәнгать мәктәбендә балалар укытам.

Дилә Рәшит кызы үзлегеннән батик сәнгатен үзләштергән. «Ефәккә ясау мөмкинлекләре киң. Батикның могҗизаи тәэсирен аңлаган рәссам чын батикчы булып китә ала», – ди ул. Үзенең иҗатында батикның сәнгати бизәм ысулын да, кайнар һәм салкын ысулларын да кулланып иҗат итә. Хезмәтләрендә күк чиксезлеген хәтерләтүче зәңгәр төскә аеруча өстенлек бирә. Яшел Үзәндә берничә ел дәвамында Н. И. Фешин исемендәге Казан сынлы сәнгать училищесы филиалы эшләгән чорда студентларына да әлеге сәнгать нечкәлекләрен җентекләп төшендергән.

Үз брендын булдырып, зәвыклы хатын-кызларыбыз өчен ефәк аксессуарлар да иҗат итә Дилә ханым. «Төрлечә стильләштерү хакында да онытмыйм, символларны, орнаментларны җентекләп барлыйм. Эшләремнең күңелгә отышлы булуын, беркемне дә битараф калдырмавын телим, – ди рәссам. – Минем барлык хыялларым, фантазияләрем тукымаларда җанлана. Чәчәкләр, пейзажлар, абстракцияләр сурәтлим. Тематик әсәрләрем, триптихларым да бар...»


Декоратив-гамәли сәнгать остасының иҗаты төрле күргәзмәләрдә экспозицияләнә. Ул 2004 елда Германиядә узган «Төбәк сәнгате» күргәзмәсенең – III дәрәҗә, 2001 елда «Алтын куллар» төбәкара бәйгесенең «Тукыманы сәнгати бизәү» номинациясе буенча – II дәрәҗә дипломнарга, 2002 елдагы хезмәтләре «Кантри» балалар киеме коллекциясендәге бизәмнәре өчен «Зөбәрҗәт» балалар мода театрлары бәйгесенең I дәрәҗә дипломына лаек булган. 2017 елда «Алтын кош» декоратив-гамәли сәнгать бәйгесендә исә «Автор проекты» номинациясендә җиңү яулаган. Рәссам-мультипликатор буларак, «Камыр-Батыр» мультфильмын иҗат итүдә дә катнашкан. Аның әсәрләре – Татарстан музейлары, Яшел Үзән сәнгать галереясы һәм Татарстан, Россия, Германия, Польша, Венгрия, АКШ, Япония шәхси тупланмалары күрке.

Алар гаиләсендә барысы да иҗатчылар: җәмәгате Алексей сәнгати фотосурәтләр төшерү белән мавыга, кызлары Яна келәмнәр чигә, ә Вилена исә – дизайнер, арт-терапевт, балалар иҗат студиясен җитәкли. «Дүрт оныгыбыз арасыннан рәссамнар да чыгар дип ышанам, үз тәҗрибәмне алар белән уртаклашыр көннәр килеп җитүен көтәм!» – дип өметләнә Дилә ханым.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА







ДИЛӘ БАРЫШЕВА






Саида

16 ТӨРЛЕ ПРӘННЕК, МАРМЕЛАД, КОРЖИК, ПЕЧЕНЬЕ


Сөтле прәннекләрне җирле җитештерүчеләрнең эремчек суыннан гына пешерәбез

Лимонлы, бөтнекле прәннекләр өчен үз технологияләребез буенча куе ширбәт ясыйбыз

Озак саклансын өчен төрле азык-төлек өстәмәләре кулланмыйбыз. Саклану вакыты – 30 көн

Мармеладны пектин нигезендә ясыйбыз

Ел саен «Хәләл» стандартлары буенча сертификация үтәбез



Саба районы
Шәмәрдән авылы,
Тимерьюлчылар
урамы, 10
8-927-249-46-22
8-937-521-76-19

e-mail: saida-kf@mail.ru

РЕКЛАМА